ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 4 (340)
АПРЕЛЬ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ҮЗЕБЕЗ БЕЛӘН КҮЗГӘ-КҮЗ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Мөршидә Кыямова, Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-878
Басарга кул куелды: 24.04.2020
Басмадан чыкты: 30.04.2020

БИТЛЕКЛЕ КЕШЕЛӘР

Ел фасыллары кебек үк, һәр дәвернең дә үз сыйфат-билгеләре бар. ТАССР туып кына килгән чорда, 1920 нче елларда, шундый билгеләр булып будёновка белән күн курткалар исәпләнгән. Хәзер инде музейларда лаеклы урынын алган яисә мәктәп дәреслекләреннән генә безгә таныш булган бу киемнәр – үткәннең символы. 1960 нчы еллар билгесе – басу-кырлар патшабикәсе кукуруз, дисәк, ялгышмабыз, шәт. 80 нче еллар «музыка безне бәйләде» рәвешендәге хитлар белән истә калган. 90 нчы елларда көнкүрешкә алагаем зур шакмаклы букчалар килеп керде, аларны «челноклар» үз заманы билгесенә әверелдерде. Бу кешеләр үз җилкәләрендә авыр-авыр букчаларны гына түгел, ә тулы бер чор икътисадын да сөйрәп баручылар булды...

2020 нче еллар нәрсәсе белән истә калачак соң? Мөгаен, битлекле кешеләре белән: ак, кара, шакмаклы, борчак төшерелгән, чәчәкләр белән бизәлгән чуар битлекләр – бүгенгенең аерылгысыз атрибуты.

Вазгыять ничек кенә кырыс булмасын, 2020 нең модалы интернет-индустриясе, коронавирус белән көрәшкә аз булса да төрлелек кертү максатыннан булса кирәк, алдагы буыннар өчен тарихны онлайн-битләргә яза: битлекләр белән бергә виртуаль мәйданда тулы бер комплект тегәләр һәм саталар. Билгеле инде, халык күз алдына син тиешле рәвештә чыга алсын өчен...

Хәер, халык күз алды дигәне, билгеле... әлеге дә баягы Инстаграм. Әмма монда да әдәп сакларга кирәк. Рәсемнәрне карап, лайклар куеп баручылар бит, дөньяның тәртиптә икәнен күреп, яхшы тәэссоратлар кичерәчәк, даруханәләр – җиңел сулаячак. Соңгыларында инде битлекләрне эпидемия башланган тәүге көннәрдән бирле көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмый...

СЕЗНЕҢ ҮЗИЗОЛЯЦИЯЛӘНГӘН РЕДАКЦИЯГЕЗ

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга. Гомуми тираж: 3500 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ

www.protatarstan.ru

АЙДА КАЗАНГА БӘЙЛЕ УРЫННАР

Айда Казанга бәйле дистә ярымлап урын барлыгын беләсезме? Николай Лобачевский, Дмитрий Лубяго, Игорь Белькович, Анатолий Нефедьев, Авенир Яковкин... Әлеге галимнәрнең исемнәре Айдагы кратерларга кушып мәңгеләштерелгән. Казан галимнәре Айны тикшерүгә гаять зур тырышлык куеп, Россия буенча гына түгел, дөнья күләмендә дә алдынгылар рәтенә керделәр! Без Айны өйрәнү буенча махсуслашабыз дияргә дә буладыр....

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

барыТИК ТАТАРСТАНДА

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Вируска каршы көрәш
Татарстан фәне COVID-19ка каршы нәрсәләр тәкъдим итә ала

8. «Чиста су» президент программасы
Каты суны ничек йомшартырга

12. Педагог анты
Авыл укытучысына ничек миллионер булырга

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18. Кече Ватан патриотлары
Әхсән Фәтхетдинов иҗаты

24. Бөек Җиңүнең 75 еллыгына
Арча эвакогоспитале

28. Тыл ветераннары
Илебезнең шәфкать туташы

30. Тарих сәхифәләре
Казан губернасы 1812 елгы Ватан сугышында

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

8. Беренче Президент дәвере
Минтимер Шәймиев хыялларын ничек тормышка ашырган

16. Бөек күченүләр чоры
Тузган торак программасы буенча күпме фатир тапшырылган

20. Башта снайперлар, аннан – Ельцин
Татарстан Ельцинга толерантлылыгын ничек күрсәткән

24. Редакция кухнясы
Зилә Вәлиева: «Ашаган да белә, тураган да белә»

30. Казан – Истанбул – Казан
Төркиягә Казаннан беренче авиарейс

32. Кандагар вакыйгалары
Татарстан очучылары әсирлектән ничек качканнар

34. Яр Чаллыдагы фаҗига
Ни өчен КГБ журналистларга КАМАЗдагы янгын турында язарга рөхсәт итми

40. «Нишләп әле безгә концерт белән Казанга барып кайтмаска?»
Борис Гребенщиков беренче концертларын ничек оештырган

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

01.04

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Президенты, – эшкуарлык җәмәгатьчелегенә мөрәҗәгатендә:

– Коронавирус белән вазгыять шуны күрсәтте: безнең арада битараф булмаган кешеләр бик күп! Волонтерлар, эшкуарлар, артистлар, республикабызның гади халкы бер-берсенә ярдәм итәр өчен берләшә!

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

03.04

Сергей КОГОГИН, «КАМАЗ» ГАҖ генераль директоры, – автогигантның эшен яңарту турында карар кабул иткәннән соң:

– КАМАЗның эшләве коронавирус инфекциясенең таралуы белән бәйле вазгыятькә дөрес мөнәсәбәтне тәэмин итәргә, социаль хәлне тотрыклыландырырга, чикләүләр кертелү сәбәпле туган икътисадый кыенлыкларны җиңелрәк кичерергә мөмкинлек бирәчәк, ә иң мөһиме – илнең транспорт куркынычсызлыгын тәэмин итәчәк. Халык хуҗалыгына бик тә кирәкле «КАМАЗ» автотехникасын чыгару – компаниянең коронавирус белән көрәшкә керткән саллы өлеше ул.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

02.04

Динә ГАРИПОВА, җырчы, Татарстанның атказанган артисты, – «ВКонтакте» социаль челтәрендәге битендә:

– Теләсә кайсы вазгыятьтә иң мөһиме – күңел төшенкелегенә бирешмәү, иң мөһиме – яхшыга өметләнү! Безнең ил кыенлыкларны күп күрде. Аларны санавы да авыр… Бу вирусны да җиңәрбез! Бергәләп!

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

НИ ӨЧЕН кешелек дөньясы һәрвакыт вируслар белән көрәшә

Каты суны **НИЧЕК** йомшартырга

Авыл укытучысына **НИЧЕК** миллионер булырга

ФӘН ВИРУСНЫ ҖИҢӘ АЛАМЫ?

2019 елның декабрендә Кытайның Ухань шәһәрендә пневмониянең килеп чыгышы билгесез төре белән чирләүче беренче кеше табылды. Шуннан соңгы вазгыять һәркемгә мәгълүм. Безнең белән нәрсә булыр, өметсезлекнең кайсы чигенә барып җитәрбез – бу текстны язган вакытта җаваплар юк әле. Хәер, без файдалырак сорауга җавап эзләргә булдык: безнең Татарстан фәне үлемгә китерүче вируслар һөҗүмен туктатырга сәләтлеме?

Автор:
Ольга Туманская

ПАНДЕМИЯДӘН ВАКЦИНА

КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институтында танылган галим-вирусолог Альберт Ризванов яңа COVID-19 коронавирус инфекциясеннән вакцина табу юнәлешендә эшли. Юк, әлеге лабораториядә чын вирус юк – генетика кафедрасы профессоры аның санлы күчермәсеннән файдалана.

Күз алдына китерү катлаулы, әмма әлеге хезмәт менә нәрсәдән гыйбарәт: галимнәр электрон рәвештә кайбер вируслы геннарның генетик моделен төзи. Аннары ДНК химик рәвештә синтезлана һәм геннар инженериясе ярдәмендә вакцина ясала. Казан галимнәре тикшеренүенең үзенчәлеге шунда: әлеге вакцина нигезенә вирусның берьюлы берничә генының комбинациясе ята. Барлыкка килгән ДНК-вакцинаны организм күзәнәкләренә керткәндә, алар, яңа генетик мәгълүматны укып, вируслы аксымнар биосинтезын эшләтеп җибәрәчәк. Организм аларны чит дип кабул итәчәк һәм саклагыч иммунитет (антитәнчекләр һәм Т-күзәнәкләр) эшләп чыгара башлаячак. Бу вакытта вирус үзе ясалмаячак.

– Кайчанга көтәргә инде бу вакцинаны? – дип, бөтен кешене кызыксындырган соравымны бирергә ашыгам.

– Суворов кебек – сан белән түгел, осталык белән алдырмакчы булабыз, – ди Ризванов. – Без бу эшкә башкалардан соңрак керештек бит. Прототипны шактый тиз – май уртасына өлгертергә ниятлибез. ДНК-вакцинаны хайваннарда сынауга тагын бер-ике ай китәчәк. Ә менә аннан соң күп акча таләп ителәчәк – тере вируста сынауга һәм клиник тикшеренүләргә. Һәм бу озак вакытка сузылачак.

Ихтимал, укучыбызда сорау туар: бүген әзер булмагач, киләчәктә, бу коронавирус афәте тынгач, вакцинаның хаҗәте бармы соң? Моңа җавапны профессор Ризванов әллә ничә интервьюсында бирде инде: әгәр Казан галимнәре үзләренең вакцина булдыру юлының нәтиҗәле икәнен дәлилләсә, тагын пандемия килеп чыга калган очракта икенче вакцина табу вакыты бермә-бер кыскарачак.

Хәер, COVID-19 чире (аңа кадәрге дүрт кардәш-коронавирусы кебек үк) гадәти сезонлы авырулар сафында үз урынын алган очракта, коронавируска каршы Казан вакцинасының киң кулланылу ихтималы да бар. Мондый вакцинаның кулланылышы турында карарны галимнәр түгел, бәлки табиб-эпидемиологлар кабул итәчәк.

– Барысы да бу вирусның бездә ничек яшәвенә бәйле булачак. Шул ук грипп әйләнеп кайткан саен яңа штамм пәйда була – яңа вакцина эзләргә туры килә. Кешелекнең вируслар белән көрәше мәңге дәвам итә. Һәм әлегә бу көрәшнең азагы күренми.

КҮРӘЗӘЛӘР СИСТЕМАСЫ

Кичен Разиянең хәле начарлана, температурасы күтәрелә. Салкын тигәнме? Охшамаган. Кулында тиктомалдан карала башлаган кечкенә генә җәрәхәт тапкач, шиге тагын да көчәя. Тиздән исә куркыныч симптомнар аның Яшел Үзән районындагы туганында да табыла – күрше совхоздан сатып алынган итне алар икәү эшкәрткән була. 2016 елда Татарстанда түләмә кизүе шушы гап-гади көнкүреш вакыйгасыннан башлана…

Әйе, үлемгә китерүче йогышлы чирләр һөҗүме – безнең заманда чын була алмый, дип уйлау беркатлылыктыр. Өр-яңа тарихта эпидемияләр бик сирәк була, дип уйлау исә тагын да ялгышрак фикер. Юк, кешелеккә куркыныч вируслар һөҗүменә чынбарлыкта каршы торырга туры килә. 1918 елда тарихта иң куркыныч пандемия китереп чыгарган шул ук «испанка» безгә берничә тапкыр әйләнеп кайта, һәрвакыт бераз үзгәргән генә була. Шул ук H1N1 серотибының 2009 елдагы дуңгыз гриппы афәтен генә булса да искә төшерик. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы аңа иң югары – алтынчы дәрәҗә пандемия куркынычы бирәчәк – йогышлы чир ике йөздән артык илгә кагылачак… Мондый кизүләргә әзер тору өчен аларны алдан фаразлау мөмкинме? Тик Ванга



Фото: Александр Ефремов

белән Нострадамусның бүген социаль челтәрләрне тутырган күрәзәлекләренә генә таяна күрмәгез!

Алдан фаразлау, ә иң мөһиме, эпидемияләрне булдырмау өчен, нәтиҗәле мониторинг системасы кирәк. Һәм, сүз уңаенда, бездә ул бар. Альберт Ризванов аны террорчылыкка каршы көрәш белән чагыштыра: җинаять эшләнгәч, бу турыда бөтен кеше белә, ә менә булдырылмый калган уннарча һәм хәтта йөзләрчә теракт хакында беркем дә белми. Яңалыкларны укыганда, нигә терлек һәм кошларның барысын да шулай юкка чыгарырга кирәк икән соң дип аптырыйбыз. Ә бит шундый катгый чаралар күрелмәсә, башка мал-туар һәм кош-кортны саклап калу гына түгел, вирусларның мутациясеннән һәм кешегә йогуыннан котылып булмаячак. Якынча тикшеренүләр нәтиҗәсенә ышансак, Уханьда нәкъ менә шулай булган да бит.

Тормыштан мисал: 2016 елда Татарстанда африка дуңгыз чумасы таралмый кала. Эпидемиягә каршы чаралар республиканың сигез районына кагыла. Ул чакта да бик гади башлана хәтәр: Нурлат районы Сосновка авылындагы фермер хуҗалыгында бер дуңгыз чирли. Бәхеткә, хуҗасы тиз генә мал табибын чакырып дөрес эшли, ул куркыныч диагноз куя. Соңрак диагнозны Татарстан төбәкара ветеринария лабораториясе һәм Бөтенроссия ветеринар вирусология һәм микробиология фәнни-тикшеренү институты белгечләре дә раслый. Бөтен терлек юкка чыгарыла, карантин чорында катгый чаралар кертелә. Хайваннарны күчереп йөртүне, мал суюны, ит сатуны тыю – эшләнергә тиешле гамәлләрнең бик аз өлеше генә. Карап торышка, африка дуңгыз чумасы авыл хуҗалыгы өчен генә куркыныч чир кебек бит, пандемиянең монда ни катнашы бар соң? Менә сезгә соңгы мәгълүматлар: Хайваннар сәламәтлеген саклау федераль үзәге белгечләре африка дуңгыз чумасының кеше өчен куркыныч вируска әверелү ихтималын кире какмый.

Әйе, кешеләр сезонлы, шулай ук чума һәм ваба кебек башка куркыныч чирләрнең башлану вакытын фаразларга өйрәнгән инде. Ә менә эш моңарчы билгесез вируска кагылганда, алданрак нинди дә булса чара күреп буламы соң?

– Табигатьтә бүгенге коронавирус пайда булу ихтималын тикшеренүчеләр берничә ел элек үк фаразлаган иде, – дип сөйли Альберт Ризванов. – Әмма эш узгач акыл сатарга барысы да булдыра, чынбарлыкта исә галимнәргә килеп ирешкән күпсанлы сигналларны аңлавы артык катлаулы. Вакыт үтеп, авыр тәҗрибә туплангач кына, чыннан да нәтиҗәле күрәзәләр



Фото: Александр Ефремов

системасын төзеп булачак. Грипп (шул исәптән, дуңгыз һәм кош гриппы да) очрагындагы кебек. Вирусларның пандемия китереп чыгарырга сәләтле яңа генетик вариантлары пәйда булуны фаразлау тармагында фәннең дәрәҗәсен күтәрергә кирәк безгә. Менә шул вакытта без, чыннан да, бер адым алдарак булачакбыз. Әлегә исә бу бөтендөнья фәненең хәленнән килмәслек бурыч.

ФИЗИКЛАР – СӘЛАМӘТЛЕК САГЫНДА

Хәер, фән башка нәрсәгә өйрәнгән. Россия үзизоляция режимында яшәп яткан көннәрдә Казан физиклары аның тәмамлану вакытын фаразлый алган.

Аеруча оптимистик фаразны тудырган исәп-хисапларга тирәнтен кереп китмичә, һәркемне борчыган сорауга җавапны гына әйтик. «Авыруы ачыкланганнар саны артудан туктап, кимү ягына китү 9–14 апрельгә туры килергә тиеш, – дип фаразлый әлеге хезмәт авторлары. – Бу иң оптимистик сценарий буенча. Шуннан соң да чир йоктыручылар саны артмаса, бер атна-атна ярымнан карантин бетәргә тиеш, бу исә апрельнең 20 ләре, ягъни ай азагы булачак!»

Безнең физиклар бу исәпләүләргә үзизоляциядә ятып эчләре пошканга тотынган, дип уйлыйсызмы әллә? Юк шул. Эш шунда ки, КФУның Физика институтындагы исәпләү физикасы кафедрасында нәкъ менә шуңа охшаш бурычларны хәл итәргә тиешле юнәлеш – катлаулы системалар физикасы гамәлгә кертелә.

– Без, пандемия турындагы мәгълүматларны туплап, аеруча оптималь уңай фараз төзедек, – ди кафедра мө-

дире, физика-математика фәннәре докторы **Анатолий Мокшин**. – Эш шунда: фән бер урында гына тормый, төрле дисциплиналар чигендәге төрле юнәлешләр үстерелә. Физикада билгеле бер математика ысуллары бар, аларны бөтенләй физикага кагылмаган процессларга карата кулланып була. Мәсәлән, кардиограмма сигналларын тикшереп – инфаркт булачагын, Җир кабыгының тирбәлешләрен анализлап җир тетрәвен фаразлый алабыз. Башланган пандемиянең ничек узасын шактый тиз арада фаразларга мөмкинлек бирә торган җитди тәҗрибәбез дә бар безнең.

Скептиклар мондый мәсьәләләрне хәл итү – бөтенләй яңалык түгел, дип уйларга мөмкин. Эпидемияләрне фаразлау модельләре бар инде. Әмма эш шунда: бүгенге пандемия – үзгә, аның буенча җитди фаразлар юк диярлек. Ул яңа һәм өйрәнелмәгән, аның турында дөрес мәгълүмат аз. Хәтта авыруның инкубация чоры күпме булуы турында да бәхәсләр бара. Шунлыктан әлеге мәгълүм модельләргә нинди параметрлар кертергә соң? Биредә төрле-төрле, шул исәптән яңа алымнар да эшләп китәргә мөмкин, дип саный Анатолий Мокшин. Һәм хәтта мәгълүматларны гади анализлау һәм аларны статистика ягыннан эшкәртү генә дә эпидемияләр барышын фаразлау буенча әһәмиятле нәтиҗә бирергә сәләтле икән.

– Без пандемияләр буенча профессиональ белгеч түгел, әмма фәннәр чигендәге бу хезмәт – физикларның

вируска каршы көрәштә ярдәм итү омтылышы һәм кешеләрне тынычландырырлык дәлилле җаваплар эзләве, – ди Анатолий Мокшин.

Ихтимал, әлеге хезмәт пандемияләргә бәйле башка юнәлешләрдә дә чагылыш табар. Җәмгыятьнең нинди ихтыяҗы булачагын без әлегә белмибез. Әллә ничә төрле бурыч куелырга мөмкин, һәм физиклар кабат аларны хәл итү юлларын эзләргә тотыначак.

ТЕСТ КИРӘК!

Коронавируска анализ бирәсегез киләме? Массакүләм мәгълүмат чаралары, шул исәптән Татарстанныкылар да, хәбәр иткәнчә, тест үтү – үзе бер квест. Озак вакыт буе бу хәтта ватаннарына «куркыныч» илләрдән кайтучылар өчен дә башкара алмаслык диярлек бурыч булган.

– Эпидемияләргә каршы көрәштә сез нинди өч чараны мәҗбүри итәр идегез? – дип сорыйм профессор Ризвановтан. Һәм ул, уйлап та тормыйча, санап китә: карантин, гигиена, тест ярдәмендә эпидемиологик вазгыятьне мониторинглау. Аның коллегасы – хәзер Германия хөкүмәтенең яңа коронавирус инфекциясенә каршы көрәш буенча медицина консультанты, танылган вирусолог Кристиан Дростен үз иленең башлангыч этаптагы уңышларын нәкъ менә колачлы диагностика белән бәйли. «Без бик күп тест үткәрдек», – ди ул интервьюларыннан берсендә. Бу Германиягә кизүнең масштабын дөрес билгеләргә һәм пандемия һөҗүменә әзерләнү өчен вакыт отарга ярдәм иткән.

Рәсми статистикадан күренгәнчә, әлеге өлкәдә Россиянең дә мактанырлыгы бар. Беренче апрельдә премьер-министр Михаил Мишустин Россиянең яңа коронавирус инфекциясен ачыклау өчен үткәрелгән тестлар саны буенча лидер-илләр өчлегенә керүен белдерде. Ярты миллионнан артыграк тест ясалган. Әмма башка күрсәткеч тә бар шул – 10 мең кешегә туры килгән тестлар саны. Һәм менә монда без инде алдынгы түгел. Баштарак тестлар бары тик Роспотребнадзор лабораторияләрендә генә ясалган. Бәхеткә, 19 марттан әлеге эшкә тагын 193 медицина оешмасының лабораториясе кушыла алган.

Әмма бу гына аз, илгә аэропортларда ук күп кешене тиз арада тикшерү мөмкинлеге бирә торган экспресс-методлар кирәк, дип саный Альберт Ризванов. Мондый чара халыкара туристлык трафигын тестлар белән тулысынча тәэмин итәргә һәм вирус белән йогышланучыларны хәтта симптомнары беленмәгән стадиядә үк ачыкларга мөмкинлек бирәчәк.

– Асылда, моны нибары 30 минут эчендә эшләп була. Әмма, кызганыч, бүген Россиядә әлеге эшне алып барырга рөхсәт бирерлек законнар базасы юк. Тестлар бары тик патогенлыкның икенче төркем патогеннары белән эшләү лицензиясенә ия махсус лабораторияләрдә генә ясала. Һәм бу – архаизм. Мондый логистика һәм иске технологияләрдән файдалану тестлар үткәрүне шактый тоткарлауга китерә.

Галим ышандыруынча, вирусны танучы тестны шактый тиз арада эшләп була – әмма Россиядә әлеге тестны теркәгәндә кыенлыклар килеп чыгачагы бәхәссез. Тулаем алганда, кабат квестсыз булмый. Ә бит бүгенге вазгыять сөрән сала: безгә тест-системалар эшләү, теркәү һәм җитештерү процессының нәтиҗәлелеген арттырырга кирәк. Алар инфекция килеп чыгуның башлангыч этабында ук ихтыяҗны канәгатьләндерерлек күләмдә булырга тиеш.

Хәзерге вакытта КФУда Ризванов җитәкчелегендәге галимнәр командасы коронавирусны ачыклаучы экспресс-тест булдыру өстендә эшли. Ул кешедә коронавируска каршы антитәнчекләрнең булу-булмавын ачыклаячак, эш принцибы исә йөклелекне билгели торган тестныкы кебек, тик биоматериал булып кан тамчысы тора. Бер сызык – син сәламәт, ике сызык – син йогышлангансың яки инде авыргансың. Бу системаны авыруны башлангыч чорында диагностикалауда кулланып булмаячак, ул сизгеррәк ПЦР-тестларны алыштырмаячак, бәлки аларны тулыландырачак кына. Аның өстенлекләре – куллану гадилеге һәм бик тиз нәтиҗә ясау. Бу исә, үз чиратында, тиз арада карар кабул итү мөмкинлеген бирәчәк. Моннан тыш, тест инде моңарчы чирләгән һәм иммунитеты формалашкан (димәк, авыруны башка йоктырмаячак) кешеләрне ачыкларга булышачак, вакцина пәйда булгач исә аның нәтиҗәлелеген бәяләргә дә ярдәм итәчәк. Җитештерүне шулай ук Казанда җәелдерү планлаштырыла.

ДАРУ ЭЗЛӘГӘНДӘ…

Сүз уңаеннан, яманаты чыккан коронавирус хәзерге пандемиягә кадәр үк дөньяда шау-шу куптарып алган булган инде. Аның SARS-CoV төре 2002 елда көнчыгыш илләрендә кабынган эпидемиягә сәбәп булган. Тагын ун елдан соң «кардәше» MERS-CoV егермедән артык илгә таралган һәм үлем-китем дәрәҗәсе 30 проценттан арткан типик булмаган пневмония китереп чыгарган!

Россиягә әлеге эпидемияләр кагылмаса да, Казанда, КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институтындагы микробиология кафедрасында моңа бәйле рәвештә кабат тикшеренүләр үткәрелә башланган – ахыр чиктә аларның нәтиҗәләре коронавируслар китереп чыгара торган типик булмаган пневмонияләрне, шул исәптән бүгенге COVID-19 чирен дәвалауда да алга таба зур адым була алыр иде.

– Микроорганизмнарның ферментлары безнең кафедрада күптәннән инде тикшеренүләрнең төп темасы булып тора, – дип аңлата галим-микробиолог, КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты доценты **Павел Зеленихин**. – Без өйрәнә торган бик күп фермент арасында РНКны таркатучы ферментлар – рибонуклеазалар классы да бар. Алар күп төрле биологик үзлекләргә ия, шул исәптән вирусларга каршы тору үзлегенә дә.

Бик гадиләштереп әйткәндә, рибонуклеазаның генетик материалы РНКда булган вирусларга «һөҗүм итәргә» сәләтле. Коронавируслар семьялыгы – шундыйлардан. Мисал өчен, тилчә (ящур) вирусы да, котыру вирусы да шундыйлардан, кафедра галимнәре аларда рибонуклеазаларны сынап караган инде. Эш хәтта ветеринариядә зур тикшеренүләргә кадәр барып җиткән: рибонуклеазалар хайваннар белән үткәрелгән сынауларда вирусларга каршы яхшы активлык күрсәткән. MERS-CoV коронавируслары һәм аның сезонлы гриппны китереп чыгаручы көчсезрәк «кардәшләре» объект итеп алынган тикшеренүләр барышында да яхшы нәтиҗәгә ирешелгән. Билгеле, биредә модель системалары турында гына сүз бара – әлегә эш клиник сынауларга барып җитмәгән.

– Без, рибонуклеазалар авыруның барышын җиңеләйтергә, ягъни коронавирус йоктыручыларның савыгуын тизләтергә һәм үлем-китем дәрәҗәсен киметергә сәләтле, дип фаразлыйбыз, – ди Павел Зеленихин. – Әмма шул ук вакытта безнең ферментлар нигезендә ясалган препаратларыбызның кешеләр өчен дә нәтиҗәле һәм куркынычсыз булуына дәлилләребез фундаменталь, ягъни теориядә генә. Дару формасын уйлап табу һәм препаратны базарга чыгару бик күп акча таләп итә. Хәер, җәмәгатьчелектә безнең эшебез белән кызыксыну туса һәм финанслау җайланса, тикшеренүне дәвам итәргә дә була.

Кем белә бит, кешелекнең вирусларга каршы мәңгелек көрәшендә бәлки нәкъ менә шул кечкенә генә рибонуклеазаларга коткару чарасы булырга язгандыр? Чөнки, Павел Зеленихин әйтүенчә, фән безгә потенциаль мөмкинлекләр – глобаль бурыч һәм проблемаларны хәл итү өчен фундаменталь ачышлар әзерли бит. Һәм, ачыкланганча, бу эштә Татарстан галимнәренең урыны – алгы сафларда.

«ЧИСТА СУ» ЧИШМӘСЕ

«Экология» федераль программасы кысаларындагы «Чиста су» милли проекты 2024 елга республика халкының 95,54 % ын үзәкләштерелгән системалардан эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк. «Татарстан» программаның республикада бүген ничек гамәлгә кертелүе турында сөйли.

Автор:
Алсу Троицкая

Фото: Кадыйр Шакиров

– Безнең авылда су шундый начар – эмалендә зур ак таплар калдырганга, аның белән хәтта машинаны да юарга куркыта, – ди республиканың Балтач районы Чепья авыл җирлеге башлыгы Азат Нотфуллин. – Ә халык исә шул каты суны эчәргә мәҗбүр иде!

Су каты гына түгел, җирлекнең кайбер авылларында хәтта кызыл балчыклы да була. Мондый суны үзеңә эчәргә түгел, хәтта терлеккә эчертергә дә куркыныч. Шунлыктан эчәргә яраклы суны, һава торышының нинди булуына карамастан, чишмәләрдән ташырга туры килә… Ә менә үз йортындагы чиста сулы сууткәргеч турындагы хыялның чыннан да тормышка аша алуына чепьялеләр 2014 елда ышана. Ул чакта милли проект әле башланмаган була, әмма инде республика халкын эчәргә яраклы су белән тәэмин итү программасы һәм 2011–2017 нче елларга тәгаенләнгән «Чиста су» федераль максатчан программмасы ул чакта ук тулы куәтенә эшли башлый…

ИҢ МӨҺИМЕ – БАШЛАУ

«Чиста су» милли проекты актуаль генә түгел, бәлки зарури да: чөнки һәр бишенче авыру начар сыйфатлы суга бәйле булырга мөмкин. Проектның финанс өлеше ачык һәм аңлаешлы: 81%ы – федераль, 19% ы– республика бюджетыннан. Милли проектта катнашып, Татарстан үз алдына 2024 елга кадәр республика халкының 95,54 %ын үзәкләштерелгән системалардан эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү максатын куя. Бу бик зур бурыч: су белән тәэмин итү объектлары һәм челтәрләренең тузуы 60,5 % дәрәҗәсендә дип бәяләнә. Төбәк программасын гамәлгә кертүгә миллиард сумнан артыграк акча бүленгән.

Азат Нотфуллин әйтүенчә, Чепья авыл җирлеге өчен иң катлаулы һәм авыр чор әлеге эшне башлап җибәрү була.

– Иң мөһиме – милли проектка эләгү иде. Җирләрне инвентарьләштерү һәм экспертиза үткәрү, проектлаштыру, подрядчыларны эзләп табу… Аннары инде башлыйсы гына кала. Әмма, дөресен әйтергә кирәк, проектлаштыру эшләрен башкару өчен Балтач районы башлыгы җирле бюджеттан финанс ярдәме алырга булышмаса, мөгаен, без «Чиста су» милли проектына эләгә алмас идек.

ТӘҖРИБӘНЕҢ КАБАТЛАНУЫ ЯХШЫ

Республиканың экология һәм табигый байлыклар министры Александр Шадриков әйтүенчә, 2019 елда Татарстанда әйләнә-тирә мохитне саклау чараларына 9 миллиард сумнан артыграк акча бүленгән. Аеруча зур финанслау «Иделне савыктыру», «Урманнарны саклау» һәм «Чиста су» федераль проектларына кагылган. Аларны гамәлгә кертү өчен федераль бюджеттан 1,65 миллиард сум акча алынган. 2021 елга экологик федераль проектлар санын алтыга җиткерү планлаштырыла.

Милли проектларны формалаштыру техникасы 2019 елда зур сынау узар, дип гөманлаган идек. Хәзерге бурыч – булган тәҗрибәне исәпкә алып, бүленгән акчаны мөмкин кадәр нәтиҗәле тоту. Чепья авыл җирлегендә әлеге җәһәттән җитди тәҗрибә тупланган. Андагы җиде торак пунктта өч меңгә якын кеше яши. Башта сүүткәргечне Янгырчы авылында алыштыралар, аннары, инде үзара салым механизмыннан файдаланып, тагын биш торак пунктка чиста су кертәләр.

Бүген Тагашур авылы халкын сыйфатлы су белән тәэмин итү бурычы куелган, моны 2021 елда башкарып чыгарга планлаштырылалар. Хәзер исә Арбор авылында яңа сүүткәргеч салынып ята. Сүүткәргечнең ике чакрымы сузылган инде, тагын бер чакрым сузасы гына калган. Эшне тәгәлләү өчен кирәкле бөтен нәрсә – гидрантлар, полиэтилен торбалар, фильтрлар сатып алынган... Авыл җирлеге идарәсендә безне ышандыруларынча, техника белән дә проблема юк. Инде бүген үк Арбордагы ике йөзләп йортта краннан саф артезиан суы ага.

Чепья авыл җирлегендәге җиде торак пунктта өч меңгә якын кеше яши. Аларның һәркайсы чиста су белән тәэмин ителәчәк.

ПРОЕКТ БАР ИКӘН – ЧИСТА СУ ДА БУЛАЧАК

Бүген акчаны сорап алу һәм тоту җиңел түгел, бөтен нәрсәне төгәл дәлилләп күрсәтергә кирәк. «Чиста су» милли проектында катнашу өчен проект-смета документациясен әзерләү мәҗбүри. Бу арзан түгел һәм барлык авыл җирлекләренең дә хәленнән килми, дип саный ТР Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлеге башлыгы Ирина Тихонова.

– Безнең җирлектәге өч торак пункт – Льяшево, Олы Бисәр һәм Ямбактыда нибары 275 кеше яши. Проект-смета документациясен әзерләү һәм экспертиза үткәрү өчен кирәкле 700–800 мең сум акчаны без хәтта үзара салым ярдәмендә дә җыя алмыйбыз, безнең өчен бу артык зур сумма, – ди ул. – Ә су бик кирәк – күптән түгел Льяшевоның ике урамында халык өч атна буе сусыз тилмерде. Сүүткәргеч шулкадәр иске ки, аны үз көчебез белән ел буе ямаудан башыбыз чыкмый. Җирле «Маяк» предприятиесе аграрийларына рәхмәт әле. Алар техника һәм запас частьлар белән булыша. Ямбакты авылында сүүткәргеч бөтенләй юк, коелар гына, аларда су исә шулкадәр каты, кер не дә агартып булмый... Шунлыктан без «Чиста су» милли проектында катнашучыларга көнләшеп һәм кызыгып карыйбыз. Бу – авыл халкын эчәргә

яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү өчен менә дигән мөмкинлек.

Ә менә аларның күршеләре, Олы Шәмәк авылы халкы, үз дигәненә ирешкән. Гәрчә алардагы биш торак пунктның икесендә бик аз кеше яшәсә дә – мәсәлән, «Победа» бистәсендә нибары алты кеше гомер сөрә. Олы Шәмәк авыл җирлеге башлыгы Алексей Афанасьев әйтүенчә, кечкенә авыллар өчен бер генә юл бар:

– Без өч ел дәвамында үзара салымнан кергән акчаның төп өлешен проект төзету һәм дәүләт экспертизасы уткәрүгә дип җыеп бардык. Кирәкле акчаны – 800 мең сумга якын – шул рәвешле тупладык. Бүген без «Чиста су» программасында катнашу чиратында районда өченче булып торабыз.

БҮЛӘККӘ – СУҮТКӘРГЕЧ

«Чиста су» программасын гамәлгә кертү башланган иң беренче авылларның берсе – Татарстанның Чирмешән районындагы кечкенә генә Андреевка авылы. Биредә нибары бер урам, янәшәдә эчәргә яраклы чиста су алырлык чишмәләр бөтенләй юк.

77 яшьлек Мария Сидорова Андреевкага 1962 елда, кияүгә чыккач, күчеп килгән. Ул чакта авылда суүткәргеч бөтенләй булмаган, суны коедан ташыганнар, 1970 елда суүткәргеч сузылгач, халык бик сөенгән. Әмма йортларга сузылган металл торбалар ярты гасыр эчендә тузып беткән шул инде.

Бүген авылга яңа суүткәргеч сузу өчен кирәкле кое боҗраларын китерә башлаганнар, тиздән полиэтилен торбалар да кайтартылачак. Суүткәргеч төзү чыгымнарын, проект-смета документациясен әзерләү һәм экспертиза үткәрүне дә кертеп, дәүләт тулысынча үз өстенә алган.

– Хәзер без ирем белән икәү генә яшибез, алты балабызның берсе дә янибызда калмады. Билгеле, су беткәндә, бик авыр, беркемгә дә мөрәҗәгать итә алмыйбыз, – ди Мария Сидорова. – Әгәр быел яңа линия сузсалар, бу иремә бик шәп бүләк булыр иде – көзгә аңа 80 яшь тула…

АВЫЛГА ДА, ШӘҺӘРГӘ ДӘ

Төбәк программасы бурычларыннан берсе – 2024 елга кадәр шәһәр халкының 98,98%ын эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тәэмин итү.

– Программаны гамәлгә кертү нәтиҗәләреннән рәхәт күрүчеләр арасында – Болгар халкы, – ди Татарстан Республикасы Газлаштыру фонды каршындагы Инженерлык челтәрләрен капиталь төзү һәм энергияне саклаучы технологияләрне үстерү идарәсе баш инженеры Дмитрий Вильгельмский. – Былтыр анда суалгыч реконструкцияләнде. Хәзер 8,5 меңгә якын кеше эчәргә яраклы сыйфатлы су белән тулысынча тәэмин ителгән. «Чиста су» программасы буенча 2024 елга кадәр без Алексеевский, Нурлат районнарында, Осиново һәм Васильево бистәләрендә шундый ук эшләрне башкаруны планлаштырабыз.

P.S. Пандемия һәм икътисадый кризис китереп чыгарган үзгәрешләр урынлы сорау тудыра: бу негатив процесслар бик мөһим милли проектны гамәлгә кертүгә комачауламасмы икән? Россия Табигый байлыклар һәм экология министрлыгы башлыгы Дмитрий Кобылкин әйтүенчә, әлеге бик җитди сәбәпләр «Экология» милли проекты бурычларын тормышка ашыруга комачауламасын өчен, мөмкин булганның барысы да эшләнәчәк. Нинди дер төзәтмәләр кертелү ихтималы да бар икән. Әмма, тулаем алганда, «бернинди проектлар да туктатылмый һәм киләчәккә күчерелми».

Фото: Александр Ефремов

АВЫЛ УКЫТУЧЫСЫНА НИЧЕК **МИЛЛИОНЕР БУЛЫРГА?**

Соңгы елларда Татарстанда оптимальләштерү нәтиҗәсендә авыл мәктәпләре күзгә күренеп азайды, сала укытучылары арасында кадрлар җитешмәү исә һаман да проблема булып кала бирә. «Земский учитель» федераль программасы бу хәлне төзәтергә тиеш. Татарстанның мәгариф һәм фән министры Рафис Тимерхан улы Борһанов «Татарстан» журналына республикада гамәлгә кертелгән әлеге программаның үзенчәлекләре һәм аннан көтелгән нәтиҗәләр турында сөйләде.

Текст:
Арина Ваничкина

– Рафис Тимерханович, Татарстан авыллары мәктәпләрендә күбесенчә нинди укытучылар җитми?

– Безнең авыл мәктәпләрендә математика һәм физика, рус теле һәм әдәбияты, шулай ук инглиз теле укытучылары җитми. Күп кенә мәктәпләрдә башлангыч сыйныф укытучыларына да кытлык бар.

– Татарстанда «Земский учитель» программасының нинди дә булса үзенчәлекләре бармы? Авыл җирлегенә эшкә киткән барлык укытучыларга да бер миллион сум акча биреләчәкме, әллә бу акчаны алу өчен ниндидер чикләүләр каралганмы?

– Татарстанда әлеге программада катнашу өчен, 55 яшькә кадәрге, урта һөнәри яки югары белемле укытучылар гариза бирә ала. Алар конкурс нигезендә сайлап алыначак, аның нәтиҗәләре буенча 2020 елда 13 җиңүче билгеләнәчәк. Менә шул мөгаллимнәр миллион сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация алачак. Программа 2022 елга кадәр эшләячәк һәм ул гамәлдә булган вакыт эчендә 34 җиңүчегә шундый ярдәм күрсәтү каралган.

– Яшь белгеч үз миллионын нәрсәгә тотарга хокуклы?

– Үзе кирәк дип санаган максатта. Кагыйдә буларак, бу акчаларны торак мәсьәләсен хәл итү өчен тоталар – муниципалитетларда мондый суммага уңайлы фатир яки йорт сатып алырга мөмкин. Яки шул акча белән ипотека өчен беренче кертемне ясап була.

Акча хезмәт срогы башында бирелә. Җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, укытучы мәктәп белән биш елга хезмәт килешүе һәм бер тапкыр бирелә торган компенсация турында килешү төзергә тиеш. Ләкин кеше килешүдә билгеләнгән биш елын эшләмәсә, акча кире кайтарылырга тиеш.

Миллион сум – яшь белгеч өчен саллы ярдәм, дип саныйм, шул рәвешле без авыл җирендә мәктәпләрне саклап кала алачакбыз. Чөнки педагоглар булмау балаларның район үзәкләренә тартылуына, ә аннары зур шәһәрләргә юл тотуына китерә.

Яшьләр авылда калырга теләсен өчен, без алар өчен шартлар тудырырга тиеш. Мондый шартлар хәзер илкүләм проектлар, президент программалары ярдәмендә булдырыла: юллар, клублар, мәктәпләр, китапханәләр төзелә һәм ремонтлана – болар барысы да авылларда яшәү уңайлы булсын өчен эшләнә. Шуңа күрә матди-техник базаны ныгытуга яки укытучыларның хезмәт хакын арттыруга юнәлтелгән теләсә нинди яңа программаның барлыкка килүе – минем өчен зур шатлык. Төзекләндерелгән һәр мәктәп тә, һәр сатып алынган яңа җиһазлар комплекты да – сөенеч. Авыл мәктәпләренә барып җиткән илкүләм проектлардан без «Һәр баланың уңышы» программасы буенча икешәр-өчәр информатика һәм технология сыйныфы җиһазладык. Шулай да мин әйтә килам: мәктәп – мода белән бизәлгән диварлар түгел ул, ә белем алу, күпкырлы үсеш, дуслык, үзара ярдәмләшү дигән сүз. Ләкин мондый заманча мәктәпләрдә уку һәм укыту, белем алу һәм дуслар табу күпкә кызыграк икәнлеге белән дә килешәм.

– Укытучылык эше өчен авылны сайларга теләүчеләр күбрәк булыр да алар, субсидияне ала алмыйча, күңелләре кайтып, ул авылларны ташлап китәр дигән куркыныч юкмы?

– Мондый хәл була калса, президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миңнеханов тиешле чаралар күрер, дип уйлыйм. Бу программада катнашырга теләк белдерүчеләрнең күбрәк булуын телибез. Сала кешеләре өчен уңайлылык һәм кулай шартлар тудыруга юнәлдерелгән барлык авыл программалары белем бирүче мөгаллимнәр генә түгел, аларның укытыр кешеләре дә булсын дигән максатны күздә тотып гамәлгә ашырыла. Моннан тыш, Татарстанның күп кенә районнарында укытучыларга муниципалитетлардан да өстәмә түләүләр каралган.

– Конкурста бары тик педагогик белемгә ия кеше генә катнаша аламы? Әйтик, математик белем алган затның андый мөмкинлеге юкмы?

– Бар. «Педагогика» юнәлеше буенча һөнәри әзерлек узу турында дипломы булган очракта. «Яңа укытучыбыз» грантын гамәлгә ашырганда, андый тәҗрибәбез булды. Педагогик юнәлешне күздә тотмаган югары уку йортларын тәмамлап, мәктәпләрдә укытучы булып эшләргә теләге зур егетләр һәм кызлар конкурста катнашты, грант отучыларны эшкә алдылар һәм шул ук вакытта педагогика нигезләрен үзләштерү өчен укырга җибәрделәр. Алар искиткеч шәп укытучылар булды.

– Декрет ялы килешүдә каралган биш еллык стажга керәме?

– Бала карау өчен бирелә торган ял бу стажга керми, дөрес, мин моның белән килешеп бетмим. Чөнки бала табарга теләгән хатын-кызга без барлык шарт-

Фото: Александр Ефремов

ларны тудырырга тиеш: «Демография» илкүләм проекты, Россия Президенты һәм Татарстан Президенты юлламалары кушканча да. Шуны аңларга кирәк: безнеке кебек зур ил өчен, икътисадыбыз да, халык хуҗалыгы да тиешенчә эшләсен өчен, ким дигәндә, ике тапкыр күбрәк халык кирәк. Минемчә, без бала табарга яки сабыйларны уллыкка-кызлыкка алырга теләгән хатын-кызларга ничек тә булышырга тиеш.

– Бу программа буенча эшләгән вакытта укытучыга читтән торып югары белем алырга ярыймы? Яки икенче югары белем?

– Әлбәттә. Бу – Россия Федерациясе Хезмәт кодексында да каралган. Югары белем алганда, укытучы кешегә эш бирүче оешма, урта хезмәт хакын саклап калган хәлдә, сессия вакыты өчен өстәмә ял бирә.

– «Земский учитель» программасыннан нинди нәтиҗә көтәсез?

– Төп өмет, әлбәттә, яшь белгечләрнең авыл мәктәпләрендә төпләнеп калуы. Ә авыл мәктәпләрен кадрлар белән тиешенчә тәэмин итү нәтиҗәсендә салада укыту методларын камилләштерүгә дә, белем бирү мөмкинлекләрен киңәйтүгә дә, сыйфатлы бушлай белем алу өчен һәркемгә җай тудыруга да, шулай ук авыл мәктәпләрендә уку-укытуның сыйфатын күтәрүгә дә юл ачылачак.

– Яшь белгеч авылга кайтсын өчен, мондый эшне күпме вакыт дәвамында алып барырга кирәк?

– Мондый тәҗрибә һәрвакыт булырга тиеш. Егермебишмеңчеләр турындагы тарихны искә төшерегез әле. Ул вакытта мәктәпнең өч кенә сыйныфын булса да тәмамлаган эшчеләрне шәһәрдән авылга балалар укыту өчен җибәргәннәр. Нинди дә булса кызыксындыру чаралары – грантлар, конкурслар, төрле ярдәм күрсәтү кебек ысулларга хәзер дә вакыт-вакыт әйләнеп кайтырга кирәк.

Ел саен 12 меңгә якын кеше педагогик белем алу процессын дәвам итә. Әмма, ни кызганыч, аларның күбесе педагогика өлкәсендәге эш урынына барып җитми. Шуңа күрә үз вакытында без педагогик белем алган һәм кайдадыр бизнеслары булган затлар – инде йортын да салган, машина да сатып алган, үз бизнесыннан арырга да өлгереп, яраткан эш белән шөгыльләнергә теләгән 40–45 яшьлек кешеләрне дә чакырып карадык. Без аларны яңадан укытып чыгарырга һәм мәктәпләргә җибәрергә әзер идек. Тик, кызганыч, берничә елна сузылган тәнәфестән соң, кешегә кабат сыйныф бүлмәсе ишеген ачып керү шактый кыен. Моннан 20 ел элек булган сыйныф белән хәзергесе бик нык аерыла. Бу заманда үз фәнеңнән генә түгел, ә барлык юнәлешләр буенча да яхшы әзерлекле булырга кирәк. Балалар бүген бик хәрәкәтчән, күп белүчән һәм алдынгы карашлы. Мондый алга киткән укучы каршында абруй казана белү зарур. Ә бу төр сәләт, әлбәттә, һәркемгә дә бирелмәгән. Кайчагында моңа тәҗрибә белән ирешәсең. Баштагы мәлдә балалар белән уртак тел табып булмаска да мөмкин...

– Балалар, нигездә, яшь укытучыларны, яңа укытучыларны ярата...

– Әлбәттә, яраталар. Ә ни өчен? Чөнки аларны мыскыллап, кимсетеп була. Үземнән хәтерлим, мин дә бит Арчада авыл мәктәбендә укыдым. Төрле хәлләр булды, хәзер шуның өчен оят та әле. Үз укытучыларыма рәхмәт сүзләре генә әйтә алам. Тик кайчагында яшүсмерлек максимализмы аркасында, коллективта аерылып тору теләге белән, укытучылар өчен бик кимсеткеч гамәлләр дә кылып ташлый идек... Акланыр өчен бердәнбер нигез – без моны явызлыктан эшләмәдек, бүген үз гамәлләребезнең дөрес булмаганлыгын аңлыйбыз һәм үкенәбез.

Бездә өлкән балалар сыйныфы да бар иде. Гаиләләрдә берничә бала булган вакытлар, алар бер үк мәктәптә бербер артлы укый. Кайчагында укытучылар кече яшьтәгеләрнең тәртибе өчен эти-әниләренә түгел, ә өлкәнрәк абый-апаларына зарлана. Ул чакта укытучының абруе бөтенләй башка иде. Мин башкарма комитет рәисенең улы идем, әгәр син нindидер түрә кешенең улы икән, җаваплылык икеләтә арта, бер дә хәзерге кебек түгел. Теләсә кайсы укытучы әтинең кабинетына кереп, синең ни майтарганың турында сөйли ала. Тик алар, безне кызганып, андый юлга бармады. Безнең мәктәптә яшь укытучылар бик күп иде. Әйтик, математика укытучысы Нина Степановна Демьянова, институтны тәмамлау белән мәктәпкә килеп, безне дүртенче сыйныфта кабул итте һәм чыгарылышка кадәр илтеп җиткерде.

– Хезмәт юлына яңа аяк баскан яшь авыл укытучыларына нинди теләкләрегезне ирештерер идегез?

– Табиблар Гиппократ анты бирә. Укытучы да ант итәргә тиеш: үз һөнәренә тугрылык саклау турында – аңа хыянәт хакында уй башка да килеп карамасын; укучыларга карата мәхәббәт турында – яратканнары да, өнәп бетермәгәннәре дә сезнең мөнәсәбәттәге аерманы сизмәсен өчен; белем бирү эшендә әдәплелек, тәртип турында – сезнең һәм үзенең матди хәленә карамастан, һәр укучы белем алу мөмкинлегенә ия булсын өчен.

Һөнәр сайлаганда, кеше кайда укытачагын, нинди кыенлыклар белән очрашачагын бик үк уйлап та бетермидер,

«Татар-информ» МА фотосы

мөгаен. Үз һөнәреңә карата мәхәббәткә нәкъ менә беренче биш-алты елда нигез салына, ә аннары, яхшы укытучы булсаң, балаларың да китәргә ирек бирмәячәк, җибәрмәячәкләр. Балалар күркәм укытучыга тартыла, яхшы педагогны бернинди гаджет та алыштыра алмый. Чөнки бары тик тере кеше, белемле укытучы гына укучыларда теге яки бу фәнгә омтылышны, нинди дә булса сәләтне күрә һәм үстерә, шәхеснең көчле якларын ныгыта, җитешмәгән сыйфатларны үстереп җибәрә ала. Мөгаллимнең артта кала торган укучы белән шөгыльләнеп, 8–9 нчы сыйныфка аның сәләтләрен, талантларын ачып җибәрүе, нәтиҗәдә ул укучының ачылып китеп, алдынгылар рәтенә керүе – мондый очракларның минем күз алдында булганы бар.

«ЗЕМСКИЙ УЧИТЕЛЬ» ПРОГРАММАСЫНЫҢ БАРЛЫК ШАРТЛАРЫ,
ШУЛ ИСӘПТӘН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДАГЫЛАРЫ БЕЛӘН ДӘ, МОНДА ТАНЫША АЛАСЫЗ:

1. «Земский учитель» Бөтенроссия мәгълүмат порталында – **zemteacher.edu.ru.**
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтының **(mon.tatarstan.ru)** «Эшчәнлек» бүлегендә – «Программалар, проектлар һәм чаралар» бүлекчәсе – «Земский учитель» программасы.
3. «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе сайтында – **www.irort.ru.**

Яшь укытучыларга үзеңне камилләштерү, үз предметыңны укытуда осталыкны арттыру юнәлешендә даими эшләргә һәм мәктәптә белем бирүнең ике өлештән – укыту һәм тәрбиядән торуын һәм аларның бертигез дәрәҗәдә мөһим икәнлеген онытмаска киңәш итәм. Тәрбия бирмичә генә укытырга ярамый, шул ук вакытта уку-укытусыз гына тәрбияләп тә булмый. Безгә белемле була торып та әдәпсез, рухи кыйбласы бозык укучылар кирәк түгел. Җәмгыятебезгә өлкәннәр турында да кайгырта белгән, бер-берсенә ярдәм кулы сузарга әзер торган кешеләр таләп ителә. Мин үзебезнең мәктәптә көчлерәк укучыларның арттарак баручылар белән шөгыльләнүен искә алам, һәм бу һәрвакыт нормаль күренеш саналды, нindiдер гайре табигый эш дип кабул ителмәде. Укучыларның аерым фәннәрдән белгеләрен генә яхшыртып калмыйча, төрле яклап үстерергә ярдәм иткән факультативлар, класстан тыш дәресләр дә күп иде. Укытучылар безнең белән шөгыльләнергә иренмәде, балалар бакчасыннан башлап, чыгарылыш сыйныфка кадәр мөгаллимнәремнән уңдым мин. Балалар бакчасында укыткан барлык укытучыларымны, тәрбиячеләрне һәм хәзер инде мәрхүмә пешекче Маруся апаны – барысын да хәтерлим, тулы исем-фамилияләрен әйтеп бирә алам. Маруся апаның вафат булуына 50 ел инде, андый кешеләрне шулкадәр озак хәтердә тотар өчен, алар сиңа нindiдер онытылмаслык игелек эшләргә, үрнәк күрсәтергә, күңелеңә кереп калырга тиеш. Бернинди ятлату, көчләп укыттыру белән генә моңа ирешә алмыйсың. Бу кешеләр безгә бар күңелен, йөрәген, яшьлекләрен бирде. Сыйныф җитәкчебез Галина Николаевна әнә шулай безне кайгыртып, кияүгә дә чыкмады, көн-төн укучылары белән шөгыльләнде, шәхси тормышына вакыты да калмады... Әлбәттә, бу күптән булган хәлләр инде – әле совет мәктәбендә...

– Укучылар һәм укытучы арасында мондый мөнәсәбәтләр, сезнеңчә, берәр кайда калды микән әле?

– Бездә, Татарстанда, авыл педагогик культурасы һәм тәрбиясенең хәзинәләрен Азнакайда һәм Сарманда күреп була. Хәер, ераккарак киткән саен шулкадәр күбрәк сакланып калган ул – Мөслимдә, Актанышта... Анда укытучы-укучы арасында үрнәк мөнәсәбәтләргә мисаллар бар. Шуңа күрә безнең бурыч бу процесста ике зат – укытучы белән һәм укучыны күзгә-күз калдырудан гыйбарәт, ә калганнар – уку-укыту буенча урынбасардан, мәктәп директорыннан алып мәгариф министрына һәм президентка кадәр – кирәкле шартларны тудырырга тиеш. Чөнки ни дисәң дә, монда иң мөһиме – укытучы, ул – милли проект, икътисадның төп герое. Тормышның иң башында, балачакта, укытучы балада нинди күнекмәләрне үстереп җибәрә, без аннары шундый белгеч һәм шәхес алачакбыз дигән сүз. Йә ул кешедән башы шәп эшли торган оста килеп чыга – бу инде, нинди генә булмасын, фәнни-техникмы, гуманитармы, социальме – алга бару, прогресс дигән сүз. Йә инде уртакул кеше генә укып чыгачак, андыйлар исә икътисадның бүгенге халәтен тотып торырга ярдәм итә алачак. Ә дөнья бик тиз үзгәрә бит, аның артыннан өлгереп барырга кирәк.

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
Подписка!
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Туй күлмәкләре модасы
70 нче елларда кияү-кәләшләр нинди булганнар
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
19 марта 2020
18 марта 2020
Табиевны ни өчен Әфганстанга илче итеп билгеләгәннәр
Хәрби чор дипломатиясе
Идел буе кораб урманнары: тарихи экскурс
Тарих сәхифәләре
Бары күләгәдән генә чыгасы!
Реклама 16+

Игелекле эшләр

Б У С А Н Д А
Т Ә К Ъ Д И М И Т Ә Б Е З :

«Ияләр» **КАЙДА** яши

Арча госпиталендә **КЕМНӘРНЕ** дәвалаганнар

Немец әсирләрен **КЕМ** Мәскәүгә кадәр озата барган

1812 елгы сугыш Казан губернасында **НИНДИ** эз калдырган





ЯЗМЫШ БАГАНАСЫ

Автор: Мөршидә Кыямова

Рәссам, сынчы, монументалист Әхсән Фәтхетдинов рәсем дөньясында үз юлын, үз стилен тапкан оста. Фольклор һәм мифологиягә нигезләнеп иҗат итүе, шигърияткә мәхәббәте, яшәешкә карата тирән мөстәкыйль фикергә ия булуы аны кабатланмас сәнгатькәр итеп танытты. Аның иҗатын башкаларныкы белән бутый алмыйсың. Бу бик бәхетле иҗатчылар өлешенә генә тигән мәртәбә.

Фотолар Әхсән Фәтхетдиновнең шәхси архивыннан алынды; Александр Ефремов

ФӘЛСӘФӘЧЕ РӘССАМ

Әхсән Фәтхетдиновны милли тамырлар, татар рухы һәрвакыт дулкынландырып, үзенә ымсындырып торган, күрәсең. Түбән Тагил пединститутын тәмамлаганнан соң шунда ук рәсем сәнгате кафедрасында укытучы булып эшләгән 30 яшьлек рәссам Татарстанга кайтып төпләнә һәм Түбән Кама каласында яшәп иҗат итә башлый, фольклор материалларына нигезләнгән әсәрләрен халыкка таныта. Сәнгатьнең бу өлкәсе зур талант, уңганлык, сабырлык һәм үзенчәлекле фикерләү таләп итә, шуңа күрә Әхсән Фәтхетдиновның иҗаты башкаларныкыннан үзгә. Аны без «фәлсәфәче рәссам» дибез.

«Рәссам булу сезгә кайдан килгән, дип сорыйлар кайчак. Миңа тормыш бүләк иткән эти белән әнидән, дип җавап бирәм. Эш сөюем, тырышлыгым – бу дөньядан бик иртә киткән әнием Мәгъмурәдән, ә рәсем ясау сәләте – урманчы, умартачы, балта остасы, бакчачы һәм башка бик күп һөнәрләргә ия әтием Сарыймнан», – дип яза Әхсән Фәтхетдинов автобиографиясендә.

«Рәсем ясаучы», «Ияләр иясе», «Җеннәр ясаучы рәссам» – бу исемнәрне Түбән Кама халкы Әхсән Фәтхетдиновка яратып, үз итеп таккан. «Ап-ак чәчләре һәрдаим халык арасыннан күренеп-күренеп китә иде. Чалбарына кыстырылмаган ак күлмәге милләтебезнең аклыгын билгеле торган төс. Шул ак төсләр аркылы ул чиста күңел көрлеге белән иҗат итте», – ди аның хакында шәһәрдәшләре. 2016 елда Түбән Камада Әхсән Фәтхетдиновның музей-йорты оештырылды. Биредә аның иҗаты, фәлсәфәсе белән якыннан танышырга мөмкин.

Рәссамның беренче эшләре – шәһәр һәм авыл пейзажлары, төрле натюрмортлар, портретлар. Ул теге йә бу темага багышланган серияләр иҗат итә. Шундыйларның беренчесе – «Шүрәле» циклы – 50дән артык агач сынны үз эченә ала. Аның икенче сериясе 10 картинадан гыйбарәт. Алар «Тукай шигырьләре», «Халык шагыйре», «Тукай кабере» һ.б. дип исемләнгән. Халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигырьләренә таянып иҗат ителгән «Татар зираты» рельефлы сыннар төркеме татар халкының кире кайтмас югалтулары һәм газаплары өчен тирән борчылу хисләре белән сугарылган. «Үксегән чаклары да, иҗат һәм шатлыгыннан күк катларына менәрлек үсенгән чаклары да булгандыр. Һәрхәлдә, бүгенге милли сынлы сәнгатебезнең асыл бер өлешен тәшкил иткән әсәрләрне шушы шәһәрдә иҗат итте Әхсән», – ди аның хакында шагыйрь дусты.

Әхсән Фәтхетдинов Равил Фәйзуллин белән еш аралашып яшәгән. Күрешми торганда кылкаләм остасы үзенең шагыйрь дустына хатлар язган. Ул хатларда фәлсәфәче рәссамның күңелен сыкраткан, киндергә төшми калган уй-кичерешләре, милләт, сәнгать турындагы уйланулары «түгелгән». Әлеге хатларны ул, Казанга килгәч, адресатының үз кулына тапшыра торган була, чөнки хатларның күләме амбар кенәгәсе чаклы – машинкада 70–80 биткә җиткәннәре бар. Андый хатлар Равил Фәйзуллинда кырыклап саклана.

«... Күптәннән бирле күрешкән, сөйләшкән юк бит. Ул инде синең Тукай бәйрәменә килүеңне сизеп, сагынып көткәнгәдер, синең янда минем бит күңелем нечкәрә. Шуның өчен дә хатларымны да сиңа гына язам. Минем башка язмаларым да юк. Бер генә үтенечем бар: син аларны сакла әле. Еллар узгач, синең янга килеп шуларны укып утырырмын. Үткәннәрне искә төшерермен. Әгәр инде сиңа бик кирәк димәсәң, бер килүдә алып та китәрмен. Бары тик кешегә йөк кенә буласым килми...
21 июнь, 1986 ел».

Рәссамның 50 эштән торган «Ияләр» циклы халык тарафыннан аеруча яратып кабул ителде. Ул татар сәнгате тарихында беренче тапкыр мәдәниятебезнең мәҗүсилек чорына мөрәҗәгать итте. «Ияләр» – халык авыз иҗатына юнәлдерелгән. Автор раславынча, аларның төбендә фани дөньяда һәрнәрсәнең иясе, сакчысы һәм хуҗасы бар дигән фикер чагылыш тапкан. Сынчының «Ияләрен» карап, хәтта дәвалануычылар да бар икән.

«Иҗат иткәндә минем йөрәгем дулкынлана. Хисләр дөньясына чумам. Мин тыныч күңел белән бернәрсә дә ясый алмыйм. Менә шушы күңел дулкыннары кайчагында тамашачыга да барып җитә торгандыр. Кешене уйланырга мәҗбүр итә алсам, мин бәхетле», – дигән иде сынчы-рәссам шәхсән үземә бер әңгәмә вакытында.

Заманында ул онытылып барган «Моң» һәм «Ияләр» дигән сүзләрне үз иҗатында кулланды. Гел үсештә, гел иҗади үрләр югарылыгында торырга яраткан Әхсән Фәтхетдинов халыкка «Баганалар» һәм «Тәрәзәдәге атлар» сериясен дә бүләк итте. Багана сүзенә ул зур мәгънә сала. Биредә ул багана-

БИОГРАФИК БЕЛЕШМӘ

Әхсән Фәтхетдинов 1939 елда Чирмешән районының Урманасты Үтәмеш авылында туган. Урта белемне рәссам ике педагогика училищесында ала: беренче өч курсны Самара өлкәсенең Камышлы училищесында укый, дүртенче курсны Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәрендә тәгәлли. Бер ел укытучы булып эшли. Чиләбе өлкәсенең Снежинск каласында армия хезмәтендә була.
1961 елны Әхсән Фәтхетдинов Түбән Тагил пединститутының нәфис графика факультетына укырга керә, аны 1966 елда тәмамлый. Рәсем сәнгате кафедрасы ассистенты итеп калдырыла, өч ел композиция һәм рәсем сәнгате укыта.
Рәссам 30 яшендә Татарстанга кайтып төпләнә һәм Түбән Кама каласында яшәп иҗат итә. Әхсән Фәтхетдинов – Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм ТРның халык рәссамы.

«Казан утлары» журналы редакциясендә очрашу.

«Көн аяза».

га рухи яктан да, физик яктан да якын килгән. «Мин баганаларны терелттем. Баганалар да кеше язмышы кебек. Баганалар да озак яшәми. Алар чери, югала, ава. Кеше дә шулай бит...», дия торган иде автор.

Чыннан да, Әхсән аганың хезмәтләрен тыныч күңел белән генә карап булмый. Моңсу күзле атлары елатырга, мөгезле Шүрәлесе елмаерга, «Үзем белән икәү» дигәне уйланырга мәҗбүр итә. Биредә агач һәм рәсем сәнгатенең табигый бөтенлектә берләшүе, ягъни синтезы күзәтелә. Аның күргәзмәләренә яшьләр, балалар да яратып йөри.

ИЯЛӘР ИЯСЕ

«Бүген вөҗдан хәлләре начар тора. Мине иң борчыган нәрсә – халык язмышы. Бер эшемә мин: «Дөнья төрлелеге белән матур» дип куйган идем. Бу Аллаһының бүләгедер инде. Ә соңгы вакытта бөтен нәрсәне берләштерә башладылар. Элитаның халыктан артык аерылуы халыкны эш атына әверелдереп бара. Байларның баюы, элитаның халыктан аерылуы борчый мине. Без революцияләр, сугышлар аша үттек. Халык кырылды, фаҗигаләр зур булды. Хәзерге заманда тагы да көчлерәк сынау – акча белән сыналу чорына кердек. Минемчә, бу адәм баласының акрынлап (ә бәлки, тиздер) эчтән таркалуы дип уйлыйм. Шуның өчендерме, минем иҗатым, башлыча, әхлакый темаларга кагыла. Ияләр саклый. Ә кешенең эчендә Багана булырга тиеш. Булмаса, ул аны үзе куярга тиеш. Кайда укыган, кайсы чишмәнең суын эчкән – менә боларның һәммәсен дә барларга кирәк», - дип яза рәссам.

Әхсән Фәтхетдинов иҗат иткән «Ияләр» циклы аеруча зур абруй казанды. 50 әсәрдән гыйбарәт әлеге шәлкем лаеклы бәясен дә ала – аның өчен ул Габдулла Тукай премиясе лауреаты булды.

«Татар фольклоры буенча, безнең тирәдәге һәммә нәрсәнең иясе, сакчысы, хуҗасы бар. Ияләр ташларны ватылмасын, суларны пычранмасын, тауларны җимерелмәсен өчен саклыйлар. Мәҗүсилек дип йөртелгән чорда кешеләр агачларга, ташларга, күлләргә табынганнар, димәк, алар табигатьне саклаганнар. Ияләр үлемсез... Алар кешелекне бертуктаусыз озатып баралар, кабат-кабат әхлакка чакыралар», – ди һәр нәрсәнең асылын тоярга омтылган сизгер рәссам.

Әхсән Фәтхетдинов иҗатта гына түгел, тормышта да үзенчәлекле, шаян шәхес була. Аны татарның танылган сәнгать әһелләре дә үз итә, аның рәссам турында халык арасында мәзәкләр чыккалый. Мисал өчен, шуларның берсе. Җырчы

Из ночи в день

Каравылчы

Илһам Шакиров белән каядыр барышлары икән. Әхсән Фәтхетдинов, ялкынланып, мәшһүр җырчыга нидер сөйли… Әңгәмәдәше аны тыңлый-тыңлый йокымсырап китә. Уянып күзен ачса, рәссам, кычкырып-кычкырып, «Иске кара урман»ны суза икән. Илһам Шакиров түзми, җырламаска боера. «Әллә сиңа гына җырларга дигәнме?» – ди Әхсән. Илһам, машинаны туктатып, аны төшереп калдырган, имеш. Соңыннан шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовка да бу вакыйганы сөйләп аңлаткан: «Мамадышка килеп җитәбез. Мин йокыдан айнып китсәм, кайдадыр таулар ишелә, сулар шаулап ага, сыерлар мөгри, сарыклар кычкыра кебек. Нәрсә булган, ахырзаман мәллә, дисәм, Әхсән «Кара урман»ны җырлый икән», – ди.

Агач уймалар остасының иҗаты – агач белән рәсем сәнгате синтезы. Картиналары кебек үк, аларның рамнары ук үзенчәлекле. Алар традицион формасын югалталар, тәрәзә, ишекләрне хәтерләтә башлыйлар. Нәкышче картиналарын әйләнә-тирә дөньяга органик рәвештә тәкъдим итә.

Ун агач сыннан гыйбарәт «Кимсетелгәннәр» сериясе репрессия корбаннарына багышлана. Агачны уеп эшләгән «Тәңре», «Сугыш елы атлары», «Җирсү», «Кара урман», «Төнге җәнлек» һ.б. әсәрләрен дулкынланмый гына карау, өйрәнү мөмкин түгел. Әхсән Фәтхетдиновның әсәрләре Татарстанның күпсанлы музейларында урын алган. Чит илдәге шәхси коллекцияләрдә дә рәссамның эшләрен табарга мөмкин. Фәлсәфәче рәссамның һәр хезмәте гомумкешелек идеяләре белән сугарылган, шунлыктан алар дөньяның һәр халкына, һәр кешесенә дә якын, газиз, тансык.

Розалина Шаһиева, сәнгать белгече:

– Әхсән Фәтхетдинов иҗаты – җилләр, һәлакәтләр, традиция ташкыннары, халык бәләләре һәм фаҗигаләре, кешеләрнең сыкранулары белән тоташудан туган сәнгать; аның табигать киләчәге, гомумцивилизация, милләт, дәүләт, этнос хакындагы хәсрәтле уйларының чагылышы. Нәкъ шушы сыйфатлар аны нинди дә булса аң тарлыгыннан, чикләнүләр, заман кысалары, базар исәп-хисапларыннан өстен булган фидакарь фикер иясенә әйләндерде. Безнең сәнгатьтә моңарчы күрелмәгән, мәгънәсе тапталмаган чор проблемалары хакында күрәзәлек иткән хикмәт-гыйбрәт тулы әсәрләр иҗат итүгә китерде; чын мәгънәсендә халык мәнфәгатен кайгыртучы, хөр күңелле, тирән сәяси акыллы халык рәссамы итеп таныта. Татар халкының рух менталитетына тиң сәнгать булдыруда күрсәткән фидакарьлек һәм фанатизм аны табигый рәвештә Татарстанның үз юлы, хөррият, суверенитет өчен барган көрәш юлына бастырды. 1990 нчы еллардагы вазгыятьнең сәнгати символикасы булып яңгыраган мифологик образлар пантеоны – «Ияләр» дастанына алып чыкты. Ул аның яңа эстетикасының формуласы, ачышы һәм иҗади җиңүе!

Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык шагыйре:

– Әхсән югары кимәлдәге талант иясе иде. Ул дәрәҗәле мөнбәренә авыр һәм газаплы юл үтеп, танылу-танылмау баскычлары аша күтәрелгән шәхес. 1980 нче елларда башланган дуслыгыбыз, аның гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итте. Әхсәннең Казанда оештырылган беренче күргәзмәсендә танышкан идек. Ул әдәбият һәм поэзия яратты. Мин аңа шигырьләр җыентыгымны бүләк иткән идем. И сөенгән инде ул аңа! Шуннан ул мине якын итә башлады. «Зират. Кабер ташлары» идеясе шуннан туды булса кирәк. Ул 60–70 агачка шигырьләремне чокып мәңгеләштерде. Әхсән белән безне иҗади намус бәйләгәндер: минем поэзия дә, аның эшләре дә намуска нигезләнгән. Сафлык һәм ихласлык хас иде аңа.

Ике хәзинә бар дөньяда: саклагыз!
Каберстан аның берсе. Гел гөлдә булсын!
Катапханә икенчесе. Күңелдә булсын!
Базар болай да калыр…
Уй-ниятләребез бер дулкында тибрәнгәндер.

Әсхәннең хатыны рус милләтеннән иде, балалары булмады. Күп вакытын ялгызлыкта, остаханәсендә үз-үзе белән сөйләшә-сөйләшә иҗат итә иде. Ялгызлык аңа дөньяны үзенчә аңларга ярдәм иткәндер… Ә Казанга минем янга килә. Аккош күлендәге йортымда рәхәтләнеп фикерләшә идек. Дөресрәге, ул сөйли, мин күбрәк аны тыңлыйм. Туктамыйча сөйли, мин башка бүлмәләрдән йөреп керәм, ә ул һаман сөйли. Әхсәннең миңа язган хатларын дөньяга чыгарасым килә. Соңгы вакытта аның хатларын редакциялим, дөресрәге кыскар-

там. Фәтхетдиновның рәссам буларак кына түгел, чын фикер иясе икәнен дә күрсәтәсем килә. Бу бөек кеше алдында бурычымны үтәргә телим. Миңа ышанып язган бит ул. Андый чиста кеше юк. Ул сабый да, хаким дә иде. Ияләрнең иясе. Ияләр дә күренеп йөрми бит. Әхсән – Табигать баласы.

Рауза Солтанова, сәнгать белгече:

– Әхсән Фәтхетдинов иҗаты – хәзерге татар сәнгатенең иң якты феноменнарыннан берсе, ул халык аңына үтеп кергән мифологиянең катлаулы дөньясын сәнгатьчә аңлау буларак үстерелә. Ул монументаль-декоратив сәнгатькә дә, скульптурага да, станок рәсеменең төрле жанрларына да зур өлеш кертте. Бу сәләхиятнең чыганагы, барыннан да элек, татар рәссамының авылы ядкәрләре белән аерылгысыз бәйләнештә булуында, алар бөтен татар мәдәниятендә рухиятнең тотрыклы нигезе булып тора. Кабинетымда Әхсән Фәтхетдиновның миңа бүләк иткән эшләренең берсе эленеп тора. Ул аны миңа 2010 елда «Галәм диннәре әхрамы» галереясендә шәхси күргәзмәсен оештырган вакытта бүләк иткән иде. Бу композиция агачтан эшләнгән, анда Равил Фәйзуллинның «Бу дөньяда гомер түгел, кабатланмый төшләр дә» дигән сүзләре язылган. Ул миңа әлеге үзенчәлекле рәссам турында гел искә төшереп тора һәм беркайчан да ялкауланырга ирек бирми.

Рөстәм Галиев, Түбән Каманың Т.Миңнуллин исемендәге Татар дәүләт драма театры җитәкчесе:

– Табигый, чиста күңелле кеше иде ул. Халкын да, илен дә бәхетле итәргә теләде, төссез, телсез, шаулы дөньядан игелек, әхлак, хаклык, матурлык таләп итте. Остаханәсендә Әхсән абый халык җырларын көйли-көйли эшләде. Әйе, халык җырларына мөнәсәбәте үзгә булды. Алар турында сөйләргә тотынса, бик озак, фәлсәфи якларына басым ясап, ялкынлы эчке кичерешләрен тезеп китә.

Әхсән абый – бик уңган кеше. Ул тәүлекнең 24 сәгатен эшләп уздыра. Төп хезмәт урыны – бакчасы, ә остаханәсенә кирәк булган өчен генә, сирәк йөри. «Ияләрем бакчада «туды», – дия иде.

Төрле чакларын күрергә туры килде: усал, кәмит, йомшак, баладай самими. Берәр җитди эшкә тотынса, үз эченә бикләнә, «телсез» булып кала.

Гомеренең азагында иҗат иткән җансыз баганаларга җан кертеп, дөньядан китеп барды ул. Циклның фәлсәфәсе шул: дөньядагы барлык баганаларның да үз язмышы бар. Ә Әхсән баганасы – биек, чиксез, очы-кырые күренмәгән шәфәкъ.

Бу дөньядан бакыйлыкка күчергәндә, аны гүргә үзем иңдердем. Һәм соңгы баганасын үз кулым белән утыртып калдырдым, Әхсән абыйга дога кылдым. ■

75 ПОБЕДА! 1945–2020

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ил өстенә мең бәла ябырыла. Шуларның берсе – яралы солдатлар өчен госпитальләрдә, хастаханәләрдә урын җитмәү. Тиз арада, 1941 елның 7 июлендә, СССРның Оборона халык комиссариаты госпитальләр санын арттыруны максат итеп куя. Нәтиҗәдә, илдәге 632 ял йорты һәм 221 шифаханә госпитальгә әйләнә. Шул рәвешле 55 мең урынга исәпләнгән дәвалау, тернәкләндерү үзәкләре барлыкка килә. ТАССР да илебезнең иң күп госпитальләр оештырылган төбәкләрнең берсенә әверелә. Бездә 17 госпиталь ачыла.

Бөек Җиңүнең 75 еллыгы якынлашкан көннәрдә, Арча районында эшләгән эвакогоспиталь турында язарга булдык. Иң сөенечлесе – шунда шәфкать туташы булып эшләгән ике ветеран әби бүген дә исән. Һәм без, аның берсе белән очрашып, аралашу бәхетенә ирештек.

СУГЫШ ЭЗЕ: АРЧА

«1944 елның 16 апрелендә миңа госпитальне ашыгыч рәвештә ташлап китәргә туры килде. Моңа көнләшү һәм яла сәбәпче булды: имеш, шунда эшләүче шәфкать туташы белән минем арада мәхәббәт хисләре барлыкка килгән. Ә чынлыкта бу бары кешелеклелек, бер-береңә карата ихтирам гына иде. Госпитальнең директоры, табиблар, шәфкать туташлары белән хушлашу авыр. Мин аларны гомерем буе онытмаячакмын. Безгә алар әсир итеп түгел, ә кеше итеп карады», – Италия гражданины Энджинио Франзини Арчадагы эвакогоспиталь турында шулай дип яза.

Автор:
Руфия Фазылова

«Бер генә үкенеч – бу эшкә соң алынганбыз», - диде Люция Фатыйхова.

Фото: Лилиана Валитова

«КУЕЛГАН МАКСАТНЫ ҖИРЕНӘ ҖИТКЕРЕП ҮТИЛӘР...»

Арча районы эвакогоспитале 1941 елның 24 июлендә үк оеша. Һәм ул 1946 елның 15 ноябренә кадәр эшли. Баштагы ике елда госпитальдә үзебезнең солдатлар дәваланса, 1943 елдан анда әсир төшкән немецларны алып киләләр. Сәбәп нидә? Нәрсә, сугыш уртасында кинәт кенә яралы солдатлар кимиме? Юк, әлбәттә. РФ Оборона министрлыгы Үзәк архивының Санкт-Петербургтагы филиалы (Хәрби-медицина документлары) мәгълүматларыннан күренгәнчә, 1941–1942 елларда яралы солдатлар арасында туберкулез киң тарала. Авыру солдатларны аерым дәвалый башлыйлар. Ләкин бу ярдәм генә җитми, чир көннән-көн киңрәк тарала. Җитәкчелек тиз арада чарасын күрергә ашыга, 40–50 кешелек, хәтта аннан да күбрәк урынга эвакогоспитальләр ача башлыйлар. Хәрби җитәкчеләрнең планы рас килә: 1943 елда туберкулез чигенә. Ә эвакогоспитальләрне берләштерергә дигән фәрман чыга. Шул рәвешле, Арча эвакогоспиталендә дәваланучы солдатларны бүтән җирләргә күчерәләр, савыкканнарын исә фронтка яки өйләренә озаталар.

Тарих битләренә күз салсак, Арча эвакогоспитале башта 0192 номеры белән йөри, аннан соң аңа 3655 номеры бирәләр. Аның беренче җитәкчесе – икенче ранглы хәрби табиб – Веньямин Иосифович Эмдин була. Баш табиб истәлекләрендә госпитальне 31 июльгә әзер булды, дип яза. Госпитальнең беренче бинасы өчен район хастаханәсенең яңа ягын алалар. Ул бина 150 кешене сыйдыра ала. Веньямин Эмдин, госпиталь өчен сөлге, халат, медикаментлар, аш-су бүлмәсенә кирәк-яраклар бирүләрен сорап, кат-кат рәсми хатлар яза. Һәм теләгенә ирешә. Госпиталь өчен тагын ике бина – Арча педучилищесының ике катлы тулай торагы һәм уку бинасын бирәләр. Җәмгысы 550 солдат өчен урын булдырыла. Тагын госпиталь карамагында аш-су әзерли торган агач йорт, шәфкать туташларына яшәү өчен аерым агач бина да була.

Үзәк бер айдан соң гына авыруларны кабул итә башлый. (Документларны тәртипкә китерү, коллектив туплау өчен шулкадәр вакыт кирәк була). Яралы солдатларны санитар поездлар белән Арча тимер юл станциясенә күпләп (сиксәнгә якын) алып киләләр.

Арча эвакогоспитале башта аяк-куллары яраланган солдатларны дәвалау өчен дип оеша. Ләкин гадәттә аяк-кулы яраланган солдатның эчке әгъзалары да җәрәхәтләнгән була. Бу авыруларны дәвалау чын проблемага әйләнә: госпитальгә хирурглар җитми, ә баш хирург бөтенләй юк. Медицина югары уку йортларын тәмамлаган яшь белгечләрне тиз арада ГИДУВта, яңадан әзерлек курсларында укытып, Арчага җибәрәләр. Шулай итеп терапевт, педиатр, гинеколог булырга укыган студентлар, катлаулы операцияләр ясый башлый. Шунысын да әйтергә кирәк: операция блогы чорына күрә бик яхшы җиһазландырылган була. Чисталык ягы да бик зур контрольгә алына. Кан белән проблема тумый – даи-

ми рәвештә Үзәк кан бирү станциясеннән килеп тора.

1942 елның 17 мартында Арча эвакогоспиталенә Мәскәүдән тикшерү комиссиясе килә. Актка комиссия әгъзалары болай дип язып калдыра: «Операцияләр нәтиҗәсе бик тә канәгатьләнерлек, кан салу нәтиҗәләре әйбәт. Яшь табиблар коллективы авыруларга карата зур игътибар бирә һәм тырышлык күрсәтә. Куелган максатны җиренә җиткереп үтиләр».

ӘСИРЛӘРДӘН СОҢ УРЫН – БАЛАЛАРГА...

Арча эвакогоспитале 1943 елның 7 мартында үзебезнең солдатларны дәвалаудан туктый. Бирадәге табиблар, шәфкать туташлары ике ел эчендә 3380 кешегә ярдәм күрсәтә. Тиз арада – өч көн эчендә госпитальдәге 311 яралы солдатны төрле җирләргә озатып, 10 мартта әсирлеккә алынган тоткыннарны каршы алалар. Госпитальнең коллективы үзгәрми, шушы составка бары 5 конвоир гына өстәлә. Үзебезнең солдатлардан аермалы буларак, тоткыннарны дәвалау катлаулырак була. Яралары өстенә аларда дизентерия, туберкулез кебек йогышлы авырулар барлыгы ачыклана. Шулай ук тиф, гепатит, малярия, корчаңгы кебек чирләр дә табыла. Тоткыннар арасында үлүчеләр бик күп була. Аларны, Арча янында махсус зират ачып, шунда күмә баралар. (Анда меңнән артык әсирнең җирләнгәнлеге мәгълүм). 1945 елда, югары оешмалар кушуы буенча, госпитальнең бер бинасы урта мәктәп карамагына бирелә. Әсирләр өчен 300 урын кыскартыла. Ә эвакогоспиталь тулысынча 1946 елның 15 ноябрендә таратыла. Ике бинаның берсе – район хастаханәсенә, икенчесе Арча педучилищесына кайтарыла.

Арчада кайчандыр эвакогоспиталь булганын искә төшерә торган урын районда икәү генә: берсе – әсирләр күмелгән зират, икенчесе – музей. Зират район админист-

1945 елда госпитальнең бер бинасы урта мәктәп карамагына бирелә.

Италия гражданины Энджинио Франзини, Арча эвакогоспиталендә дәваланып, туган ягына исән-имин әйләнеп кайткан солдатларның берсе. Әсирлектә булган хәлләре турында ул «Последний ад» дип исемләнгән әсәр яза. Аны 1966 елда китап итеп бастырып чыгара. Әсәрнең сигезенче бүлегендә Арча госпитале турында да языла:

«Бүген 1943 елның 9 мае. Без, ике йөзләп әсир, станциядә поезд көтәбез. Кулга алынганда 500 солдат идек. Өч йөз ватандашыбыз бакыйлыкка күчте, аларны туганнар каберлегенә күмәр өчен көннәр җылынганын көттеләр. Сау булыгыз, туганнар. Сезнең хакта якыннарыгызга җиткербез. Бәлки... Ә бәлки тиздән үзебез дә сезнең янда булырбыз...

Кая барабыз? Безне озата барган табиблар – Лидия белән Сонядан шул хакта сорадым. «Хәрби сер», – дип әйтмәделәр. Саубуллашканда өлкән яштәге рус табибы: «Сез әле яшьләр, барысы да алда. Борчылмагыз, якты киләчәк каршына барасыз», – дип озатып калды. Якты киләчәк... Бармы икән ул?..

Поезд көнчыгышка таба юл тотты. Эх, шушы урман арасында поездан төшеп калыр идем. Әнә анда кечкенә өйләр күренеп калды. Шунда иген үстереп, табигатькә сокланып яшәр идем. Бу ачлык, бу салкын, бу авыру бәгырьләрне телә...

Шулай уйланып, ярым тилергән хәлдә, биш тәүлек бардык. Поезд станциягә килеп туктады. Арча дигән зур бистә икән. Казаннан 50 чакрым ераклыкта, диделәр. Картадан карадык – ул шәһәр янында Идел елгасы ага булып чыкты. Эх, шуны барып күрергә...

Арчада безне бик яхшы каршы алдылар. Иң мөһиме – туйганчы ашадык. Минем Чыңгыз хан турында укыганым бар иде. Ни өчендер, Арча миңа шул әсәрдә язылган авылны хәтерләтте. Безне яхшы дәвалыйлар. Шәфкать туташлары хәтта ара-тирә концерт та куя...

1944 елның 16 апрелендә миңа госпитальне ашыгыч рәвештә ташлап китәргә туры килде. Моңа көнләшү һәм яла сәбәпче булды: имеш, шунда эшләүче шәфкать туташы белән минем арада мәхәббәт хисләре барлыкка килгән. Ә чынлыкта бу бары кешелеклелек, бер-береңә карата ихтирам гына иде. Миңа якын дустым Ферраринины ташлап китүе авыр. Шулай ук госпитальнең директоры Наимә Байтирәкова, хирург Константинов, шәфкать туташлары белән хушлашу да авыр. Мин аларны гомерем буе онытмаячакмын. Безгә алар әсир итеп түгел, кеше итеп карады... Истәлеккә үзем белән агачтан ясалган коробканы алам. Без, әсирләр, бирадә зур булмаган остаханә булдырган идек. Менә шунда төрле кул эшләре ясадык.

...Сау булыгыз, дусларым. Барыгызга да зур рәхмәт. Сезне мәңге йөрәгемдә саклармын!..»

рациясе карамагында икән, ул төзек, чиста. Ә музей 3 нче номерлы башлангыч мәктәптә урнашкан. (Балалар бакчасы да шунда ук.)

– Безнең мәктәп урынында эвакогоспиталь булганын җирле халык бик яхшы белә, – диде 3 нче башлангыч мәктәбенең директоры Люция Фатыйхова. – Балаларга бер тарих, күрсәтер урын булсын, дип, музей булдырдык. Дөресрәге, эшнең башы ветеран укытучы, җәмәгать эшлеклесе Рәмзия апа Хәмидуллинага барып тоташа. Арчада эвакогоспиталь хөрмәтенә музей ачу өчен, конкурста катнашып, грант откан иде ул. Ниятен Арча район хастаханәсенә җиткергән. Тик бу фикерне күтәреп алучы булмаган. Шуннан Рәмзия Шәриповнага: «Грант акчасына музейны безнең мәктәптә ачыйк», – дидем. Ул бик теләп риза булды.

Узган ел шул грант акчасына 3 нче мәктәп ишегалдына мемориаль такта эшләтеп куйганнар. Анда 3655 эвакогоспитале турында кыскача белешмә язылган.

– Бер генә үкенеч – бу эшкә соң алынганбыз, – дип дәвам итте директор. – Бүгенге көндә Арча эвакогоспиталендә эшләгән ике генә кеше исән, һәрхәлдә, без белгәннәре. Мәгълүм булганча, бирегә табибларның барысы да диярлек читтән килә, ә шәфкать туташларының күбесе үзебезнең районнан яки якын-тирә районнардан җыела. Алар белән күрешеп сөйләшергә бер дигән мөмкинлек булган икән, ә без шуны файдаланмаганбыз. Соңгы ун елда гына да госпитальдә шәфкать туташы булып эшләгән берничә әби бакыйлыкка күчкән. Ни кызганыч…

Шулай да мәктәп укытучылары, укучылары мәрхүм булган ул әбиләрнең кайберләрен эзләп тапкан. Балалары белән күрешеп, алар турында истәлекләр җыйганнар. Һәм, шул мәгълүматларга таянып, төрле стендлар эшләткәннәр.

«ХАТЛАР КИЛӘ ТОРА...»

Люция Фатыйхова белгечлеге буенча немец теле укытучысы. Музей ачылганнан соң тарих белән дә кызыксына башлаган.

– Минем максатым – биредә эшләгән табиблар, шәфкать туташлары турында күбрәк мәгълүмат белү. Һәм 3655 номерлы эвакогоспитальдә дәваланган әсирләрнең якыннарын эзләп табу, – диде директор.

Тамчыдан күл җыела шул. Люция Фатыйхова унлап әсирнең туганнары белән элемтә булдырган.

– Ә сез аларны ничек эзлисез? – дидем директорга.

– Аларның исемлеге бар бит. Төрле илләрнең консуллыкларына аңлатмалы хатлар язам. Алланың рәхмәте, җаваплар килә. Мисал өчен, италияле бу әсирнең фотосын музейга кую өчен балалары җибәрде. Ул Арча туганнар зиратына күмелгән. Германиядән Питер Шнайзер исемле ир, берничә ел элек Арчага кайтып, әтиләренең каберен күреп киткән. «Зират бик матур, каралган. Моның өчен зур рәхмәтемне җиткерәм», – дип язды ул миңа. Узган җәй Арчага Япониядән кунаклар кайтты. Алар башта Казанга килеп, әсирлектә булган бабалары турында белешмә җыйган. Аның монда җирләнгәнен белгәч, безгә килделәр. Туганнар зиратына барып, бабалары истәлегенә үз традицияләре буенча дога кылдылар. Музейга кереп, госпитальдә эшләгән шәфкать туташларының фотоларын карап, документ күчермәләре белән танышып йөрделәр. Җылы бер очрашу булды ул.

Гаҗәп: госпитальнең бинасы 2010 елга кадәр файдаланыла! Дөрес, аңа капиталь ремонт ясала. Бәлки әле тагын белем бирү үзәге буларак та кулланылыр иде, ләкин бина 2010 елда ишелеп төшә. Шуннан соң, сүтеп, аның урынына яңа мәктәп салалар.

– Җир казыганда сугыш чорына караган предметлар чыкмадымы? – дип кызыксындым Люция Фатыйховадан.

– Юк, дип беләм. Ул вакытта эвакогоспиталь тарихы белән әллә ни кызыксынучы кеше булмаган. Махсус эзләп утырсалар, бәлки, табылыр да иде.

...Җитмеш ел элек Арча эвакогоспиталендә ниләр булганын хәзер төгәл генә әйтеп булмый, әлбәттә. Ләкин бер нәрсә хак – кешеләр шәфкатьле булган, бер-берсенә карата кайгыртучанлык күрсәткән. Үз солдатымы, Ватанына һөҗүм иткән дошман улымы, барысына да ярдәм иткән. Шундый авыр минутларда ул әбибабаларыбыз Кеше булып кала алган. Безгә әнә шуны онытмаска кирәк…



Музей экспонатлары.

«РФ Оборона министрлыгы Үзәк архивының Санкт-Петербургтагы филиалында сакланган хәрби-медицина документларыннан күренгәнчә, Арча эвакогоспиталендәге тоткыннарның ашаулары хәтта үзебезнең солдатларныкына караганда да яхшырак була. 1943 елның октябрь аена ясалган исәп-хисап документыннан күренгәнчә, ризыклар яңа өлгергән, чи яшелчәләрдән әзерләнә. Витамин өчен дип хәтта юеш чүпрә дә бирелә. Яшелчәләрдән тыш бәрәңге оны, манный, дөге, макарон, сыер ите, балык, сыер мае, шикәр, чәй, кофе, сөт, каймак, эремчек һәм башка ризыклар бирелә. Әйе, гаҗәп яхшы күңелле халык яши Россиядә! «Цивилизацияле» Германия безнең әсирләрне ачлыктан интектергәндә, газлы камераларда үтергәндә, без аларныкын диетик ризыклар ашатып, тәрбияләп тоттык. Ә шул ук вакытта үзебезнең халык ачлыктан тилмерде».

Михаил Черепанов,
«Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан госпитальләре» китабыннан.

ИЛЕБЕЗНЕҢ ШӘФКАТЬ ТУТАШЫ

Автор: Руфия Фазылова

Ул әсирләрне Мәскәүгә кадәр берүзе озата бара. Арча эвакогоспиталеннән киткәндә, 17 немецны кисәтеп куялар: «Александра Николаевнага хатын-кыз дип кенә карамагыз. Кырыйгарак бер адым – шунда ук ут ачачак. Ул яктан да аның осталыгы бик яхшы – шикләнмәгез...» Сүз профессионал атучы турында бара дип уйласагыз, ялгышасыз. Александра Барышева бары тик гап-гади шәфкать туташы була.

«ӘНИ СҮЗЕН ТЫҢЛАП...»

Госпиталь хезмәткәрләре дөрес әйтә: Александра Николаевна яхшы ата. Үсмер кыз моңа мәктәптә укыганда ук өйрәнә. Әлбәттә, ул кайчан да булса бу шөгыльнең кирәге чыгар дип башына да китерми. Ә тормыш, чынбарлык мәҗбүр итә.

Бөек Ватан сугышы башланганда Александра Барышева 8 нче классны тәмамлаган була. Кызның ничек тә туган иле, җәмгыять өчен файдалы буласы килә. Һәм, озак уйлап тормыйча, Арча медицина мәктәбенә документларын тапшыра. Сугыш барганлыктан, уку елы сигез ай гына бара.

– Медицина мәктәбе курсын тәмамлаганда, миңа уналты яшь иде, – дип искә алды Александра Барышева. – «5» ле билгеләренә генә укыдым. Уку йортының җитәкчелеге документларымны Казанга – медицина институтына әзерли башлады. И, сөенгәннәрем! Бу турыда өйгә кайтып әнигә әйттем, тик ул кырт кисте: «Кызым, тормышлар бик авыр. Сине укытырлык чама юк. Әлегә шәфкать туташы булып эшкә урнаш. Сугыш бетеп, дөньялар тынычлангач укырсың», – диде. Шулай итеп, алга таба белем алудан баш тартырга туры килде. Юк, мин әнигә үпкәләмим. Тугыз бала, аларны бит ашатырга кирәк. Әти авыру. Кыен вакытлар...

Александра Николаевна бүген, инде тормыш тәҗрибәсе туплаган, дөньяның ачысын-төчесен татыган кеше буларак шулай фикер йөртә. Ә ул чакта, туган иленә файда китерү теләге шул дәрәҗәдә көчле булган ки, хәтта әти-әнисе турында уйлау да икенче планга күчә. Югары белем алу хыялы чәлпәрәмә килгәч, ул иптәш кызы белән... Арча район хәрби комиссариатына китә.

– Менә безнең кулда диплом. Яраларны бәйли беләбез, укол кадарга өйрәндек, кирәк икән, күрсәтә алабыз. Безне фронтка җибәрегез әле, – диләр.

Баш комиссар, серле генә елмаеп, кызларны тыңлап тора да:

– Рәхмәт, кызлар! Сез бик батыр. Сездән яхшы шәфкать туташлары чыгачак, моңа мин һич шикләнмим. Ләкин әле сезгә унсигез тулмаган. Исемлеккә беренче итеп язып куябыз, хәбәр көтегез. Ә хәзергә сезне юллама белән кая җибәрделәр, шунда барыгыз, – дип озатып кала.

– Ни өчендер бик тә фронка барасыбыз килде. Анда безнең ярдәмгә мохтаҗ кешеләр күп кебек тоелды, – ди әңгәмәдәшем.

Тик чакыру килми дә, килми, яшь шәфкать туташларын фронтка чакыручы булмый. Хәер, кызлар баш комиссарның мыек астыннан гына елмаеп сөйләшүен янында чакта ук чамалый.

– Сугыш бетмәсә, яшебез тулгач, хәрби комиссариатка кабат килербез, – дип сөйләшеп куялар үзара.

Кеше эзләгәнен табар, диләр халыкта. Фронтка бармаса да, кызның хыялы тормышка аша – яралы солдатларны дәваларга насыйп була аңа. Дөрес, үзебезнекеләрне түгел, шулай да...

– 1942 елның 5 августында юллама буенча Әтнә районындагы балалар шифаханәсенә киттем, – дип дәвам итте сүзен Александра Николаевна. – Анда вакытлыча әти-әниләреннән аерылган балалар яши иде. Кайсының әниләре окоп казырга киткән, кайсының үлгән, ә әтиләре фронтта. Без, дүрт яшь шәфкать туташы, шундагы алтмыш баланың сәламәтлеген карап тордык. Шифаханә дип аталса да, анда шартлар әйбәт түгел иде. Ярый инде, балалар ачка тилмермәде. Ә менә безгә, шәфкать туташларына, бөтенләй шартлар начар. Ашарга юк, салкын бүлмәләрдә яшәдек. Әле өйләре якын булган кызларга җиңелрәк, туганнары ашарга алып килде. Миңа исә сынык та алып килмәделәр. Беренчедән, Әтнә Арчадан ерак, икенчедән, өйдә дә ашау ягы такы-токы. Тагын аларны борчымадым инде.

Александра Барышева Әтнә балалар шифаханәсендә 1944 елның июненә кадәр эшли. Ә аннан соң аны Арча эвакогоспиталенә җибәрәләр.

– Балалар шифаханәсендә мин бик нык бетерештем, – диде әңгәмәдәшем. – Салкын тиеп каты авырып яттым. Шифаханәнең директоры, мине кызганып:

– Александра, син монда үләсең. Бар, туган ягыңа кайт. Арча эвакогоспиталенә барып кара. Мин сиңа яхшы характеристика язып бирәм, – дип кайтарып җибәрде. Атлап түгел, йөгереп йөргән кыз, аяклары йөрмәс дәрәҗәгә җитеп, Әтнә балалар шифаханәсеннән чыгып китә.

– Аякларым йөрмәс булды. Гаҗәп тә түгел: тәүлегенә бер ипине өч шәфкать туташы белән бүлешеп ашадык.

«КУРКУ ТУРЫНДА УЙЛАМАДЫМ ДА»

Александра Барышева туган йортына кайта. Аз гына хәл алгач, эвакогоспитальгә китә. Директорны көткәндә, аякларының хәле бетә, санитаркадан коляска сорап ала. Бу хәлгә калган яшь кызны госпиталь җитәкчесе кызгана:

– Шәфкать туташын башта туйганчы ашатыгыз, дәвалагыз. Аннан эш бирерсез, – ди.

– Һич онытасым юк: өлкән шәфкать туташының мине эшкә аласы килмәде, – дип дәвам итте Александра Николаевна. – Гаепләмим, ул вакытта госпитальдәге әсирләргә ризык кеше башы исәбеннән кайта. Ә мин беркем дә түгел – әле эшкә урнашмаган, димәк, шунда эшләүчеләрнең ризыгын ашарга тиешмен. Әлбәттә, госпиталь җитәкчесенең сүзенә каршы килмәде. Мине ике ай дәваладылар. Аякка баскач, рәсми рәвештә эшли башладым.

Кызга бәхет елмая – Арча медицина мәктәбендә белем биргән укытучысы Фаина Галиевнаның бирердә табиб булып эшләве ачыклана. Яшь шәфкать туташын ул үзенең канаты астына ала. Озак та үтми, Александра Николаевнаны өлкән шәфкать туташы вазыйфасына күчерәләр.

Фото: Лилиана Вәлитова

– Эвакогоспитальдә дәваланучы әсирләр милләтенә карап бүленгән иде, – диде әңгәмәдәшем. – Без венгрлар, румыннарны дәваладык. Немецлар кебек үк, СССРга каршы сугышсалар да, аларны бер-берсе белән очраштырмыйлар иде. Чөнки ике арада бәхәс чыгу ихтималы зур. Госпитальдә әсирләр бер палатада ун-унбиш кеше яшәде. Куллары богаулы түгел, төнгегә үзләре генә калалар иде.

– Ә сез, яп-яшь кызлар, шул әсирләр янына ничек курыкмыйча керә идегез? – дим.

– Безнең белән конвой да керә иде. Автомат белән. Курку хисе юк иде. Ничек аңлатырга... Бу бит авыру белән табиб мөнәсәбәте. Үзләрен дәвалаганга, ашатканга, әсирләр безгә бик рәхмәтле иде. «Фронттан соң без җәннәткә эләктек», дип кабатладылар гел.

– Госпитальдән качу яки берәр табиб, шәфкать туташына һөҗүм очраклары булмадымы? – дим.

– Әсирләрнең качу очрагын хәтерләмим. Хәер, качып кая барсыннар инде. Ә менә бер шәфкать туташына һөҗүм булган иде. Һөҗүм, дип... Шәфкать туташы бер румын әсирен немецлар белән чагыштырган. Шуннан әсирләр моны палата уртасында чолгап алган. Конвой белән табиб кергәч кенә таралганнар.

Александра Барышева Арча эвакогоспитале ябылганчы эшли. Алай гына да түгел, соңгы эшелонны Брестка кадәр озата барган санаулы кешеләрнең берсе дә була. Ул көннәрне ветеран бүген дә хәтерли:

– Арчада дәваланган әсирләрне җыеп, мине һәм тагын ике лейтенантны поездга утыртып җибәрделәр. Мин, шәфкать туташы буларак, әсирләрнең сәламәтлеген кайгыртырга тиеш идем. Безгә кораллар бирделәр. Әсирләрне тезеп бастырып, барысын да аңлаттылар. Миңа карата аерым игътибар булды. Хатын-кыз дип кенә карамагыз, Александра Николаевна бик яхшы ата, дип, әсирләрне куркыткан булдылар.

– Ә чынлыкта яхшы ата идегезме соң? – дим.

– Әйе, яхшы ата идем. Безгә бит мәктәпкә «Военная подготовка» дигән фән керде. Практик дәресләр дә күп булды. Мин гел «унлы»га тидерә идем.

Арчада дәваланган әсирләр Мәскәүгә кадәр тыныч бара. Мәскәүдә исә вагоннарга бүтән әсирләр дә керә. Менә анда аяныч хәлләр була... Әсирләр бер-берсен үтерә башлый.

– Ни сәбәпле? – дим Алексанра Николаевнага.

– Туган якларына алып кайтабыз бит. Кемдер СССРга каршы сугышмаган. Ә бичарадан ничара, дигәндәй, фронтка китәргә мәҗбүр булган. Моны иптәшләре дә белә. «Туган якка кайткач, синең нишләп йөргәнеңне тиешле оешмаларга җиткерәбез», – дип яныйлар. Шуннан талаш, ызгыш китә. Иптәшләрен яклап



бүтәннәре дә кушыла. Берничә шундый конфликтны үземә дә туктатырга туры килде. Андый вакытта кулыңа корал аласың, йөзеңә зәһәрлек чыгарасың...

Әсирләрне озата киткән шәфкать туташы, бер ай дигәндә, янә туган нигезенә әйләнеп кайта.

«ЕЛАП АЕРЫЛЫШТЫК...»

Александра Барышева язмышы турында берничә фильм төшерергә булыр иде һәм төрле жанрда. Мисал өчен, сугыштан соңгы тормышы берәр мелодрама өчен менә дигән тарих.

Иң беренче шуны әйтим: батыр ханым игезәк балалар – малай белән кыз үстергән. Бүген ул улы, килене, оныклары белән бергә яши.

– Балаларымның геннары яхшы булсын, дип, махсус көчле, матур ир сайладым, – дип елмайды Александра Николаевна.

– Һәм шундый кешегә кияүгә чыктыгызмы? – дидем.

– Юк, кияүгә чыкмадым, дөресрәге, балаларымның атасы белән язылышмадык. Ә болай рәсми рәвештә кияүдә булдым мин.

Бактың исә, Александра Николаевна Арча егетенә кияүгә чыккан. Тик биш елдан, балалары булмау сәбәпле, аерылышканнар.

– Иремнән ялынып диярлек сорадым: «Ирләр болай да аз, зинһар, бүтән хатын-кызга өйлән. Тулы гаилә булып яшәрсең, балалар сөярсең», – дидем. Ул риза булды. Озакламый ул икенче кызга өйләнде. Бер-бер артлы ике балалары туды. Тик ирем атна саен диярлек яныма килеп йөрде. «Сине оныта алмыйм», – дия иде. Ә мин аны сүгә идем. Күрәсең, яратмаганмын. Кешеләр балалары булмаса да бергә яши, ә мин яши алмадым.

– Ә балаларыгызның атасы белән ничек таныштыгыз? – дим.

– Борис Арчага эшкә килгән иде. Инженер, төз гәүдәле, укымышлы, чибәр. Апага фатирга кергән иде ул. Мин бик күп укый идем. Берсендә шулай китаплар сорап килде. Сөйләшеп, аралашып киттек. Киного чакырды. Бер уйламаган җирдән безнең арада мәхәббәт ялкыны кабынды. Мин ул вакытта район хастаханәсендә рентген кабинетында эшли идем.

Яшь ханым соңрак йөкле икәнен белеп ала. Бу турыда Бориска әйтә. Егет исә кызны үзе белән китәргә – Мәскәү өлкәсенә чакыра. Тик Александра ризалашмый.

– Ни өчен? – дидем, гаҗәпләнеп.

– Борис югары белемле, иптәшләре дә укыган кешеләр. Ә мин нәрсә, гади авыл кызы. Бер белмәгән җиргә ничек чыгып китәсең? Арчада инде фатирым бар, эшем яхшы. Без аның белән елап аерылыштык. Хатлар язып торырга, тагын күрешергә сүз куештык.

– Күрештегезме соң? – дим.

– Балалар тугач килде ул. Аралашып яшәдек. Балаларны үзе янына да чакырды. Борисның гаиләсендә дә игезәк балалар үсте.

Язмышлар, диген... Александра Николаевна үзе сиздермәскә тырышса да, миңа шулай тоелды: Борисыннан башка бүтәнне ярата алмаган ул... Кияүгә сорап килүчеләр дә күп булган, тик ул, балалар хакы дип, ул тәкъдимнәрне кире кагып яшәгән. Ә теге вакытта сөйгәне белән ни өчен Мәскәү өлкәсенә чыгып китмәгәне... Минем өчен сер булып калды. Кулына автомат тотып, әсирләр белән атналар буе поездда барган кыз чит җиргә китүдән куркып торыр идеме?..

Хәер, монысы инде безгә кагылмый. Уналты яшеннән фронтка китәргә теләгән, егерме яшендә әсирләрне дер селкеткән кызның язмышы да әнә шундый борма юллар аша сузылырга тиеш булгандыр...

КАЗАН ГУБЕРНАСЫ 1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫНДА

Автор:
Илдус Заһидуллин

Тарихи вакыйгалар үз вакытында ничек аталып йөртелә дә, аннары аларга нинди мөһер сугыла? Ә бит аларны ничек атау һәм дәреслекләргә кертү, беренче чиратта, дәүләтнең сәясәте һәм халык үзаңына сеңдерергә теләгән күзаллаулары белән бәйле. Шундыйларның берсе – Россия тарихындагы «Беренче Ватан сугышы» буларак билгеле вакыйгалар чылбыры.

Дворяннар чоры историографиясенең күренекле вәкиле Модест Богданович үзенең 1859–1860 нчы елларда басылган өч томлы хезмәтендә Ватан сугышы белән Александр I җитәкчелек итте, сугышның әйдәп баручы көче дворяннар булды, аларның җиңүенә Аллаһы Тәгалә ярдәм итте, дигән карашны алга сөрә.

ВАТАННЫКЫМЫ? ЮКМЫ?

1812 елгы Ватан сугышы хакында һәрберебез азмы-күпме белә. Бүген, җәмгыятьтә патриотик тәрбиягә игътибар нык көчәйгән шартларда, «Ватан сугышы» темасына еш мөрәҗәгать ителә.

Александр I идарә иткән елларда дөнья күргән тарихи хезмәтләрдә 1812 елгы вакыйгалар «1812 елгы сугыш» дип атала.

«Ватан сугышы» дигән төшенчә император Николай I кушуы буенча кертелә. Әлеге төшенчә беренче мәртәбә Александр Михайловский-Данилевский (1812 елгы сугышта Михаил Кутузовның адъютанты) тарафыннан юбилейга йөз тотып язылган һәм 1839 елда дөнья күргән тирән эчтәлекле дүрт томлы китапта телгә алына. Әлеге бәяләмә 1917 елга кадәр яши. Әмма Михайловский-Данилевский хезмәтендә 1812 елда крестьяннар белән алпавытлар арасында киң җәелгән сыйнфый көрәш турында бер сүз дә әйтелми.

Бөек рус язучысы Лев Толстойның 1865–1869 елларда дөнья күргән «Сугыш һәм солых» («Война и мир») роман-эпопеясе дворян историографиясе казанышларына таянып языла.

XX гасыр башындагы яңа карашлар җиде томлы фундаменталь «Ватан сугышы һәм рус җәмгыяте» исемле хезмәттә теркәлә. Бу хезмәтне әзерләүдә 60 тан артык галим катнаша, ул сугышның 100 еллыгына багышлана. Китапта рус императоры бик һавалы, хәрби осталыгы чамалы булган шәхес итеп

сурәтләнә, Наполеон белән килешүгә бармавы аның төп казанышы дип атала. Авторлар дворяннарның патриотизмын да шик астына куя, крепостной крестьяннарда («колларда») патриотик хисләр булуда, гомумән, шикләнә. Сугыш вакытындагы сыйнфый көрәш калку күрсәтелә, ул, хәтта «барлык катлам вәкилләренең тәхет тирәсендә берләшүе» турындагы фикерне какшата да сыман. Буржуаз тарихчылар феодал тәртипләр хакимлек иткән Россиянең Наполеонны тар-мар итүен иске тәртипләрнең революцион Францияне һәм демократияне җиңүенә тиңлиләр.

Большевиклар хакимияте урнашкач, СССРда Владимир Ленин тарафыннан советларның баш тарихчысы итеп билгеләгән Михаил Покровскийның әле 1913 елда ук әйткән «Наполеон баскынчы түгел, аның 1812 елгы походы мәҗбүри саклану чарасы» дигән фикере өстенлек ала. Наполеон үзенең төп көндәше итеп Англияне саный, аның белән сугышка әзерләнә. 1811 елда рус императоры Александр I, һөҗүм итәргә ниятләп, көнбатыш чик буена 311 мең сугышчы һәм 956 туп тезеп куя, чөнки ул шул елның көзендә Пруссия белән бергә һөҗүм башларга килешә. (Бу хакта көнбатыш чик буендагы биш корпус җитәкчеләренә 24, 27 һәм 29 октябрьләрдә приказлар юллый, ләкин, союзникның килешүне бозу сәбәпле, план өзелә). Моны белеп алган Наполеон, 325,9 меңлек гаскәр һәм 984 туп алып, Неман елгасын кичә. Максаты – рус гаскәрләрен тар-мар итеп, Россия белән солых төзү. Чик буенда тупланган гаскәрләр, император Александр Павловичның ни эшләргә белми аптырап торуы һәм Петербургка кайтып китүе сәбәпле, тәртипсез рәвештә чигенә башлый. Бу чигенү ниндидер план нигезендә түгел, ә чарасызлыкның аяныч нәтиҗәсе була.

Михаил Покровский 1912 елдагы сугышның халыкчан булганын инкарь итә, Кутузовны нык тәнкыйтьли, дошманга төп зыянны хәрби бәрелешләр түгел, ә кышкы салкыннар һәм күпмилләтле гаскәриләр арасында дисциплинаның йомшаклыгы салды, дип аңлата. Тарих фәнендә, мәктәпләрдә шушы фикер җиткерелә.

1938 елда, һич көтмәгәндә, академик Евгений Тарле (1874–1955) үзенең «Наполеонның Россиягә һөҗүме» исемле китабында 1812 елгы сугышны кабат «Ватан сугышы» дип атый. Академик рус императорын һәм царизмны нык тәнкыйтьләсә дә, басып алу планы хакында бер сүз дә әйтми. Марксизмның сыйнфый көрәш концепциясе хакимлек иткән шартларда аңардан «Ватан сугышы», «бөтенхалык сугышы» турындагы «яңалыкны» Иосиф Сталин әйттергән, дип саный бүгенге галимнәр.

Бөек Ватан сугышыннан соң, 1812 елгы вакыйгаларны совет тарих фәне Иосиф Сталин билгеләгән рәвештә, «ура патриотизм» рухында, тагын да үзенчәлеклерәк итеп яктырта.

Сталин үзе дә, 1947 елда «Большевик» журналында мәкалә бастырып, Кутузовны зур талантка ия даһи полководец дип бәяли. Әлеге язмадан соң, рәсемнәрдә фельдмаршалның йөзкыяфәтен матурлап: битен «чистартып», тар маңгаен «киңәйтеп», сугышта яраланып югалткан уң күзен «табып», ике күзле итеп сурәтли башлыйлар.

1950 елда Мәскәүдә тарихчы Павел Жилинның (1952 елда Сталин исемендәге премия белән бүләкләнә) «Кутузовның 1812 елгы контрһөҗүме» китабы басылып чыга. Автор 1941 елда иптәш Сталин гитлерчыларны Мәскәү янына кадәр махсус алдалап алып китерә, кайчандыр Кутузов та шул рәвешле хәрәкәт иткән, дип раслый. Югарыда телгә алынган Михайловский-Данилевскийны кабатлап, Наполеон Россияне басып алырга теләде, дип яза. Барклай де Толлины кимсетеп, Кутузовны идеаллаштырып сурәтли. Императордан аны баш командующий итеп билгеләргә халык һәм армия сорый, фельдмаршал французларны җиңде, ул Бородино бәрелешендә зур җиңүгә иреште, дигән фикерләрне ассызыклый. Наполеонны Мәскәүне яндыруга гаепли (чынлыкта шәһәргә утны Мәскәү генерал-губернаторы Ростопчин боерыгы буенча төрткәләр – авт.).

1960 нчы еллар башында, сәяси «җепшеклек» заманында, халык ополчениесе, партизаннар хәрәкәте, крестьяннарның алпавытларга каршы көрәше һәм башка кайбер сюжетлар ныклап өйрәнелә. Наполеонның сугыш башлау турында Россиянең тышкы эшләр министры Александр Салтыковка 24 июньдәге нотасының тексты да 1962 елда дөнья күрә: сугыш игълан итмичә, кача-поса Россиягә басып кергән илбасар образы бераз йомшый төшә.

1960 нчы еллар уртасыннан тарих фәнендә торгынлык күзәтелә. Бу елларда совет тарихчылары Россиянең 1813–

1812 елгы ополчение. Рәссам: Г.Д.Алексеев.

1815 елгы чит ил походлары «реакцион рухлы» булуы, аның Француз революциясе казанышы – Наполеон төзегән империяне юкка чыгаруы турындагы Маркс-Энгельс-Ленин фикерләрен инкарь итеп, чит ил походлары, 1812 елдагы кебек, «азатлык сугышы» иде, Европа халыклары, ниһаять, Бонапарт изүеннән азат ителде, дигән концепциягә әйләнеп кайта. 1810–1811 елларда Россиянең сугышка әзерләнүе Наполеонның һөҗүменә каршы тору өчен кирәк булды дип раслана. Квазипатриотизм рухында, Михаил Кутузовның Аустерлиц янында илебез тарихында иң зур җиңелүләрнең берсенә дучар булганын онытып, ул һәрвакыт Наполеонны җиңде дип язалар. Бородино сугышында өстен булуын дәлилләү өчен, рус гаскәрләренең французларныкына караганда күбрәк булганын яшерәләр, ә французларның югалтуларын ике тапкыр арттырып күрсәтәләр (60 мең). Төгәлрәк әйтсәк, Брежнев чорында Сталин заманы бәяләмәләре кабат көч ала.

Шулай да 1960–1980 елларда чыганакларны бастыру үзгәртеп кору елларында кайбер яңалыкларны фәнни әйләнешкә кертүне тизләтә. Әйтик, тарихчылар Бородино бәрелешендә французларның – 134 мең, русларның 157 мең кешелек гаскәре булу хакында язалар.

1812 ЕЛДА КАЗАН ГУБЕРНАСЫНДАГЫ ЯҢА КҮРЕНЕШЛӘР

Чыннан да, Россия 1810 елдан башлап, сугышка ныклап әзерләнә. Бу, беренче чиратта, 1810–1811 елларда рекрут җыюны арттыруда (94589 һәм 120000 кеше-план 135 мең кеше була) күренә. Сугыш башланган 1812 елда рекрутларның буйларына, сәламәтлекләренә, тәннәренең тышкы кимчелекләренә карата булган таләпләр киметелә, хәрби хезмәткә 3 тапкырга күбрәк – барлыгы 166563 кеше чакырыла. Бу шулай ук 1811–1812 еллардагы хәрби министр Барклай де Толли тарафыннан, Франция гаскәреннән үрнәк алып, реформа үткәрүдә һәм хәрби чыгымнарны каплау өчен яңа салымнар кертүдә чагылыш таба. Әйтик, 1810 елның 2 февралендәге «Дәүләт бурычларын киметү чаралары» манифесты нигезендә, 1810 елдан башлап, 1 пот тозның бәясе 40 тиеннән 1 сумга күтәрелә, паспорт бирү, мәхкәмә эшләре буенча хакимият органнарының хезмәт күрсәтү бәясе (гербовой сбор) арта, крестьяннарга, мещаннарга, сәүдәгәрләргә салымнар күбәя. Бу сәясәт 1811, 1812 елларда яңа кануннар кабул итүгә китерә.

Казан губернасында яшәгән татарлар 1812 елгы Җиңүгә нинди өлеш керткәннәр соң? Моның өчен, иң беренче чиратта, ул чорның социаль структурасын белү кирәк.

Империядә яшәгән кешеләрнең хокуклары, аның дәүләт алдындагы бурычлары кайсы сословиегә теркәлгән булуыннан чыгып билгеләнә. Югары, өстенлекле катламга дворяннар һәм православие руханилары кергән.

Түбән катламда мещаннар һәм крестьянар теркәлгән. Казан губернасында дәүләт крестьяннары авылда яшәүчеләрнең 81%ын, уделныкылар (салымнары импертор гаиләсен асрау өчен сарыф ителгән) 2,5%ны, ә шәхси ирекләрдән мәхрүм алпавыт крестьянары 15,1%ны тәшкил иткән.

Шушы ике капма-каршы яктагы төркемнәр арасында хәрби-йомышлылар урнашкан. Бу казак, башкорт, мещеряк сословиеләре вәкилләре Казан төбәгеннән бигрәк, күршедәге Оренбург губернасында яшәгән. Шушы «аралыкка» салымнар түләүче сәүдәгәрләр катламы да кергән. Татар сәүдәгәрләре һәм мещаннары Казанда һәм Чистайда көн күргән.

1812 елның 6 июлендә Александр I француз армиясенең Россиягә басып керүе турында манифест чыгара. Императорның 6 июль һәм 18 июль манифестлары буенча Идел буе ополчениесе төзелә башлый: ул Казан, Түбән Новгород, Пенза, Кострома, Сембер һәм Вятка «тыл губерналарын» берләштерә. 6 июль манифесты Казанга ике атнадан соң, 18 июльдә килеп ирешә. Казан граждан губернаторы Борис Мансуров документның бер данәсен шунда ук Казан архиереена җибәрә, күбәйтеп, тиз арада өяз шәһәр ратушаларына һәм губерна шәһәре магистратына юллый. Текстны Казан гимназиясе директоры профессор Илья Яковкиннан татарчага тәрҗемә итә, тиз арада типографиядә 200 данә бастыралар һәм Казанда татар бистәләренә һәм авылларга тараталар. Торак пунктларында халыкны манифест тексты белән руханилар таныштыра.

Халык хәтеренә Наполеон исеме 1806 елны ныклап кереп урнаша. Александр I 1806 елның 30 ноябрендә кул куйган «Барча төбәкләрләрдә вакытлы ополчение яки милиция төзү һәм оештыру турында»гы манифестта Наполеонның Австрияне солых төзергә мәҗбүр итүен, Пруссияне басып алгач, Россия чикләренә якый башлавын, шуңа күрә, мәҗбүри саклану чарасы буларак, Франциягә сугыш игълан итүен белдерә. Патша даими армиягә ярдәмгә 612 мең кеше чакыра (Казан губернасына «план» 16 мең кеше була). Александр I Франциягә каршы игълан иткән сугышны «милли» сугыш дип атый һәм дворяннарны, сәүдәгәрләрне, мещаннарны, дәүләт крестьяннарын ополчениегә язылырга өнди. Дворяннар үзләренә кушылган санда крестьяннарны киендереп, коралландырудан тыш, һәрберсе өчен 3 айлык ризык бирергә һәм өчәр сум акча кертергә тиеш була. Мещаннар һәм крестьяннар ополчениегә ирекле кабул ителә, һәр шәһәр җәмгыяте үз сугышчысын матди кайгыртырга йөкләмә ала, губерна халкы ополчениегә коралллар белән ярдәм итәргә тиеш була. Нигездә алпавытлар тырышлыгы белән 1807 елда хәрби җитәкчелек карамагында 600 мең кешелек ополчение туплана, дөрес, алар сугышларда катнашмый, ләкин югалтулар зур булу сәбәпле, Франция белән Тильзит солыхы төзелгәч, патша алпавыт крестьяннарын хуҗаларына кире кайтарып тормый, рекрутка «күчереп», солдат хезмәтенә калдыра.

Халыкның патриотизмын арттыру максатыннан, Александр I кушуы буенча Изге Синод Наполеонны антихрист дип игълан итә. Ул Франциядә хакимиятне үз кулына алуда, Европа илләрен үзенә буйсындыруда, христиан диненнән читләшүдә, Мисыр походы вакытында мөселманнарны яклауда, ә Европада яһүдиләргә дин иреге бирүдә, синагогаларга һәм раввиннарга хөрмәт күрсәтүдә гаепләнә. Патша үзенең 1806 елның 13 декабрендәге указында Изге Синодның Наполеонны анафемага бирү «игъланын» урнаштыра һәм аның текстын, типографияләрдә күбәйтеп, барлык чиркәүләрдә һәрбер дини бәйрәм саен даими рәвештә укырга һәм гыйбадәткә килгән халыкны ополчениегә язылырга өндәргә боера.

1812 елгы патриотизм руслар арасында дини рух белән дә сугарылган була. Әлбәттә, бу фактор рус халкын мобилизацияләүгә уңай йогынты ясый.

ИСЕБЕЗГӘ ТӨШТЕКМЕ?..

Автор:
Луиза Янсуар

2020 елның язы безне – якыннарыбызга, туганнарыбызга һәм бигрәк тә яраткан шөгыльләребезгә вакыты җитмичә, тормыш куган, үз тирәнлекләренә күмелүдән инде ваз кичеп өлгергән токымны – өебезгә бикләп куеп «сынарга» булды. Без бу сынауны ничек кичеп чыгарбыз, нәтиҗәләре белән ничек килешербез дә кайтавазы никадәр озак яңгырар – монысы турында әлегә нибары фаразлый гына алабыз... Ә ул арада безгә һәрчак юаныч булган, ярдәмгә килгән Интернет-платформалар, аудиторияне җәлеп итү максатыннан, бик тә мавыктыргыч ташламалар һәм промокодлар системасы тәкъдим итә. Бөтен өлкәләрдә дә: ашау, ризыкны өйгә китертү, спорт товарлары белән тәэмин итү, чүп чыгарыр өчен өегезгә махсус ярдәмчеләр җибәрү... – рәхәтләнегез! Кино сөючеләр дә мондый затлы тәкъдимнәрдән мәхрүм түгел. Сезгә соңгы сезонның ике кызыклы проектын тәкъдим итәм.

«ТОРМЫШНЫ РӘХИМЛЕ ЗАТ ДИП БУЛМЫЙ, КОМИССАР ӘФӘНДЕ!..»

ВАВИЛОН-БЕРЛИН
(2017–2020)

Жанры:
неонуар, криминаль драма, триллер, детектив, тарихи драма

Сценарий авторлары һәм режиссерлар:
Том Тыквер, Ахим фон Боррис, Хендрик Хандлогтен

Сезоннары:
3 (4 нче сезон планлаштырыла)

Эпизодлар:
1 сезон – 8, 2 сезон – 8, 3 сезон – 12

Сериал турында әле беренче сезонга промо вакытында ук: «Инглиз телендә төшерелгән иң кыйммәтле немец сериалы», – дип тамга сукканнар иде. Беренче 2 сезонның бюджеты 40 милион евроны тәшкил итүе билгеле.

Һәм менә күрәбез: ул чыннан да кыйммәтле һәм затлы. Бар җәһәттән: декорацияләр, актерлар составы, костюмнар, махсус эффектлар, предметлар, детальләр... Барысы да ышандыра, бөтереп, үз эченә алып кереп китә, син XXI йөздән 1929 ел Берлинына атлыйсың.

Том Тыквер – сериалның төп идея авторы һәм төшерүчесе. Ул ике арадагы чикне алып ташлау һәм тамашачыны, комфорт зонасыннан чыгарып, әсәренгән хәлдә калдыру сәләтен әле беренче тасмаларында ук раслаган иде. Караганнар аның «Беги, Лола, беги», «Принцесса и воин», «Париж, я люблю тебя», «Парфюмер», «Любовь втроем», «Облачный атлас» фильмнарын онытa алмыйдыр дип уйлыйм: алар кадрлап-кадрлап күз алдында тора.

«Вавилон-Берлин»ның 1 нче сезоны 2016 елның маенда төшерелә башлый, 8 айга сузыла. Ул искиткеч зур уңыш казанды, тамашачы проектны кабул итте, «ыргакка эләкте». Сериал продюсерларның да, компаниянең дә, фанатларының да өметләрен аклады.

Бер еллык паузадан соң, 2018 елда, аның 2 нче сезоны тәкъдим ителде, 3 нче сезон исә 2019 елның маенда төшерелеп бетеп, узган елның азагында экраннарга чыкты. 2020 елда, 3 ай эчендә, ул барлык эре платформаларда да иң югары рейтинглар яулап өлгерде. Сүз уңаеннан, 3 нче сезонны әлегә барлык платформаларда да язылу буенча карау мөмкинлеген бирмиләр, сезонны махсус сатып алып карарга кирәк. Ул – топ-сериаллар исемлегендә чөнки. Әмма бу – популяр проектлар белән була торган гадәти хәл, беләбез.

«Вавилон-Берлин» сериалының төп интригасы нәрсәдә соң? Фашизм режимы кергәнчегә кадәрле, ике бөтен-

Фото: https://www.ivi.ru/, https://okko.tv/, https://www.kinopoisk.ru/ сайтларыннан алынды.

дөнья сугышы арасындагы Германиянең тарихи һәм сәяси тукымасын тукып күрсәтү – шулай вәгъдә итте продюсерлар. Шуңа да нигездә тарихи сериал көтелде. Әмма Тыквер чиста документалистика һәм тарихи эзлеклелек буенча гына китсә, Тыквер булмас иде, беләбез! Юк, ул безнең аңыбызны символика һәм абсурд, эзоп теле, ә вакыт-вакыт кычкырып торган сатира, памфлет, гротеск белән «шартлата». «Вавилон-Берлин» – жанрлар синтезы, стилизация һәм пастиш, эклектика тантанасы. Нинди виртуозлык, дип сокланып карадым мин һәр 3 сезонны һәм, тәмамлангач, «тизрәк дүртенчесен!» дип өндәргә генә калды... (Ә ул арада дөнья үзизоляциягә тукталып калган иде инде).

«Уолл-стрит джорнэл»га биргән интервью вакытында Том Тыквер сериал турында тәфсилләп болай сөйли:

«Ул заманда кешеләр Веймар Республикасы дип аталган яңа җәмгыять конструкциясенең ни дәрәҗәдә тотрыксыз булуын ваемламый әле. Алар, нинди шартларга эләгүләрен аңлап җиткермичә, яшәргә тырыша. Тырмаша, дисәк, дөресрәк булыр. Безне бу тема ни өчен җәлеп иттеме... Чөнки демократия төшенчәсенең соңгы елларда ни дәрәҗәдә уалырга мөмкин, ни дәрәҗәдә иллюзор икәнлеген күзәтергә туры килә...

1929 елда яңадан-яңа мөмкинлекләр барлыкка килә. Хатын-кызларның да җәмгыять тормышында катнашырга мөмкинлеге арта. Бигрәк тә – хезмәт базарында. Ул чактагы Берлин яңа карашлар, фикерләр, фәлсәфә, яңа сәнгать – театр, музыка, журналистика, иҗат белән кайнап тора. Әлбәттә, без Веймар Республикасының «алтын» дип атап йөртелгән чорына мөрәҗәгать иттек. Әмма аның инде эченнән чери башлаган булуын күрсәттек, идеаллаштырмадык.

Кешеләр, соңыннан Гитлер Германиясендә булган хәлләрне исәптә тотып, аңа карата идеалистик караштa торырга да мөмкиннәр. Ләкин республика чоры Германия тарихындагы бик авыр вакыт була. Беренче Бөтендөнья сугышыннан исән калган халык һаман аның сөременнән айный алмый, тән һәм җан җәрәхәтләреннән тилмерә, ачлыктан, фәкыйрьлектән җәфа чигә, ә «югарыдагылар» типтерә...»

Шунысы да бар: Тыквер мәктәптә укыганда, Веймар Республикасы турында дәресләрдә бернәрсә дә искә алынмый. Шуңа да сериалны тудыручылар аның Германиядә яшьләр арасында популяр булуы, хәтта югары сыйныфларда мәктәпләрдә күрсәтелүе белән горурлана. «Тарихның «ак таплары» гел булачак, һәркем үзен борчыганы турында сөйләргә хокуклы», – диләр алар.

Тыквер һәм аның фикердәшләре сериалны ике төп герой – полиция инспекторы Гереон Рат һәм тикшерүче булырга хыялланучы тынгысыз табигатьле Шарлотта Риттер белән алар перефириясендәге затлар тирәсендә әйләндерә, дип тәкъдим итә, нигездә, рецензентлар. Әмма килешмәс идем, минемчә, «Вавилон-Берлин»ның чын тормышчанлыгы да шунда: ул гаҗәеп күптармаклы, катлы-катлы, һәм геройларның берсен дә эпизодлар дәвамында күз уңыннан ычкындырмыйсың, аларның «төп» һәм «эпизодныкы»сы юк диярлек. Әлеге күппланлылык үз эшен эшли дә: караучыда бу вакыйгаларның эчендә булу тойгысы барлыкка килә. Ә димәк ки, бүгенгегә проекция ясап карап, чорын, үзен һәм кылганнарын/кылмаганнарын бәяләргә дә мөмкинлеге арта төшә.

Тагын бер үзенчәлеккә тукталасым килә: сериалның саундтрегы – меломаннар өчен чын бүләк. Фильмнарына музыканы үзе иҗат итәргә яратучан Тыквер төшергән тасмада бу гаҗәп тоелмаска да тиештер болай үзе. Әмма монда Тыквер Джонни Клаймен, Райнхольд Хайль, Кристиан Ярви, Джин Прицкер белән бергә гаҗәеп яхшы тандем тудыра алуга ирешкән.

Дөньяның яңа Вавилоны турындагы тарихның чишмә башын эзләүчеләр табылса, китабына мөрәҗәгать итәргә дә була. 1 нче сезон шаулаганнан соң, 2017 елда, «Эксмо» аны «Кинопремьера мирового масштаба» сериясендә бастырып чыгарды. Шәхсән мине Фолькер Кучер романы әллә ни тәэсирләндермәде, әмма параллельләр уздырырга теләүчеләр өчен – үзенчәлекле чыганак. Тарихи җирлек һәм сюжет линияләре, әлбәттә, детектив форматында нәкъ менә биредән башлана. Әмма сценарийда алар инде бөтенләй икенче масштаб һәм укылыш ала...

Кыскасы, мин сезне галиҗәнап сериалга – аның сихри һәм кабатланмас дөньясына чакырам! Нәкъ фильмдагы бер герой әйткәнчә: «Күзләребезне йомыйк та – алга! Ә, юк, күзләребезне ачыйк та – алга!»

«СЕР БЕР ЧИШЕЛМИ КАЛМЫЙ...»

СКРЫТЫЕ
(2019–2020)

Жанры:
фэнтези, психологик триллер, криминаль драма

Сценарий авторлары һәм режиссерлар:
Джонатан Сьоберг, Дэвид Беррон, Бьёрн Пакуалин, Даниель ди Градо

Сезоннары:
1 (2 нче сезон планлаштырыла)

Эпизодлары:
8

Швед сериалларының, киноиндустрияне яулап, үз лаеклы урынын алуларына инде шик юк. Аларның үз атмосферасы: томанлы-серле, салмак, куе вакыт агымына корылган. Шул ук вакытта син эчке борчуыңны, шөбһәңне баса алмыйсың, азаккача җиңел суларга кыймыйча, ни булып бетәсен ваемлыйсың.

«Скрытые» бик гадәти көндәлек яссылыкта башланып китә – безгә сценаристлар белән режиссерлар «алдавыч» тәкъдим итә, янәсе йотасызмы-юкмы. Кемне күрәбез? Күңел төшенкелеге табигый халәте булып әверелгән гап-гади бер егет: акчага мохтаҗ, тәзелештә тиен-миенгә эшләп йөреп, тормышының очын-очка ялгый. Башкалар белән аралашырга да әллә ни атлыгып тормый, социофоб – маңгаена язылган... Әмма! Әмма нидер дөрес түгел, нәрсәдер сәер икәнлеген чамалыйсың...

Филипп Александерсонның «Перворожденный» романына нигезләнеп эшләнгән сценарий динамикасы белән «Вавилон-Берлин»нан баштанаяк аерылып тора. Әмма аның эчке нерв җепселләре тартылган: син шуларның пульсациясен тояр өчен күзеңне экраннан алмыйсың. Романы һәм аның сюжеты турында язучы үзе менә нәрсә ди:

> *«Мине һәрчак тормышның өске ягында түгел, ә яшеренеп, аскы катламында яшәүче көч кызыксындыра иде. Фантазияләрем сериал геройлары аша экранга күчте, бу – үзе фантастика!»*

Төп геройларны «Корона» сериалы аша популярлык казанып өлгергән, бруталълеге һәм романтик амплуаны берләштерә алуы белән җәлеп иткән Аугуст Витгенштайн һәм кайчандыр Бондның сөйгәнен уйнаган беренче Польша актрисасы Изабелла Скорупко гәүдәләндерә. Бер-берсе белән, беренче карашка, берничек тә кисешмәскә тиешле, әмма котылгысыз рәвештә үзара тартылучы тормыш линияләре башта ике параллельдә сак кына шуа, яшерен эзләр сала. Без бу ике каһарманда аларны яшәтүче дә, шул ук вакытта һәлакәткә илтүче дә көч барлыгын тоябыз.

Variety өчен әңгәмәсендә Изабелла Скорупко бу проектны күңеленә бик тә якын алуы, аның үз язмышына аваздаш икәнлеге белән уртаклашты. Һәм героинясы Эльдхның аңа уйнарга насыйп булган иң миһербанлы, кече күңелле, шул ук вакытта искиткеч көчле образ булуын да ассызыклады ул.

Фэнтези белән криминал, триллер белән психологик драма чигендә торган әлеге сериалның буеннан-буена безгә уңайсыз: үзебезнең ваемсызлыгыбыз, җәмгыятьнең гаделсезлеге, сәясәтнең сәерлеге, хәтта ки абсурд, абстракт булуы өчен... Шул ук Изабелла Скорупко, сериал экраннарга чыккач, болай диде:

> *«Без чәчәк аткан җәмгыятьтә яшибез» – шулай дияргә яратабыз. Безгә куркыныч, хәтәр янамый, дигән ышаныч җылыта күңелебезне. Әмма хәтәр – кул сузымында гына. Һәм кул сузымында гына – язмыш бөтереп алып, аяныч хәлләргә дучар ителүчеләр дә. Без аларны күрмәскә тырышабыз: документлары юк беженецлар, бомжлар – барысы да бу система кысаларыннан чыгарып ташланган. Үзләре гаеплеме? Җиңел аклану... «Скрытые» сериалының сценарием укый башлауга ук аңладым: мин бу сериалда төшәчәкмен».*

Режиссер һәм операторларның Стокгольмны – шәһәрне һәм аның урамнарын, биналарын, локацияләрен – ничек төшерүләре сокландыра: кадрларда шәһәр фон гына булып калмый, ул яши. Һәм әлеге шәһәр эчендә, лабиринтка эләгеп квест чишкәндәй, син дә яшисең. Даими рәвештә кое-йортларның берсенә килеп туктаган һәм эчкә узган кара машинаның инде юкка гына килмәвен аңлыйсың – бу кадр безгә һәрвакыт өстән күрсәтелә. Ни дәрәҗәдә котылгысыз хәл икәнлеген ассызыклар өченме, әллә безнең барыбызның да үз стереотиплары төрмәсендә яшәвебезгә ишарә итәләрме? Иң мөһим каһарманнарның берсен – кешелек архивын туплаучыны уйнаган бәләкәй генә кызны күргәч, янә бер мәртәбә исеңә килә алмый торасың: бертуган Стругацкийлар романы буенча 2006 елда Константин Лопушанский төшергән «Гадкие лебеди» да искә килеп төшә, Орсон Скотт Кард романы буенча Гэвин Худ экранлаштырган атаклы «Игра Эндера» картинасы да...

«Скрытые» сериалын промо һәм продакшн вакытында продюсерлар урбанистик фэнтези буларак тәкъдим итте һәм Скандинавиянең бу юнәлештә тормыш базарында да, сәнгать өлкәсендә дә алдынгы булуын әйтте. Паранормаль вакыйгаларны чынбарлык яссылыгына сыйдыра алган режиссерларның һәркем өчен дә аңлаешлы һәм тәэсирле тарих тудыруы да, бәлки, әнә шуның бер чагылышыдыр? Чынлап та, «Миллениум» сериясеннән – Стиг Ларссон эпопеясеннән башланган бу клаустрофобик йомыклык белән берррәттән, дөньяга яралары, җәрәхәтләре белән шыр ачык булу... Скандинавия проектларының иң характерлы билгесе әнә шул бугай...

«Скрытые» режиссеры Джонатан Сьоберг үзе, артык фәлсәфәгә бирелеп тормыйча, бик гадәти генә аңлатма бирә сериалга:

> *«Бу – өлкәннәр өчен фантазия, чөнки алар гадәттә бик тирәндә нindiдер сер яшереп йөртә. Көннәрдән бер көнне ул сер барыбер чишелми калмый... Һәм еш кына үзләренең кабатланмас булуын онытып җибәрә, стандарт кагыйдәләргә ияләшә, кысаларга кереп утыра. Үзләре үк теләп! Актерларга әнә шул кысалардан атлап чыккан катлаулы персонажларны уйнарга туры килде. Изабелла героинясына хас булган эмпатия һәм гуманлылыкка рәхмәт: нәкъ шул сыйфатлар аңарга ике дөнья арасында арадашчы, ул дөньяларны тоташтыручы булырга ярдәм итте».*

Яхшыга илтәме без, кешеләр, үзендә яшереп йөрткән (ә бәлки, инде барлыгын да оныткан, онытырга тырышкан) серләр? Нәрсәгә хезмәт итә синең омтылышларың, гамәлләрең нәрсәгә китерә?!

«Син уянырга тиеш түгел идең», – ди төп геройга аның язмышы өчен җаваплы берәү. «Әмма мин уяндым!» – ди Йонас, эчендәге давылны тыярга тырышып. Һәм аның җавабына каршы көлемсерәүле дә, катгый да сорау яңгырый: «Йә, кем инде син хәзер?»

...Ә өстәл уенындагы уемтыларга кешелек язмышын хәл итәргә тиешле ак һәм кара шарлар тәгәри: шобага салалар. Кайсылары күбрәк?

...Һәм, чынлап та, кем без хәзер?
Исебезгә төштеме?
Дөресрәге, төштекме исебезгә?!

МАХСУС ПРОЕКТ

— 53нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Фото «Татар-информ» МАнан алынды

Борис Тихомиров, «Казан Гипронииавиапромы» АҖнең генераль директоры, апрель аенда үзенең «Казан Гипронииавиапромы» АҖндә эшләвенең 50 еллыгын билгеләп үтә.

Александр Ватагин,
«ОДК-Климов» АҖнең башкарма директоры

Фото «ОДК-Климов» АҖннән алынды

Реклама

Авиасәнәгать өлкәсендә профессионал

– Хөрмәтле Борис Иванович!

«ОДК-Климов» АҖ коллективы исеменнән Сезне хезмәт эшчәнлегегезнең 50 еллыгы белән чын күңелдән котлыйм! Тармакка ярты гасыр дәвамында тугры хезмәт итүегез дәверендә Сез Татарстан һәм ил күләмендә авиация сәнәгатенең иң хөрмәтле хезмәт иясе дәрәҗәсенә күтәрелдегез. Шушы еллар күпме истәлекле очрашулар, хәлиткеч вакыйгалар, җаваплы карарлар һәм менә дигән нәтиҗәләр белән тулы.

Сез һәрвакытта да югары осталык үрнәге күрсәтәсез, оборона сәнәгате предприятиеләренең мәнфәгатьләрен яклыйсыз, җитештерүне модернизацияләү һәм яңа технологияләр куллануның башында торасыз.

Сезнең мактаулы исемнәрегез, тармак һәм дәүләт бүләкләре генә дә күп нәрсә турында сөйли. Шунысы мөһим: һөнәри осталыгыгызны тану өстенә Сезнең ышанычлы партнер һәм яхшы кеше дигән даныгыз бар. «ОДК-Климов» АБ белән «Казан Гипронниавиапромы» АҖ арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре коруда, катлаулы проект-төзелеш эшләрен башкаруда Сезнең казанышларыгыз бәһаләп бетергесез.

Чын күңелдән Сезгә ныклы сәламәтлек, иминлек, бетмәс-төкәнмәс көч һәм эш дәрте, яңадан-яңа уңышлар телим!

Фатих Сибагатуллин, җиденче чакырылыш РФ Дәүләт Думасы депутаты, май аенда үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Шамил Яһүдин,
«Татнефтепром-Зүзәй нефть» АҖнең генераль директоры, VI чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты

Фото «Татнефтепром-Зүзәй нефть» АҖннән алынды

Реклама

Ватанпәрвәр һәм профессионал

– Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович!

Безнең компания хезмәткәрләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Бүген без Сезгә Татарстан һәм ил иминлеге хакына башкарган эшләрегез өчен олы рәхмәтләребезне белдерәбез! Сезнең барлык һөнәри эшчәнлегегез республиканың муниципаль районнар территориясендәге үсешенә, икътисад һәм авыл хуҗалыгының хәлен яхшыртуга багышланган. Олы тәҗрибә, оештыру сәләте, ватанпәрвәрлек, һөнәри осталык һәм олы йөрәкле булуыгыз Сезне төбәктәге иң сәләтле җитәкчеләрнең берсе итеп танытты. Җиденче чакырылыш РФ Дәүләт Думасы депутаты буларак, Сез республика халкының мәнфәгатьләрен федераль парламентта кайгыртасыз.

Сезнең белән озак еллар дәвамында таныш булуыбыз, нәтиҗәле хезмәттәшлек итүебез һәм яхшы мөнәсәбәтләрдә торуыбыз белән горурланам. Сезнең кешелеклелек сыйфатларыгыз, булдыклы, эшлекле һәм зирәк булуыгыз һәрвакыт сокландыра килде.

Хөрмәтле Фатих Сәүбәнович! Шушы истәлекле көндә чын йөрәктән Сезгә җаваплы вазыйфагызда уңышлы эшчәнлек алып барырга, кыю башлангычларыгызга тормышка ашарга язсын, һәрвакыт уңыш юлдаш булсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет һәм сәламәтлек телим!

Анатолий Иванов, ТР Мамадыш районы башлыгы, май аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Рәис Гатиятуллин, «Мамадыш ТКИ» ҖЧҖ директоры

Туган җирендә тәрбияләнгән

– Хөрмәтле Анатолий Петрович!

Безнең предприятие эшчеләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм!

Сез язмышыгызны үзегез туган җир – Мамадыш районы белән бәйләгәнсез. Сезне шушы җир тәрбияләп үстергән, сезгә хас эшлекле һәм шәхси сыйфатлар озак еллар дәвамында районны уңышлы һәм нәтиҗәле итеп яңа үрләргә алып барырга мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы башлыгы вазыйфасында үсешкә ирешүдә төрледән-төрле бурычларны хәл итәсез, аны үстерү, ныгыту, халыкның тормышын яхшырту хакына хезмәт итәсез. Сезнең җитәкчелектә район халкы иминлеге өчен эре социаль-икътисадый проектлар гамәлгә ашырыла.

Чын мәгънәсендә лидер һәм талантлы оештыручы буларак, Сез безнең өчен Мамадыш символы булып торасыз, искиткеч хезмәт сөючәнлек, иң катлаулы бурычларны да эзлекле һәм төгәл итеп хәл итү үрнәге күрсәтәсез. Сезнең белән таныш булуыма шатмын, торак-коммуналь хуҗалык тармагына караган проблемаларны хәл иткәндә, һәрчак сүздә торучан булуыгызга сокланам. Безгә күрсәткән бәһаләп бетергесез ярдәмегез һәм теләктәшлегегез өчен бик зур рәхмәт.

Хөрмәтле Анатолий Петрович! Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, күркәм гамәлләрегездә бетмәс-төкәнмәс илһам һәм көч, яңадан-яңа идеяләр телəп калам! Башлаган һәр эшегез уңышлы тәгәлләнсен, куйган максатларыгызга ирешергә язсын, Мамадыш районы иминлеге хакына корылган барлык планнарыгыз чынга ашсын!

Фото «Мамадыш ТКИ» ҖЧҖнән алынды

Илһам Вәлиев, «ТАЛ-Агро» ИК» ҖЧҖнең генераль директоры

Лаеклы юл

– Хөрмәтле Анатолий Петрович!

«ТАЛ-Агро» Идарәче компаниясе хезмәткәрләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилей уңаеннан ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Бу көн – Татарстан иминлеге хакына куйган хезмәтегез өчен Сезгә рәхмәт белдерергә менә дигән форсат. Сез республика күләмендә иң күренекле, иң нәтиҗәле идарәчеләрнең берсе, лаеклы тормыш юлыгыз, максатчанлыгыгыз, югары һөнәри осталыгыгыз тирән ихтирам уята. Туган районыгызның патриоты, бәһаләп бетергесез хезмәт тәҗрибәсенә ия талантлы җитәкче буларак, Сез Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы башлыгы вазыйфасында иң җаваплы бурычларны үтисез һәм барлык дәүләт институтларының социаль тотрыклылыгын һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итәсез. Сез һәрвакытта да төбәкнең авыл хуҗалыгы үсеше һәм агросәнәгать тармагын модернизацияләү мәсьәләләрен шәхсән үз контролегез астында тотасыз.

Сез Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы ирешкән казанышларының башында торасыз, аның югары потенциалы һәм перспективалы булуы, шулай ук туристик һәм инвестицион яктан җәлеп итүчәнлеге дә Сезнең исем белән бәйле. Бик күпләргә билгеле булганча, Сез бүгенге көндә иң кирәкле сыйфатларга ия – еракка карап эш итәсез, дәүләт куйган мөһим бурычларны үтәүгә эшлекле якын киләсез. Тирән белемегез, оештыра белү талантыгыз, эшне нәтиҗәле итеп башкаруыгыз белән аерылып торасыз.

Хөрмәтле Анатолий Петрович! Сезгә җаваплы вазыйфагызда уңышлар телим, максатларыгызга ирешергә язсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, күңел көрлеге, бәхет һәм уңышлар юлдаш булсын!

Фото «ТАЛ-Агро» ИК» ҖЧҖнән алынды
Реклама

Нияз Шәмсетдинов,
«Шәмсетдинов»
КФХ җитәкчесе, ТР авыл хуҗалыгының атказанган хезмәткәре

Тотрыклылык һәм чәчәк ату юлында

– Хөрмәтле Анатолий Петрович!

Безнең крестьян-фермер хуҗалыгының барлык хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән Сезне олы юбилеегыз белән котлыйм!

Бу көнне без Сезгә район территориясендә авыл хуҗалыгы буенча башкарган эшләрегез һәм ярдәмегез өчен рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез. Сез бөтен көчегезне куеп, туган районыгызның үсеше хакына хезмәт итәсез һәм зур уңышларга ирешәсез. Татарстан Республикасының Мамадыш муниципаль районы башлыгы буларак, Сез район халкы тормышының тотрыклылыгына ышаныч уятасыз, бизнес өчен перспективалар ачарга ярдәм итәсез, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, медицина, мәгариф, мәдәният һәм спорт мәсьәләләрен контрольдә тотасыз. Менә 10 ел инде сез туган районыгызда җитәкчелек итәсез, шушы вакыт эчендә мул тормышлы мамадышлылар буыны үсеп җитте, районның уңышлары күзгә күренеп артты.

Сезне үз эшенең остасы, тәҗрибәле финансист, алга карап эш итәргә күнеккән зирәк җитәкче, сизгер күңелле меценат буларак беләләр. Без, кыр хезмәтчәннәре, аграр өлкәгә һәм аны модернизацияләүгә биргән игътибарыгызны күреп, Сезгә ышанабыз һәм таянабыз.

Хөрмәтле Анатолий Петрович! Бүгенге күркәм бәйрәм көнендә барлык котлауларга кушылып, Сезгә Мамадыш районы иминлеге хакына эшегездә алга таба да зур уңышлар телибез! Хезмәтегез бары тик уңай кичерешләр һәм нәтиҗәләр генә, гаиләгез җылылык һәм иминлек алып килсен!

Үзегезгә һәм якыннарыгызга бәхет, уңышлар һәм ныклы сәламәтлек телим!

Реклама Фото «Шәмсетдинов» КФХнан алынды

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2020 елның
2 яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 933 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 933 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7077 **татар телендә**

П 7076 **рус телендә**

Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

90 нчы еллар буыны киләчәкне **НИЧЕК** булдырган

Татарстан Президенты хыялларын **НИЧЕК** тормышка ашырган

Татарстан Ельцинга толерантлылыгын **НИЧЕК** күрсәткән

Татарстан очучылары әсирлектән **НИЧЕК** качканнар

Фото: Александр Ефремов

БАРЫБЫЗ ДА ӨЙДӘ ВАКЫТ

Урамнар – буш, барыбыз да өйләребездә. Беркая ашыгасы юк, гаилә белән иртәнге, төшке, кичке ашларга җыелырга мөмкин чак. Сөйләшеп утырырга, онытыла башлаганнарны искә төшерергә, яңарак берәр нәрсә уйлап табарга җай чыккан мәл. Бергәләп кино карарга мөмкин. Балаларга кычкырып китап укырга. Өлкәнрәкләренә дәрес әзерләргә булышырга. Бу вакыт безгә очраклы гына бирелмәгән. Өйләрегездә калыгыз. Тормышта иң мөһиме гаилә икәнен онытмагыз!



Казан. Бауман урамы. Апрель, 2020 ел

Демократиядән башка социализм юк
В. И. ЛЕНИН

ТАТАРСТАН
تاتارستان

Оештыручысы —
КПССның Татарстан
республика комитеты



Иҗтимагый-сәяси һәм
теоретик журнал

1920 елның декабреннән бирле чыга

7
1991

Татар һәм рус телләрендә айга
бер тапкыр басыла

Казан
КПССның Татарстан
рескомы нәшрияты

ТР Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлеге фондларыннан

Рафаэль МОСТАФИН

«АРТТА КАЛГАН НАДАН ХАЛЫК» ҺӘМ БАШКА ИДЕОЛОГИК ШТАМПЛАР ТУРЫНДА

КАЗАНДА ТАТАР ВУЗЛАРЫ БУЛГАНМЫ?

Бервакыт Оренбург Дәүләт музеенда казынганда мин бер документка тап булдым: анда әйтелгәнчә, патша властеның соңгы елларында Оренбург диния нәзарәте җирләрендә 7800 мәхәллә булган икән (һәр мәхәлләдә берәр мәктәп яки мәдрәсә, кайберләрендә исә берничә дә булган). Ә XX гасырның сиксәненче еллар уртасында Оренбург өлкәсендә соңгы татар мәктәбен яптылар. «Прогресс», кем әйтмешли, күз алдында.

Ә менә икенче бер документ, бусы инде безнең республика архивыннан. Анда 1908 елда Казанда 36 мәдрәсә һәм алар каршында 17 мәктәп булуы әйтелә. Шул вакыттан бирле шәһәрдә татарлар саны ун тапкырдан күбрәккә арткан. Ә милли уку йортлары калмады диярлек. Хәзер без аларны зур авырлык белән генә торгызырга тырышабыз.

Ә бит шул 36 мәдрәсәнең 12 се урта, 12 се тулы булмаган югары, 12 се югары типта булган. Ә нәрсә ул югары типтагы мәдрәсә? Ул асылда, әйтик, хәзерге шәрык телләре институтында алына торган кебек гуманитар белем биргән. Андый мәдрәсәләрне тәмамлап чыгучылар кимендә өч тел: борынгы төрки, гарәп, фарсы телләрен, еш кына төрек телен дә белгәннәр. Шәрык тарихы һәм мәдәнияте, бигрәк тә мөселман тәгълиматлары өлкәсендә җитди белем алганнар, логик фикерләү өлкәсендә күнекмәләргә һәм – монысы да бик мөһим – ныклы әхлакый принципларга ия булганнар. Шундый мәдрәсәләрдә алынган белемнең Октябрь революциясеннән соң рәсми рәвештә югары белемгә тиңләштерелүе тикмәгә түгел. Дөрес, баштагы елларда гына. Аннары моның өчен... инде утыртканнар.

Монда да бер чиктән икенчесенә ташлану, андый уку йортларын күккә чөеп мактау ярамас. Мондый мәдрәсәләрдә хөкем сөргән мәгънәсез хәреф ятлаудан, схоластикадан әче көлгән Габдулла Тукай үзенчә хаклы булган. Тукай мәдрәсәләрне, аларда укытуны яхшырту, тормыш таләпләренә якынайту өчен

ТР Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлеге фондларыннан

тәнкыйтьләгән. Без исә уку йортларының бу тибыннан гомумән ваз кичүне күбрәк күргәнбез.

Шундый сорау туа: бүген, космос һәм ФТР гасырында мәдрәсәләр нәрсәгә? Һич югы Шәрык мәдәниятенә, аның дөньяга карашына, яшәү рәвешенә якынаю өчен булса да, дияр идем. Шәрык бит ул үзенә бер дөнья, Көнбатышка охшамаган үзенчәлекле цивилизация. Охшамаган дигән сүз – начаррак яисә түбәнрәк дигән сүз түгел. Икенче нәрсә, кыйммәтләр, координатлар бүтән. Көнбатыш мәдәниятендә, Көнбатыш кыйммәтләрендә тәрбияләнгән кешегә Шәрыкнең җанына төшенү кыен, еш кына мөмкин дә түгел. Тик шуннан башка дипломатияне, сәүдәне ничек уңышлы алып барырга, мәдәни һәм фәнни элемтәләрне ничек үстерергә?

Ә бит революциягә кадәр татар мәдрәсәләрен тәмамлаучылар Шәрык мәдәниятенә бик табигый кушылып, берегеп китә торган булганнар. Күп кенә татар шәкертләре Сүриядә, Мисырда, Төркиядә белем алуларын дәвам иткәннәр. Бу традиция, Болгар ханлыгы чорыннан ук башланып, Октябрь революциясенә кадәр дәвам итә. Мәсәлән, татарның күренекле дин галиме Ярулла Биги (1875 елда туган) башта Казандагы икенче мәдрәсәдә укыган, аннары белем алуын Бохарада дәвам иткән, аннан Гарәбстанга киткән, Мәккәдә, Мәдинәдә, Каһирәдә, Истамбулда атаклы мөгаллимнәрнең лекцияләрен тыңлаган. Революциягә кадәрге татар язу-чыларының да күбесе Шәрыкта белем алган. Мәсәлән, Шәриф Камал Истамбул һәм Каһирә мәдрәсәләрендә укыган. Дәрдемәнд белән Фатих Кәрими Истамбул университетын тәмамлаганнар.

Шул ук вакытта татарларның цивилизацияле дөньясы Көнбатыштан, аның мәдәниятеннән дә үзен кытай стенасы белән аерып куймаган. Мәсәлән, шул ук Кәрими революциягә кадәр Германиядә, Бельгиядә, Франциядә, Италиядә, Австро-Венгриядә, Сербиядә, Болгариядә булган, шулар турында мавыктыргыч сәяхәтнамә дә язып калдырган (Ф. Кәрими. Аурупага сәяхәт. Казан, 1902 ел). Аңа тылмачның кирәге булмаган, чөнки Шәрык телләреннән тыш ул француз телен бик шәп белгән, немецча да аңлаша алган. XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында татар зыялыларының кайбер вәкилләре (әлбәттә, хәлле катлаулардан) Мәскәү, Петербург вузларында, чит илләрдә укыганнар. Ягъни Садри Максуди берүзе генә андый булмаган.

Шушы уңайдан минем тагын бер шомарып беткән идеологик штампка кагылып үтәсем килә. Революциягә кадәрге йөз ун ел эчендә Казан университетын ундүртме, унҗидеме (төрле авторларда төрлечә) татар кешесе тәмамлаган дигән сүзләр дистә еллар буена мәкаләдән мәкаләгә күчеп йөрде. Әмма университет тәмамлаучыларның чын исемлекләрен алып карауга ук бу санны ким дигәндә ун тапкыр арттырырга туры килде.

Хәер, ул кадәр ерак барып торасы да юк! Инде безнең көннәрдә, үзгәртеп кору чорында «Советская Татария» газетасында «Гаяз Исхаки, он же Штольц» дигән мәкалә дөнья күрде. Аның авторлары «татар Лев Толстое» дип йөртелгән олуг реалист язучы Гаяз Исхакиның әллә Польша, әллә Германия разведкасында вак бер агент булып йөрүен тыры-шып-тырышып расламакчылар. Хәлбуки, Г. Исхаки үз заманының иң укымышлы һәм мәдәниятле кешеләреннән берсе, дәүләт башлыклары тиң күреп сөйләшерлек кеше булган. Мәсәлән Г. Исхакины Польша президенты Пилсудский белән күп еллар дәвамында шәхси дуслык җепләре бәйләгән, алар Архангельск ягында сөргендә танышкан булганнар. Әйе, язучы большевиклар белән бәхәсләшкән, Сталин режимын дошман күргән, компартиянең милли сәясәтен танымаган. Әмма ул «шпион», «агент» булмаган, була да алмаган. Шәхеснең масштабы башка!

«Татарстан» журналының махсус проекты

БУЫННАР

Тиздән Татарстан Республикасына 100 ел була. Түгәрәк дата бик җитди: гасыр белән генә исәпләнми, ә үзе бер тарихи дәверне тәшкил итә!

2020 елның декабрендә шулай ук 100 еллыгын билгеләячәк «Татарстан» журналы уртак юбилей уңаеннан «Буыннар» дип исемләнгән проект әзерләде, ул анда Татарстаныбызның олы тарихын ясаган шәхесләр турында сөйли. Без инде 20 нче елларда республиканы оештырган шәхесләр турында сөйләдек. Моңа кадәр күрелмәгән энтузиазм һәм коточкыч кырыс репрессияләр елларында яшәгән 30 нчы еллар буыны турында. Бөек Ватан сугышын кичеп, аннан җиңүче булып чыккан 40 нчы еллар буыны турында. Сугыш афәте җимергән шәһәрләрне торгызган, нефть сәнәгатен күтәргән 50 нче еллар буыны турында. Галәмне буйсындырган 60 нчы еллар буыны турында. Иҗат итеп, төзелешләрдә эшләп, үзенә торгынлык еллары дигән мөһер сугыласын белмәгән 70 нче еллар буыннары турында. Без йә тумышыбызны, йә балачагыбыз, йә яшьлегебезне хәтерләткән 80 нче еллар буыны турында... Бүген без 90 нчы еллар буыны турында сөйләрбез.

1990 нчы еллар

90 НЧЫ ЕЛЛАРНЫҢ ДАВЫЛЛЫ БУЫНЫ

... Заманны сайлап алмыйлар – язмышыңа туры килгән заманда яшиләр, кирәк булса... исән калу өчен көрәшәләр. 90 нчы елларда без СССР, КПСС, ВЛКСМ белән хушлаштык... Пионерлар-октябрятлар һәм башка яшь натуралистлар белән саубуллаштык. Партия безнең юлбашчы булудан туктады, үткәннәр үткәндә калды, ә киләчәк килеп җитмәгән иде әле. Әмма шушы ике арада калган 90 нчы еллар буыны киләчәк өчен бик күпне эшләп калды: Татарстан суверенитет алды, газлаштырылды, тузган торактан котылды, метро төзи башлады... Һәм давыллы еллардан җиңүче булып чыкты. Хәер, башкача була да алмый иде.

1 нче ТАРИХ

БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТ ЧОРЫ

Минтимер Шәймиев һәм булмый калу ихтималы булган вакыйгалар

2 нче ТАРИХ

ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧҮ

Казанлыларның фатир мәсьәләсе ничек хәл ителә

3 нче ТАРИХ

БАШТА СНАЙПЕРЛАР, АННАН СОҢ – ЕЛЬЦИН

Татарстанда лимоннар үсүен күреп гаҗәпләнгән Мәскәү кунаклары турында

4 нче ТАРИХ

ЗИЛӘ ВӘЛИЕВАНЫҢ СӘЯСИ КУХНЯСЫ

Журналистның сәясәтчегә әйләнү тарихы

5 нче ТАРИХ

КАЗАН – ИСТАНБУЛ – КАЗАН

Казаннан беренче халыкара пассажирлар авиарейсы – Төркиягә барып, «Америка ачу»

6 нчы ТАРИХ

КАНДАГАР РЕЙСЫ

Казан очучыларының әсирлектән котылу тарихы турында

7 нче ТАРИХ

ДАВЫЛЛЫ ЧОРНЫҢ ВАК СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ

Һөнәрләрне онытып торырга туры килгән еллар

8 нче ТАРИХ

«НИГӘ ӘЛЕ БЕЗГӘ КОНЦЕРТ КУЯРГА КАЗАНГА БАРЫП КАЙТМАСКА?»

Борис Гребенщиковның Казан университетындагы чыгышы

1990 нчы еллар

ХРОНОГРАФ

1990

- ТССРның Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул ителә
- Татарстан АЭС төзелеше туктатыла
- «КАМАЗ» җитештерү берләшмәсе акционерлык җәмгыяте итеп үзгәртелә. Ул СССРның иң эре предприятиеләре арасында беренче акционерлык җәмгыяте

1991

- Минтимер Шәймиев Татарстан Президенты итеп сайлана
- «Бөгелмә» аэропорты янында «Ан-24» самолеты һәлакәткә очрый. 41 кеше үлә

1992

- Республикада референдум үткәрелә, анда татарстанлыларга: «Татарстан Республикасы – Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы килешүләр нигезендә кора торган суверен дәүләт, халыкара хокук субъекты булуы белән килешәсезме?» дигән сорау бирелә. Тавыш бирүчеләрнең 61,39 проценты «Әйе» дип җавап бирә
- Татарстан Республикасының яңа Конституциясе кабул ителә
- Казан халыкара аэропортыннан беренче даими рейс ясала. Маршруты: «Казан – Истанбул – Казан»
- РФ Президенты Борис Ельцин Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсендә «Ту-160» стратегик ракета йөртүче самолетлар җитештерүне туктату турындагы документка кул куя

1993

- КАМАЗның двигательләр заводы яна

1994

- «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләрне бүлешү турында» Шартнамәгә кул куела
- Борис Ельцинның Россия Президенты статусында Татарстанга беренче килүе
- Яр Чаллыда «ОКА» автомобильләре җитештерү заводы эшли башлый, ул елына 75 мең машина чыгарырга тиеш була

1995

- Тузган торак республика программасы гамәлгә ашырыла башлый
- Казанның «Аэростан» авиакомпаниясенең «Ил-76» самолетын талиблар кулга төшерә. Экипажны әсирлеккә алалар

1996

- Татарстан Президенты сайлаулары. Президент Минтимер Шәймиев яңа срокка Президент итеп сайлана. Аның өчен сайлаучыларның 97,1 проценты тавыш бирә
- Кандагарда әсирлеккә алынган «Ил-76» экипажы, үзләренең самолетына утырып, талиблардан кача. Командир Владимир Шарпатовка һәм икенче очучы Газинур Хәйруллинга Россия Герое исеменә бирелә
- Алабугада «Шевроле Блейзер» автомобильләрен җыя башлыйлар. Ул үзебезнең илдә җыелган беренче иномарка дип исәпләнә

1997

- Татарстанда Икътисади һәм социаль прогресс дәүләт программасы кабул ителә. Максаты – дөньякүләм хуҗалыкка интеграцияләнгән социаль юнәлешле икътисад булдыру
- Казанда метро төзелеше башлана

1999

- Казанда Төбәкара клиник-диагностика үзәге булдырыла
- Казан вертолет заводында эшләнгән «АНСАТ» җиңел вертолеты беренче очышын ясый. Бу СССР таркалганнан соң, илдә конструкцияләнеп, һавага күтәрелгән беренче һәм ул вакытка бердәнбер очкыч була.

Фото: Рамил Гали

БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТ ДӘВЕРЕ

1991 елга кадәр Татарстанның президенты юк иде. Шуңа күрә 90 нчы еллар халык хәтеренә беренче президент – Минтимер Шәймиев чоры буларак кереп калды. Республика тарихындагы әлеге иң истәлекле вакыт турында Минтимер Шәрипович белән әңгәмәбезгә хәтта коронавирус та комачаулый алмады. Татарстанның Беренче Президенты, ә хәзер ТР Дәүләт Киңәшчесе тулы үзизоляция шартларында, «Татарстан» журналы редакциясе белән скайп аша элемтәгә чыкты.

Текст:
Татьяна Вафина,
Алсу Дәүләтшина

Фото: Ната Смирнова

– Минтимер Шәрипович, 90 нчы елларга «болгавыр еллар» дигән мөһер сугылып калды. Советлар Союзы таркала, бер сәяси стройга икенчесе алмашка килә, чуалышлар, ачлык игълан итүләр, кибетләрдә буш киштәләр... Сезгә шушы вазгыятьтә президент булып сайланып, республикада тәртип урнаштырырга туры килә. Әлеге давыллы елларда сезнең өчен иң катлаулысы нәрсә иде? Кайсы вакыйга белән аеруча горурланасыз? Ниндидер үкенечләр дә бардыр, бәлки...



Президент вазыйфасына керешү. 1991 елның 4 июле.

ЯЗГА ЧЫККАН БОЗАУЛАР КЕБЕК ИДЕК...

– Нәрсәсенә үкенәсең? Бу – безнең буын язмышы, безнең өлешкә әнә шундый хәлиткеч, асылда, революцион еллар тиде. 1917 елда революция кораллы юл белән ясалган, ә 90 нчы елларда империянең таркалуын тормыш үзе китереп чыгарды.

Шулай килеп чыкты: нәкъ менә шундый вакытта президент булдым. Моңа кадәр хакимиятнең күп баскычларын уздым – министрдан алып республиканың Югары Советы Рәисенә кадәр, тиктомалдан президент була алмыйсың. Өстәвенә, безнең илдә президентлык институты юк иде әле. Президентларны беркем дә әзерләми, бу эшкә беркайда да өйрәтмиләр. 90 нчы еллар алдыннан, 1989 елда, мин, беренче тапкыр альтернатив нигездә, КПСС Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре итеп сайландым. Бүләкнең дә бүләге иде бу! Минем өчен иң катлаулы еллар – үзгәртеп кору заманы менә шунда башланды да. Кешеләр тормышны яхшыртуны таләп итә. Бөтен нәрсә җимерек, кәстрүлләр буш... Тасвирлы әйтүем. Телевизордан Борис Николаевич Ельцинның, КПССның Мәскәү шәһәр комитетының беренче секретаре буларак, кибетләрдә йөргәнен күрсәтәләр, ә анда бөтен киштәләр буш. Кешеләр үз фикерләрен ачыктан-ачык белдерә башлады, урамнарның халык белән тулганын хәтерлим. Фәүзия Бәйрәмова протест йөзеннән ачлык игълан итте... Ул бит чын-чынлап ач торды, табигате шундый аның. Тормыш та шундый иде ул чакта. Барлык катлаулы сорауларга җавап табарга кирәк иде. Сөйләргә, аңлатырга, чөнки халык төркеме хакимияттән, димәк, миннән барысын да хәл итүне көтте. Төркем белән аралашу гомумән бик катлаулы. Биналарда чыгыш ясау – бер хәл, ә урамнарда, митингларда – бөтенләй башка. Кешеләр күкрәк киереп саф һава сулый башлады кебек, әмма алга таба ничек яшәргә кирәген белмиләр иде әле. Безнең танылган язучыбыз Туфан Миңнуллин үзенең бер чыгышында бу вазгыятьне болай сурәтләп биргән иде: «Кешеләр үзләрен декабрьдә туган бозау шикелле тота. Кыш буе өйдә торган да, яз җиткәч, аланга чыгарганнар». Бик төгәл билгеләмә. Без, авыл малайлары, мондый күренешне еш күзәтә идек, шул бозаулар белән бергәләп шатланышып-сикерешеп йөргәнебез дә булды. Нишләргә белмисең: ирек, шатлык, кояш җылыта... Кинәт кенә кая килеп эләккәнеңне һич аңламыйсың...

ИТЕ ДӘ ЮК, МАЕ ДА

Союз ни өчен таркалды? Беренчедән, СССР Конституциясендә КПССның җитәкче роле турындагы 6 нчы статья бар иде. Шуңа күрә партия катнашыннан башка бернәрсә дә эшләнмәде – җитди мәсьәләләрне Госплан да, Министрлар Советы да хәл итә алмый иде. Төп сәбәп, әлбәттә, җитештерү өлкәсендә – халыкка нәрсә ашатырга? Мәсьәләләр хәл ителсен өчен союздаш республикаларга хокук бирергә кирәк иде, автономияле республикалар һәм өлкәләр турында әйтеп тә торасы юк. Автономияле республика буларак Татарстанның да бернинди хокукы юк иде. Мин – республика җитәкчесе, моны үз башымнан кичердем. Менә бер очрак. Бервакыт, Министрлар Советы Рәисе булып эшләгән чагымда, безне Краснодар крае башкарма комитеты рәисе Николай Кондратенко белән бергә КПСС Үзәк Комитетына «келәм өстенә» чакырдылар. Башта миннән союз фондына ТАССР ның сыер итеннән күбрәк дуңгыз ите тапшыруын аңлатып бирүемне сорадылар. Аңлатам: бездә

Фото: ТР Президенты Матбугат хезмәте архивыннан.



Референдум көне. 1992 елның 21 марты.

> Без ул чакта Россиядә Шартнамәгә кадәр үк референдум уздырган бердәнбер республика булдык. Референдум барлык процессларны да тизләтте.

яшүче халыкның яртысыннан артыгы мөселманнар. Без ит тапшыру буенча планны тулаем үтәп барабыз, ләбаса! Җавап: Юк, дуңгыз ите сыер итеннән күбрәк булырга тиеш түгел!

Ә Кондратенкога мондый дәгъва белдерелде: бик күп субпродукт (малның эчке органнары) тапшырасыз, ә фондка бары ит кенә кирәк. Ул да аңлата: крайда җитештерелгән барлык ит болай да союз фондына китеп бара, үзебезнең халыкка да нидер калдырырга кирәк бит... Юк! Син СССР Госпланы күрсәтмәсе буенча нәкъ менә ит кенә җибәрергә тиеш. Ә субпродуктны үзегезгә калдырыгыз.

Без дә җитештерәбез, алар да җитештерә, әмма ни аларда, ни бездә бернәрсә дә калмый. Бөтен нәрсә бик катгый күзәтчелек астында. Хәтта эремчекнең майлылыгын да өстән билгелиләр: 13% майлылыктагы эремчек ашарга хакыгыз юк, киметегез! Хәлләр менә шундый иде.

ЗАМАНА ТАЛӘБЕ

Гомумән алганда Татарстан Республикасы Балтыйк буендагы өч республика бергә җитештергән кадәр продукция эшләп чыгара иде. Сәнәгатебез мөмкинлекләре гаять зур, әмма республика аның бары тик ике проценты белән генә идарә итә ала иде. Калганы – СССР Министрлар Советы, өлешчә РСФСР Министрлар Советы карамагында. Ул вакытта «кичәге» союздаш республикалар союздаш дәүләт хокукларына дәгъва итә башлады. Һәм автономияле республикалар да үз хокуклары турында сүз кузгатты.

Россиядәге автономияле республикалар арасында дәүләт суверенитеты турындагы декларацияне беренче булып без кабул иттек. Бу, әлбәттә, кыю таләп иде. Без моны аңлап эш иттек. Татарстанның тарихы катлаулы. Милли мәдәният, тел, гореф-гадәтләр проблемалары алгы планга чыкты. Аларны хәл итәргә кирәк иде. Мондый мәсьәләләр килеп чыккан очракта аларны кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Җәмгыятьтә киеренкелек калдырырга ярамый.

ЕЛЬЦИН ТРАМВАЙДА КИТЕП БАРДЫ

Ул чакта, 90 нчы елларда, бик күп көнүзәк проблемалар өлгереп җиткән иде, шуңа күрә без чигенергә уйламадык та, вазгыять тә шундый иде. 1990 елның август башында Казанга килгәч, Борис Николаевич Ельцин хәлнең бик нык кызганын күреп, халык алдында: «Суверенитетны йота алган кадәр алыгыз», – дип белдерде. Аның бу сүзе инде тарихи гыйбарәгә әверелде. Ә ул Язучылар берлегендәге очрашу вакытында туды. Татар язучылары һәм җәмәгатьчелеге белән очрашу бик давыллы узды. Барысы да Ельцинга кискен-кискен сораулар бирделәр, җавап таләп иттеләр... Нык кына кыса башладылар! Дөресен әйтергә кирәк, ул булдыра алганча түзде, барысына да җавап бирергә тырышты. Аннан соң арткы ишектән ишегалдына чыкты да күрде: халык һаман таралмый. «Моннан урамга чыгу юлы бармы?» – дип сорады. «Бар – дим. – Әнә анда трамвай соңгы тукталышына бара». Якында – Волков урамында Сәкинә Шакировна яши иде, аның белән йөргән чакта бу тирәләрне яхшылап өйрәнгән идем... Ельцин тиз генә урамга таба атлады, туктап торган трамвайга утырды да китеп барды. Китте дә барды, чөнки чынбарлыкны үз күзләре белән күрде.

Кичке ашка керешер алдыннан ул: «Минтимер, нишлибез инде?», – дип сорады. «Борис Николаевич, – дим, – вазгыять кызганнан–кыза бара, шартларга тора, бу хәлдән чыгу юлын табарга кирәк. Кешеләрне тынычландырырга, сөйләшергә-килешергә кирәк».

Ул шартнамә проектын әзерләргә тәкъдим итте: «Әйдәгез, эшче төркемнәр төзик, алар эшкә керешсеннәр. Әгәр нәрсәгәдер барып төртелеп, шартнамә текстын язуны дәвам итә алмыйлар икән, без синең белән, яннарында торып, кулга каләм тотып, бу мәсьәләләрне хәл итәрбез». Шулай эшләдек тә. Ул сүзендә торды, һәм без 1994 елда шартнамәгә кул куюга ирештек. Тарихта беренче тапкыр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамә әнә шулай барлыкка килде.

Шартнамәгә кул куйгач, халык тынычланды, кыен хәлдән шулай чыктык. Беләсезме, мин ул вакытта нәрсәдән курыктым? Коткы салучылардан. Урамнарда, аеруча кичкырын, яшьләр иркенләп йөри, шәһәрдә студентлар күп, шунда берәрсе атып җибәрсә яки пычакка тотынса... Ә менә Ирек мәйданыннан өйгә кадәр ияреп кайткан төркем-төркем халыктан курыкмадым – кешеләр, бөтен нәрсәне миннән таләп итә-итә, янәшә атлыйлар иде...

ТАРИХ ДӘРЕСЛЕКЛӘРЕНДӘ НИЛӘР ЮК?

– Хәзерге буын 90 нчы еллардагы Татарстан турында ниләр белергә тиеш? Дәреслекләрдә язылмаганны...

– Шәхси тойгыларны, тарихи вакыйгаларга шәхсән катнашудан туган тәэсирләрнедер, мөгаен. Шул вакыйгалар эчендә кайнаган һәркем, һичшиксез, күңелендә җуелмас хатирәләр саклый. Соңыннан тарихка әвереләчәк әлеге хәлләрне үз вакытында йөрәкләребез аша уздырдык.

90 нчы елларда, яшь булсак та, тәҗрибәле, тормышны белә идек. Бу исә ахыр чиккә җитмәскә ярдәм итте. Белмим, бу кадәр сабырлыкны каян алганбыздыр – кешеләргә бөтен нәрсәне аңлатып бирергә кирәк иде бит. Барысы да беренче тапкыр эшләнә, ни кылырга, нинди адым ясарга кирәклеге аңлашылмый, хәтта партия элитасында да фикер каршылыклары килеп чыга иде.

Кагыйдәм шундый: башымда катлаулы проблемалар буенча төгәл карар, төгәл юнәлеш булдырырга тырышу. Әгәр эш барышында икеләнә, үз карарларыңны үзгәртә башласаң, хәл тагын да катлауланачак. Гадәти кагыйдәләр кебек, әмма алар барысы да безнең баштан үткән. Кешеләргә чынга аш-



> Төркем белән аралашу гомумән бик катлаулы. Биналарда чыгыш ясау – бер хәл, ә урамнарда, митингларда – бөтенләй башка. Кешеләр күкрәк киереп саф һава сулый башлады кебек, әмма алга таба ничек яшәргә кирәген белмиләр иде әле.

маслык вәгъдәләр бирергә кирәкми. Үзең булдыра алганны гына.

РЕФЕРЕНДУМ – БОРЫЛЫШ МИЗГЕЛЕ

Мәсәлән, 1992 нче елгы референдумны алыйк. Аның нәтиҗәсендә Татарстан, Канададагы Квебек, Испаниядәге Каталония шикелле, үзбилгеләнү турында референдум үткәрергә җөрьәт иткән, күпмилләтле халкы федераль үзәк белән мөнәсәбәтләрен ачыктан-ачык һәм цивилизацияле рәвештә билгеләгән республика буларак дөньяның иң яңа тарихы сәхифәсенә кереп калды. Бу инде халыкара дәрәҗәдәге вакыйга иде! Бүгенге көндә сезнең белән читлек аша сөйләшү ихтималы да бар иде…

Әлеге демократия, хокук юлларын башлап үтәргә туры килде. Без ул чакта Россиядә югарыда искә алынган Шартнамәгә кадәр үк референдум уздырган бердәнбер республика булдык. Референдум барлык процессларны да тизләтте.

1991 елның ноябрендә республиканың Югары Советы референдум турында закон кабул итте, февральдә аны уздыру көне билгеләнде – 1992 елның 21 марты. Референдумда катнашучыларга бер генә сорауга җавап бирергә тәкъдим ителде: «Татарстан Республикасының суверен дәүләт булуы, Россия Федерациясе һәм башка республикалар, дәүләтләр белән тигез хокуклы килешүләр нигезендә үз мөнәсәбәтләрен коручы халыкара хокук субъекты булуы белән килешәсезме?» Референдумга әзерлек СССР таркалу җирлегендә барды. Бу исә Мәскәүне бик җитди борчуга салды, мине бу нияттән ваз кичәргә үгетләделәр. Референдумны үткәрмәскә өндәү өчен башкалага чакырып алдылар. Казан вокзалында мине һич көтмәгәндә… Табиев каршы алды. Мин аны бик ихтирам итә идем, ул 1960–1979 елларда КПСС Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләде. Күрәсең, үзара яхшы мөнәсәбәтебезне белеп, мине үгетләргә җибәргәннәр. Табиев – оста дипломат: «Ни дә булса әйтү дә, киңәш итү дә кыен», – диде… Ул да республика өчен борчыла иде. Сергей Михайлович Шахрай янына киттек. Аңа ничек бар, шулай әйттем: халык референдум таләп итә. «Сез бит күренекле демократ, халык ихтыярына каршы килергә мөмкинмени?», – дидем. Минем урында булсагыз, нишләр идегез? Үзебез демократиягә таба беренче адымнар ясыйбыз, шул ук вакытта, үзебез үк референдумны тыябызмы? Мин моны аңламыйм…

Ул вакытта Россия Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов иде. Үз вакытында: «Шәймиевне читлеккә бикләп, Мәскәүгә алып килергә кирәк», – дип белдергән кеше ул. Әйе-әйе… Журналистлар ул заманда бу хакта бик күп язды. Хасбулатов – Кавказ кешесе, юл куярга теләмәде. «Референдумны уздырмау турында карар кабул итегез!» – дип таләп итте. Ә безнең команда барысына да әзер иде инде. ТР Югары Советы Рәисе урынбасары Зилә Вәлиева – Казанда, Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүдә, РСФСР Югары Советында оборона тоттылар.

Мин Мәскәүдәге җитәкчеләргә әйттем: «Үз халкыннан куркучы җәмгыять строе төзибезмени инде? Болай булса, без Россиянең яңарган, демократик рухлы җәмгыяте белән ничек идарә итәрбез соң? Революция бара бит… Халыкка референдум үткәрмәскә кирәк дип әйтергә кемнең хакы бар?»

Соңыннан җиткерделәр: ул очрашуда катнашкан берәү: «Каян чыккан бу үҗәт егет, кайда тәрбияләнгән?» – дип сораган…

Кыскасы, без берничек тә килешә алмадык. РСФСР Югары Советы безнең референдум буенча тискәре карар кабул иткән очракта, республика Югары Советының референдумны үткәрмәү турындагы утырышы әзерләнгән иде. Фәрит Хәйрулловичны Мәскәүдә депутатлар җәфалый, әмма ул бирешми. Татарстаннан сайланган кайбер депутатлар хәзер әүлия булып йөриләр-йөрүен, ә теге чакта республикага каршы чыктылар. Тик мин гомерем буе андый хәлләргә артык игътибар бирмим, аларга вакыт сарыф итсәң, бик күп файдалы эшләргә өлгерә алмый калуың бар.

Республика җитәкчесе буларак, ахыргы сүзне мин әйтергә тиеш идем. Көнелендә, бигрәк тә үзең өчен, карар

инде кабул ителгән икән, икеләнеп торырга урын юк. Һәм без үз карарыбызны үзгәртмәдек. Мәскәүдән Казанга десант килеп төште – безнең халыкны референдум үткәрмәскә үгетләп йөрделәр. Безнең прокурор Антоновны сайлау участоклары эшен тыярга мәҗбүр иттеләр.

Референдум алдыннан, кич белән, татарстанлыларга телевидение аша Борис Ельцин мөрәҗәгать итте. Россия президенты безнең халыкны референдумга бармаска өндәде.

Ельциннан соң республика телевидениесеннән мин чыгыш ясадым. Халкыбызга бөтән караштан чыгып мөрәҗәгать иттем: демократик җәмгыятьне үстерү зарурлыгы, илебезнең инде бу юлга басканы турында сөйләдем. Референдум соравына уңай җавап кына Татарстанга тынычлык һәм иминлек китерәчәк, дидем.

Халык реферундумга бердәм катнашты, 2611 сайлау участогының барысы да вакытында ачылды һәм тыныч кына эшләде. Минем өчен моның әһәмияте зур иде, кешеләр прокурор тыйганга карап тормадылар. Сайлау хокукына ия булган халыкның 81,7% ы референдумда катнашты, сайлаучыларның 61,4% ы куелган сорауга «әйе» дип җавап бирде. Бу турыда рәсми документ бар. Бу – безнең заманның иң мөһим хокукый документларының берсе, ул тормышыбыздагы борылыш мизгелен дәлилләп тора. Ул мизгелдә барыбыз да шуны аңладык: артка таба юл юк, уртак тел табарга һәм алга таба үсәргә кирәк.

Минтимер Шәймиев Тузган торакны бетерү программасы буенча яңа фатирларга күчүчеләрне котлый. 1998 ел.

“

Ил күләмендә моңа тиң программа хәзергәчә юк. Мин өй туйларына еш йөрдем ул чакта. Кешеләр сөенечтән елыйлар иде... Яшисең-яшисең җимерек йортта, һәм кинәт яңа йортта, яңа районда бушлай яңа фатир бирәләр!

БОЛАРНЫҢ ГАМӘЛГӘ АШМАВЫ ИХТИМАЛ ИДЕ...

– 90 нчы елларда көчле проектларга нигез салынды, ә бит аларга күпләр шикләнеп карады. Югары инфляция заманында матур хыял гына булып тоелган төзелешләрне, эшләрне башлап җибәрергә ничек күңдерә алдыгыз кешеләрне? Тузган торакны бетерү, тоташ газлаштыру программалары, ул вакытта әкият булып тоелган метро идеясе...

– Боларны ничек гамәлгә ашыра алуыбызга бүген дә гаҗәпләнәбез. Кешеләргә чын, нәтиҗәле гамәлләр кирәк иде. Илдә хәтта акча әйләнеше дә калмаган вакыт бит – инфляция 1000% ка җитте! Ә без шундый зур проектларны башкарып чыгуга ирешә алдык.

Казан тузып-җимерелеп баручы шәһәр иде. Оборона предприятиеләре булган ябык шәһәр. Сугыш вакытында бирегә эшчеләре белән күпме предприятие күчеп килгән... Барысын да ашык-пошык, вакытлыча урнаштырып торганнар. Күбесе шулай калган да. Башкаланы үстерү-яңарту өчен акча юк. Кемне дә булса гаепләү дә кыен. Тирәякта тормыш бик тиз яңадан корылганда, күпләр көчкә-көчкә очын-очка ялгап яшәгәндә торак төзү кайгысымыни?! Икътисадый яктан тотрыксыз үзгәртеп кору чорында торак төзүгә тотыну – читтән караганда, сәер генә түгел, ә гайре табигый хәл булып тоелгандыр. Әмма без 1995 елда җитди карарга килдек: шәһәрләрдәге һәм районнардагы барлык сәнәгать предприятиеләре җитәкчеләрен җыйдык та үз «салымыбызны» салдык – гамәлләштерелгән продукциянең 1% ын тузган торакны бетерү фондына күчереп барырга! Бу фәкать безнең – Татарстанның карары иде.

Бөтен тузган торакны исәпкә алдык. 1995 ел башына Казанда тузган торакта 31 мең гаилә яши, шуның 21 меңе – шәһәрнең иң үзәгендә булып чыкты. Күпме халык баракларда яши иде. Күпме кешегә фатир төзергә кирәклеген күз алдына китерә аласызмы? Хәзер минем үземә дә моңа ышану кыен, әмма без һәммәсен дә яңа, бушлай торакка күчердек! Бушлай, чөнки ул кешеләрнең түләргә акчалары юк, болай да, Горькийның «На дне» пьесасындагы кебек, тормышның төбендә яшиләр иде. Без кешеләрне тормыш төбеннән барлык уңайлыклары булган фатирларга тартып чыгардык. Бөтен ил шундый хәлдә иде, әмма без моны эшли алдык, ә башкалар – юк. Ил күләмендә моңа тиң программа хәзергәчә юк. Мин өй туйларына еш йөрдем ул чакта. Кешеләр сөенечтән елыйлар иде... Яшисең-яшисең җимерек йортта, һәм кинәт яңа йортта, яңа районда бушлай яңа фатир бирәләр! 2004 ел ахырында нәтиҗәләр ясадык: ун ел дәвамында тузган торак фондыннан гражданнарны күчерү өчен 48 мең 576 фатир төзеп тапшырылган. Мин бу карарыбызның дөреслегенә бер генә минут та шикләнмәдем, хәтта суд белән яный башлагач та. Татарстанны федераль салым базасына кул сузуда гаепләделәр, ә бу – хөкемгә тартырлык гамәл. «Мин хөкем ителергә әзер, әмма суд ачык булырга тиеш», – дип белдердем. Мин хәзер ул чорны рәхәтләнеп, канәгатьлек белән искә алам – без бөек эш башкардык.

КЕШЕЧӘ МӨНӘСӘБӘТ ҺӘМ КЕШЕЧӘ ШАРТЛАР

Газлаштыруга килгәндә, берничә тапкыр әйткәнем бар – бу минем шәхси ниятем. Туган ягым Актаныш районында урманнар бөтенләй юк диярлек. Без балачактан ук җәй буе ялыктыргыч, авыр эш белән – мичкә ягар өчен кизәк җыеп киптерү белән шөгыльләнә идек. Авыл гаиләләрендә балалар күп. Безгә су җылыту, чәй кайнату әнкәй өчен зур мәшәкать иде. Аның азаплануы күңелгә уелып калган, күрәсең. Шуңа күрә, мөмкинлек чыгу белән, без республиканы газлаштыруга керештек... Тормыш сыйфаты шунда ук үзгәрде, бигрәк тә күп балалы аналар өчен. Җирдәге оҗмах – көнкүрешебездә газ барлыкка килүне мин әнә шулай атыйм. Чөнки безнең буын мондый оҗмахсыз чорларны үз җилкәсендә татыды.

Моңа ничек ирештек? 90 нчы елларда күп нәрсә үзара мөнәсәбәтләр аша хәл ителде. Башкача булмый да, чөнки илдә акча әйләнеше туктаган, кешеләргә хезмәт хакы түләргә дә мөмкинлек юк. Шулай бервакыт безгә «Газпром» башлыгы Рем Иванович Вяхирев килде.

Без аның белән яхшы мөнәсәбәттә идек. «Минтимер, сез газны күп кулланасыз, әмма түләмисез», – диде ул. «Акча юк», – дим. Ул чакта бу бик киң таралган җавап иде. Республика предприятиеләренең «Газпром»га 53 миллион сум бурычы җыелган.

«Эшчеләргә айлык хезмәт хакын түләү өчен генә булса да бераз акча тап инде!» – ди Рем Иванович.

Һәм без ул вакытта Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары Равил Моратов белән киңәшләштек тә, үз тәкъдимебезне керттек. Бездә, «Оргсинтез» заводында – полиэтилен, Әлмәттә металл торбалар җитештерәләр. Сәнәгать предприятиеләренең дә газ өчен бурычы җыелган икән, димәк алар барысы да республиканы газлаштыру эшенә кушылачак, дибез. Ә «Газпром»ның авылларны газлаштыру планы бар. Сез шул планыгызны үтисез, ә без, бурычларыбыз хисабына, бөтен республиканы газлаштырабыз. Килешкәнчә башкарып та чыктык. Без 2002 елга, илдә беренче булып, шәһәр-авылларыбызга тоташ газ керттек – газны һәр плитәгә китереп җиткердек. Хәзергә әле бер генә төбәкнең дә мондый уңышка ирешә алганы юк. Бүгенге көнгә илнең өчтән беренә газ бөтенләй кермәгән әле.

Метро турында да шул вакытларда хыяллана башладык. Хәтеремдә, ул вакытта Башкортостан җитәкчесе Мортаза Рәхимов белән еш күрешеп-сөйләшеп йөрдек – күршеләр бит! Мин планнарыбыз белән уртаклашам, метро төзи башларга ниятлибез, дим. Ә ул: «Минтимер, мөгаен, барып чыкмастыр ул эш, вакыты да ул түгел, транспорт мәсьәләсе дә ул кадәр кискен тормый…», – ди. Метро төзүләре җиңел булмады, ләкин хәзер тормышыбызны метродан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Әйе, чыгымлы эш булды, әмма яшәргә кешечә шартлар тудырдык!

ХЫЯЛЛАР ТОРМЫШКА РӘХӘТЕН ТОЕП АШЫРЫЛЫРГА ТИЕШ

– Ягъни теге яки бу гамәл – хыялны тормышка ашыру икән, димәк, ул уңышлы булачак?

– Минем өчен шулай. Һәм үз хыялыңны тормышка рәхәтен тоеп ашырырга кирәк. Инде ун ел президент булмасам да, нишләп мин берәүгә дә тынгы бирмим? Без «Яңарыш» фондын ни өчен оештырдык? Бусы да гомерем буе күңелемдә йөрткән хыялым иде: тарихи мирасыбызны – борынгы Болгар һәм Зөя шәһәрләрен тергезү. Президентлыктан соң мин үземне ирекләрәк кеше итеп хис иттем, күңел өчен ниндидер игелекле эш белән шөгыльләнәсем килде. Эшләгәндә һәр көн җинаятьләр, янгыннар, һәлакәтләр һ.б. турында хәбәрләрдән башлана иде. Президентның көне беркайчан да яхшы хәлләрдән башланмый – миңа ышана аласыз. Әмма республика Конституциясенә кулыңны куеп ант иткәнсең икән – сәламәт бул, хезмәт ит, эшләрне күрәп бар!

Акча беркайчан да җитми торган мәңгелек хәзинәләр бар: мәдәният, ана теле… Әмма кеше бу өлкәләрдә беренчел хокукка ия. Мин ЮНЕСКОның да мондый хәзинәләр өчен борчылганын беләм – глобальләшү шартларында күпме телләр югала! Әлеге мәсьәләләр көтеп торырга мөмкин кебек тоела гына. Юк, көтә алмыйлар! Алар кичектергесез. Республикабызның уңышлы үсеше гореф-гадәтләрне, рухи мирасны саклау белән турыдан-туры бәйләнештә. Без моның белән шөгыльләнергә бурычлы. Безне аңларга телиләрме-юкмы – бусы мөһим түгел, без республикабызда яшәүче милләтләрнең барысының да ана телләрен сакларга бурычлы. Бу өлкәдә аңлашылмаучылыклар булу аркасында тынычлыгыбызны югалтабыз, балаларны тәрбия итүгә зыян китерәбез. Без эшли беләбез, димәк, максатка ирешергә кирәк. Без бергәләп, дус-тату һәм шат яшәргә, киләчәгебезне тәрбияләргә тиеш. Хәзер без күп телдә белем бирү комплекслары булдыруга тотындык, алар безнең балаларны көндәшлеккә сәләтле итеп үстерергә мөмкинлек бирәчәк. Өч телдән – рус, татар һәм инглиз телләреннән башлыйбыз. Ата-аналардан балаларга кытай, гарәп һәм башка телләрне өйрәтүне

үтенеп гаризалар кирә. Дөнья ачык хәзер, моңа шатланырга кирәк. Безнең заманда «тимер пәрдә» корылды, күп нәрсә тыелган иде, хәтта радио да тыңлый алмадык. Шуңа күрә, мөмкинлекләр ачылуына куанып яшәргә һәм үсәргә кирәк.

Берәүгә дә ике гомер бирелмәгән, тик без ни өчендер кайчак бу дөньяга мәңгегә килгәндәй кыланабыз. Ничек инде кешене туган теленнән мәхрүм итәргә, телне саклар өчен шартлар тудырмаска мөмкин? Тел мәдәният һәм гореф-гадәтләр өлкәсенә алып керә. Кешене үз милләтеннән, диненнән мәхрүм итәргә кемнең хакы бар? Моны туган теленнән мәхрүм ителмәгән кеше генә аңламыйдыр, мөгаен. Без бит ачялангач түгел, Аллага шөкер, сугыш юк. Хәзер ясалма киртәләр кору заманы түгел, нәкъ менә үсеш өчен шартлар тудыру вакыты. Безнең кирәкле дәреслекләрне әзерләү, күп телдә белем бирү мәктәпләре булдыру, кирәкле шартлар тудыру өчен мөкинлекләребез бар. Укырга һәм укырга гына кирәк! Зур социаль программаларны гамәлгә ашыра алганбыз икән, бу проектны да башкарып чыгарбыз. Дәүләтнең икътисади нигезе булырга тиеш, ул мәдәниятне дә, телне дә, рухиятне дә саклап калачак.



ЯРАТКАН ЗАМАН ҺӘМ ЯРАТКАН УРЫН

– ТАССРның 100 еллык бик бай тарихы бар. Төрле чорлар булган, шуларның кайсысы сезгә аеруча ошый, Сез кайсы чорда яшәргә яки кайсысына берaзга гына кайтып килергә теләр идегез?

– Мин бүген сезнең сорауларга ихлас җавап бирдем, язмышымнан зарланганны ишетмәгәнсездер бит? Бу дөньяда яшәвең нинди генә чорга туры килсә дә, лаеклы яшәргә кирәк. Мине беркем дә көчләп каядыр кертеп җибәрмәде. Үз өлешеңә тигән теләсә кайсы заманда лаеклы гомер кичерергә тырышырга кирәк.

– Сез Татарстанда һәр районны, аның һәр почмагын беләсез. Яраткан урыныгыз бармы? Сез үзегезне кайда бик бәхетле хис итәсез?

– Һәр кеше өчен иң яраткан урыны – туган җире, мөгаен. Актаныш районындагы кечкенә генә Әнәк авылы – язучы Нур Баянның һәм минем дә туган ягым. Без урта мәктәпне тәмамлаганда, анда 57 йорт бар иде. Югары уку йортларында да 57 студент укый иде. Димәк, уртача алганда, һәр йорттан бер бала югары белем алган булып чыга. Безнең мәктәп бик көчле иде, безнең күренекле укытучыларыбыз безгә бик яхшы белем бирделәр.

Әнкәй исән чакта авылга сирәк кайтканыма үкенәм. Барысы да бар югыйсә:



“

Әнкәй исән чакта авылга сирәк кайтканыма үкенәм. Барысы да бар югыйсә: транспорт, вакыт, мөмкинлекләр... Ә әнкәй янына кайтып күрешеп килергә өлгермим. Әни кеше ул һәрчак үз балаларын көтеп яши.

транспорт, вакыт, мөмкинлекләр… Ә әнкәй янына кайтып күрешеп килергә өлгермим. Әни кеше ул һәрчак үз балаларын көтеп яши. Казанга безгә кунакка килгәч, ул бөтен нәрсә турында сөйли башлый иде. Эштән арып кайтасың, кайвакыт әнкәй сөйләгәндә йокыга да китәсең. Ә аның яңалыклары күп җыелган. Мин йокыга китәм, ә ул минем карават янында утырып сөйли дә сөйли… Нишләп мин аны тыңлап бетерергә, озаклап сөйләшеп утырырга мөмкинлек таба алмадым икән? Минә шушы хис һич тынгы бирми. Әтиәниләрне онытырга ярамый. Бу күңелгә мәңгелеккә кереп кала. Менә сезнең белән бер–беребезнең күзенә карап сөйләшеп утырабыз – сез дә үзгәрәсез, мин дә…

Минем тагын бер яраткан урыным бар – Казан Кремле. Анда ниләр булганын күзәтергә яратам. Ашлыкны гектардан берничә центнерга күбрәк җыелып алган уңышлы бер елда, авыл җыелышларында киңәшеп, Ходай биргән өстәмә уңышны саткан акчаны Кол Шәриф мәчетен төзергә һәм Благовещение соборын төзекләндерергә бирергә карар иттек. Төзедек, төзекләндердек. Кремльдә эшләгәч, мин анда кайвакыт җәяү йөргәлим, читтән күзәтеп торам. Кешеләр мәчеткә яки соборга гаиләләре белән киләләр һәм күз алдында үзгәрәләр. Ата-аналар балалары белән әкренрәк, ягымлырак сөйләшә башлый, күзләре нурланып китә. Күрәм дә шатланам. Чыннан да, игелекле уртак эшкә катнашу безне яхшыга үзгәртә. Бу – безнең байлыгыбыз. Бу – безнең барыбызның да яраткан урыннары. Бу – безнең Ватаныбыз.

БУЛДЫРА БУ ЕГЕТ!

– Сез – халыкның яраткан президенты. Сезне ни өчен яраталар? Халык игътибарын тою күңелләме? Авырсынмыйсызмы?

– Үз-үзеңә бәя бирү бик катлаулы. Минем озын тормыш юлым күп кешеләр белән бәйләнгән. Мин моның кадерен беләм!

Хезмәт юлымны бөек реформатор Никита Хрущев чорында башладым. Кешегә үз сәләтләрен эретү-күрсәтү, халык алдына чыгару мөмкинлеге биргән яхшы заман – «җепшек чор» иде ул.

Юллама белән Мөслимгә килдем. Яңа гына институт тәмамлаган 23 яшьлек инженер. Бәлки тырыштыр, намуслыдыр, әмма моны кем белсен ул чакта? Мөгаен, барысы да бергә бик яхшы туры килгәндер: заманы да, шәхси омтылышлар да, миңа насыйп булган форсат та. Без бит барыбыз да максималистлар идек, алны-ялны белми эшләдек.

Әлбәттә, тәҗрибәле осталар миңа сак карадылар: нишләр икән монда яшь инженер? Көз иде, остаханәләрне авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлау сезонына әзерләү бара. Кулыма көрәк алдым да башкалар белән бергә остаханәне чүп-чардан чистарта башладым. Шуннан соң эшчеләр мине үз кеше итеп кабул иттеләр, үз араларына керттеләр.

Кыш көне яшь тракторчылар өчен әзерлек курслары алып барырга куштылар. Мәгълүм булганча, бу космосны актив үзләштерү еллары иде. Шуңа күрә «шәкертләрем» күбрәк трактор төзелеше белән түгел, космос белән кызыксындылар: галәмгә җибәрелгән иярчен ничек кире Җиргә егылып төшми икән? Кызыксынучан һәм белемгә тартылган кешеләргә үпкәләп буламыни? Озакка китсә дә, ясалма иярчен турында да, трактор детальләре турында да бар белгәнемне сөйләп бирергә тырыштым. Бу егетләрнең күзендә никадәр мәхәббәт, җылылык һәм өмет чагыла иде!

Иң мөһиме – кешеләрне аңлау. Кешеләр миңа ышана башлады, ә ышаныч ул – бик зур ярдәм. Мин яшьләр белән дә, олы яшьтәге тәҗрибәле агайлар белән дә уртак тел табарга өйрәндем. Һәркемгә кешечә карадым, тормышындагы проблемаларын хәл итүдә булышырга омтылдым.

Механизаторлар хезмәтен ничек җиңеләйтүем турында да искә төшерми булдыра алмыйм. Кышкы иртәләрдә машиналарны кабызу бик кыен иде, төнлә бөтен нәрсә туңа. Йөртүчеләр машина астына учаклар яга, двигательләрне җылыта, кайвакыт моңа ярты көн вакыт уза. Ул вакытта энергия белән тәэмин итү үзәкләштерелмәгән, автопаркта электрны урындагы генераторлар эшләп чыгара. Эшкә иң иртә килүче машинистка тәкъдим иттем: әйдә, машина йөртүчеләргә кайнар су әзерләп куябыз. Зур мичкә таптык, аңа катод белән анод урнаштырдык, асылда, зур су җылыткыч ясадык. Шул мичкәдә суны кайнап чыкканчы җылытабыз. Машина йөртүчеләрне җыйдым да әйттем: моннан ары бик иртә килергә кирәкми, радиаторларга салыр өчен кайнар су бар. Ни өчен моңа кадәр берәүнең дә башына килмәгәндер, белмим. Никадәр бәхет-шатлык күрдем ул эшчеләрнең йөзендә!

Техниканы гына түгел, кешеләрне дә кайгыртучы яшь инженер турында хәбәр әнә шулай таралды. «Булдыра бу егет!» – дигән фикер туды халыкта.

Тормыш – катлаулы нәрсә. Һәр кеше үзенең әзерлегеннән, тәрбиясеннән чыгып, яшәү рәвешенә һәм кагыйдәләренә карап үз фикерен белдерә яки үз гамәлләрен кыла. Төрле кешегә төрле мохит тәэсир итә. Шуңа күрә үз карашыңны аңлата белергә һәм сабыр булырга кирәк. Үз гомеремдә күңелемдә эшче кешегә карата нинди дә ачу туганы булмады. Барысы да – безнең кешеләр, безгә беркемне дә Айдан ташламаганнар, лабаса… Мин кешеләрне яратам – тормышымдагы төп кагыйдәм шул. Т



ТУЗГАН ТОРАКТАН – ЯҢА ЙОРТКА

«Без бергә» китабындагы текст бик үзенчәлекле. Биредә – 48 мең 576 фамилиядән торган исемлек. «Сезнең ярдәм белән Сезне яңа адрес буенча кабул итүгә шат барлык кешеләр исеменнән», – дип имзаланган ул. Татарстанның беренче Президенты әйтүенчә, бу – аның өчен иң кадерле китап.

Автор:
Алсу Троицкая

1995 елның 23 октябре. Минтимер Шәймиев «Тузган торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту һәм тузган торак кварталларын реконструкцияләү чаралары турында» Указ чыгара. Асылда, тузган торакка каршы рәхимсез сугыш игълан итә. Илдә сәяси тотрыксызлык хөкем сөргән, икътисадны җитди проблемалар борчыган чак, бәлки, бик вакыты да түгелдер. Әмма Президент, үз карарын аңлатып, сүзне бик кыска тота: «Торак мәсьәләсен хәл итми булдыра алмыйбыз. Бу – әхлакны билгели торган категория».

ТУЗГАН ТОРАК – ӘХЛАКСЫЗЛЫК УЛ!

90 нчы елларда республика җитәкчесе үз карашын көндәшләрне генә түгел, хәтта тарафдарларын да аптырашта калдырырлык гыйбарә белән нигезли. «Бу – әхлаксызлык бит!» – ди торган була президент. Мондый аргументның икътисадта базар мөнәсәбәтләренә йөз тоту мантыйгы белән никадәр ярашканын, күрәсең, ул үзе генә төшенгәндер.

Республикада тузган торак проблемасын кичекмәстән хәл итү кирәклеген дә яхшы аңлый ул. Бер яктан, торак фондын хосусыйлаштыру мондый җимерекләрдә яшәүчеләрнең социаль яклауга мохтаҗ, түбәнсетелгән хәлен ап-ачык күрсәтте. Базар шартларында әлеге кандала һәм күсе ояларын нишләтеп булсын, ди? Икенче яктан, Дәүләт суверенитеты турында декларация кабул иткән республика мөстәкыйльлеге турында авыз тутырып дөньяга белдерде. Димәк, халкының язмышы өчен дә җаваплылыкны үз өстенә алды. Шулай икән, каланың җимерек, тузган йортларында яшәп, бернинди кешечә шартлар булмауга каршы чыккан адәм балаларының өметсез карашларына ничек күз йомарга мөмкин?! «Долой трущобы!» диган язулар мондый каршы чыгуның, протестның иң гөнаһсыз бер рәвеше генә иде. Иң куркынычы исә агач корылмаларда көннән-көн ешрак дөрләгән янгыннар була.

ҮЗЕМДӘ СЫНАЛГАН

1993 елда нефтьчеләр каласы Әлмәттән Казанга килгән студент буларак, миңа башкаладагы коммуналь фатирлар бик сәер тоелды. Мин Һади Такташ урамында, Казан зоопаркы каршындагы бер коммуналкада яшәгән курсташым Ольга гаиләсенеке кебек көнкүреш шартлары булырга мөмкин дип күз алдына да китерә алмый идем. Басмалары кителгән ярымҗимерек баскычларда аягыңны сындырырга да озак түгел… Күзләрне әчеттергән, чын мәгънәсендә, тамакка утыра торган мәче сидеге сасысы тәмәке исе белән кушыла. Бер каттагы бөтен халык өчен – бер сасы бәдрәф. Минем гаҗәпләнүемне күргәч, дустым, бармагы белән тәрәзәгә ишарәләп, «юатып куйды»: «Күрше йортның әбрәкәе бөтенләй урамда әле. Алар суны колонкадан барып ала. Кышын ул бозланып ката да күршеләр суга монда йөри, бездә бит сүүткәргеч булса да бар».

Ә менә чүплек ике йортка бер – нәкъ тәрәзә янында гына. Анда, әлбәттә, көнетөне күселәр чабыша. Казандагы меңләгән гаиләләрнең ничәмә-ничә буыны гомер кичергән куркыныч «төш» иде монда. Университетта диплом яклавыбызны Ольганың Кол Гали урамындагы яңа, иркен фатирында билгеләп үтүебез нинди шатлык булганын күз алдына китерегез әле. Нибары дүрт елдан соң! Әти-әниләрдән башка гына, аерым фатирда…

ИРЕКЛЕ ДӘ, МӘҖБҮРИ ДӘ

Указ кабул ителгәнче гаять зур аналитик эш башкарыла. Шәһәр һәм муниципалитет хакимиятләре бөтен торак фондын диярлек тикшереп чыга, тузган йортларның исемлекләрен төзиләр, аларда яшәүче һәр кешене саныйлар. Нәтиҗәдә, 45 851 гаилә яшәгән 8 863 тузган торак йорт теркәлә. Бу гаиләләрнең барысын да, һәр кешене теркәп, исәпкә куялар, бушлай фатир алу графигын төзиләр. Аны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаралар. Архитекторлар һәм проектлау белгечләре торак йортлар, инженерлык

Тузган торакны бетерү программасын кабул иткән вакытта, республика халкының 3,3% ы начар көнкүреш шартларында яши. Чагыштыру өчен: Россия Федерациясе буенча бу күрсәткеч 1,3% ны тәшкил иткән була.

коммуникацияләре һәм инфраструктура төзелеше өчен яңа территорияләрне үзләштерү буенча тәкъдимнәр әзерлиләр. Кыска гына вакыт эчендә хокукый база эшләнә.

Мәсьәләнең башка ягы да бар: бу әйткәннәрнең барысы да үтәләчәгенә, игълан ителгән программаның чираттагы вәгъдә генә булмаячагына кешеләр ышана иде микән соң? Матур һәм шау-шу куптарган ниятләр чираттагы сайлаулардан соң бик тыныч кына онытылып куя иде бит. Әле хәтердән җуелырга өлгермәгән совет чорында әнә һәр гаиләгә аерым торак та вәгъдә иткәннәр иде... Октябрь аенда игълан ителгән «Шәймиев указы» нәрсәсе белән аерылып торачак соң, дип уйлый халык.

Беренче чиратта шунысы үзенчәлекле: ил күләмендә тиңе булмаган әлеге масштаблы социаль программаны Шәймиев үзе җитәкли. Җаваплылыкны ниндидер ведомствога йөкләп була торган очрак түгел бу, дип саный ул. 1996 елның 13 июнендә «Тузган торакны бетерү өчен максатчан салым турында» республика законы кабул ителә. 1996 елга ул – 0,3%, 1997 елга – 0,6% һәм аннан соңгы еллар өчен 1% тәшкил итә. Бу салым билгеләнгән ставкадан һәм продукцияне сатуның (күрсәтелгән хезмәтләрнең, эшләрнең) фактагы күләменнән чыгып исәпләнә, ул республиканың барлык предприятиеләренә йөкләнә. Соңрак Татарстанда якларны килештерә торган вариантка тукталалар – яңа торакны ирекле взнослар хисабына төзергә карар кылына. Ирекле дип инде?.. Ирекле дә, мәҗбүри дә. Һәрхәлдә, республиканың барлык предприятиеләре дә программага акча күчерүләрен дәвам итә. Үзенең ничек яшәп ятканын һәм республика халкының тузган торакларда ничек яшәгәнен матбугатта чагыштырып күрсәтүләренә кайсы җитәкче риза булыр икән? Сүзгә колак салмауның әнә шундый нәтиҗәгә китерергә мөмкин икәнлеге турында Минтимер Шәймиев үзенә хас тынычлык белән Татарстандагы барлык җитәкчеләрне кисәтеп куя.

АЧУЛЫ ЧАКТА БИК КУРКЫНЫЧ

Хәер, андый очраклар да була. 1997 елда «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасының башкарма директоры Тәлгать Абдуллин истәлекләреннән:

– ...1998 ел. Билгеле булганча, төзелеш өчен акчаны предприятиеләрдән җыябыз, һәм баштагы мәлдә бу эш бик үк уңышлы бармый – илдәге икътисадый хәл мактанырлык түгел иде. Әмма Татарстан Президенты эре предприятиеләрнең директорлары белән киңәшмә үткәрде, аларга максат куйды. Барысы да үз өлешен кертергә сүз бирде.

Бераздан ул аларны төзелеш урынына чакырып, эшнең ничек барганын күрсәтергә ниятләде. Билгеләнгән вакытта президент сараена килдем. Минтимер Шәриповичнең кәефләре яхшы, хәлләрне сораша, барысы да түләдеме, дип кызыксына. Икесеннән кала, башкалар барысы да түләде, дип җавап бирдем.

Директорлар янына чыгабыз. Президент бөтен кеше белән исәнләшә, теге ике директор да күрешергә кулын суза. Ә ул аларга шунда әйтеп куймасынмы:

– Ә сез монда ничек килеп эләктегез?

Һәм соңыннан менә китте, менә китте! Мин Шәймиевне беркайчан да андый итеп күргәнем юк иде. Ул әйткән сүзләр матбугат өчен түгел, хәтта безнең колаклар да шиңәрлек иде. Кыскасы, ул аларны чыбыркы шартлатып куып чыгарды, «Сезнең аркаларыгызны соңгы тапкыр күрүем булсын!» – диде ул иң ахырдан.

Икенче көнне директорларның берсе эштән куылган иде. Ә икенчесе минем янга килде дә, акча күчергән идек, дип ышандырды, янәсе, алар әле килеп кенә җитмәгән. Минем җаваплылыгым бәрабәренә генә Минтимер Шәрипович аны гафу итте. Предприятие җитәкчеләре белән бу темага башка беркинди сөйләшүләр дә кузгатылмады. Барысы да эшнең җитдилеген аңлады...

БАШКА ТОРМЫШ

Программаны финанслауда 35 меңнән артык инвестор-оешма катнаша. 1996 елда 300 миллион сум акчадан башлана – предприятиеләрнең акча янчыкларының шактый сай булуы йогынты ясый. Ә менә 2004 елда инвестиция кертемнәре күләме инде 4 миллиард сумга якын тәшкил итә. Программага барлыгы 20 миллиард 600 миллион сум акча җыела. Нәтиҗәсе дә күзгә күренерлек – республика башкаласындагы Савиново һәм Азино кебек микрорайоннар калкып чыга. ТР Президенты каршындагы бюджеттан тыш Дәүләт торак фонды тулаем республика буенча да зур эш башкара. Чистай, Алабуга, Яр Чаллы, Аксубай, Бөгелмәдә... Яңа йортлар, бәхетле өй туйлары – болар Программаның бер ягы гына. Аны тормышка ашыру Татарстанның 90 нчы елларда ярымүле хәлдә калган бөтен төзелеш индустриясен үстерүгә көчле этәргеч була.

Горки бистәсендәге һәм Кварталлардагы яңа заманча фатирларга күченгән кешеләр үз бәхетләренә әле озак кына ышана алмый йөри. Күп еллар хыялланган бәхетләре чынга аша. Һәм бу алар өчен бөтенләй башка тормыш була.

1996–2004 нче елларда 1 763 торак йорт төзелә, гомуми мәйданы 2,7 миллион квадрат метр булган торак файдалануга тапшырыла, 48 мең 576 фатир гражданнарны тузган торактан күчерү өчен бушлай бирелә.

ОҖМАХ УТРАВЫНА СӘЯХӘТ

1994 елның 31 мае. Казан. Балалар реабилитация үзәге ишегалдында, комлык янәшәсендә, бер снайпер хуҗаларча үзенә урын җайлый. Бик шәп оптикалы винтовка, үтә күренмәле битлек, бронежилет, камуфляж... Мондый көтелмәгән күршелектән бераз аптырап калган репортерлар сак кына профессионалны күзәтә. Хәер, һәр ике як та биредә бер үк эш буенча: Россия Президенты Борис Ельцинны көтә.

Автор:
Әскәр Сабиров

Президент бераз тоткарлана, һәм әлеге сәфәрне яктыртырга килүчеләр белән илбашын саклаучылар арасындагы дистанция бераздан ничектер үзеннән-үзе якыная.

– Гафу итегез, ә бу нәрсә ул сезнең? – дип сорарга җөрьәт итә республика газетасы хәбәрчесе Әнвәр Маликов, снайпер винтовкасына төртеп күрсәтеп.

– Тавышйоткыч.

– Ә нигә кирәк ул?

– Ничек инде нигә? Күз алдыңа китер, Борис Николаевич чыгыш ясый, беркем дә комачауламаска тиеш һәм менә нәкъ шул вакытта, әйтик, әнә теге тугыз катлы йортта яшәүче берәү балконга чыга...

– Чыкса нәрсә була?

– Ничек инде нәрсә?! Ә Борис Николаевичның кинәт кенә фикере чуалса? Менә артык тавыш чыкмасын өчен, безгә тавышйоткыч кирәк тә инде.

Аралашу кинәт үзеннән-үзе туктап кала. Репортерлар снайперның сүзләрен уйлап баш вата – шаяртып әйтүемеюкмы? Янәшәдәге йорт түбәләрендә ялтырап киткәләгән оптика да шомлану өчен җирлек тудыра...

Ишегалдында чиновниклар һәм сакчылар арасында Борис Николаевич белән Минтимер Шәймиев күренгәч, киеренкелек кими төшә. Ап-ак күлмәк кигән, елмайган Ельцин – гаҗәеп мөлаем. Әмма җирле журналистлардан беркем дә Президентка үзенең соравын бирә алмый кала. Ельцинны бина эченә алып кереп китәләр, ул анда балалар белән сөйләшә, сабыйлар аңа үзләре үргән кәрзиннәрен бүләк итә, аннары Президент башкала телевидениесе хезмәткәрләре микрофонына дежур сүзләр әйтә дә – шуның белән вәссәлам.



ИҢ МӨҺИМЕ – ИМИНЛЕК

Татарстан Президентының матбугат сәркатибе Әнәс Хәсәновның аннан алдагы көнне ни өчен мине президент кортежына кертергә тырышуы менә хәзер аңлашыла инде: югыйсә җирле массакүләм мәгълүмат чаралары сәфәрне Беренче канал күзлегеннән генә «күрә» алачак бит. Әмма Россия Президенты аппаратында драматургиягә бернинди үзгәреш кертергә дә җыенмыйлар: юк икән, димәк – юк. Икенче көнне иртән Әнәс Хәсәнов кунакларны кабул итүче як үтенечен тагын кабатлый.

– Юк, – ди тагын бер мәртәбә Россия Президенты аппараты вәкиле, әмма инде бераз уңайсызланган кебек тә күренә. Чөнки аның чөгендердәй кызыл йөзе, Казандагы төн йокысыз үткән ахры, дигән уйларга этәрә.

– Кырынганда киселдегезме әллә? – дип, кунак йөзенең кызыллыгына ишарәли Хәсәнов, аңардан күзен дә алмыйча.

– Ярар, – ди ахыр чиктә, ирониягә түзә алмыйча, чиновник. – Барсын алайса, кортежда...

Президент кортежы эченнән бөтенесе дә яхшы күренә: сак чарала-

ры – моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә. Уртасында Ельцин лимузины барган машиналар кавалькадасы буп-буш урамнардан җилдерә. Юллар ябык, транспорт йөрми. Кортеж башындагы микроавтобуста – камуфляж кигән кораллы баһадирлар.

Әмма болары чәчәк кенә булган икән әле. Кортеж Осиновога – «Майский» совхозына юнәлгәч, тагын да кызыграк хәлләр башлана. Горький шоссесының буеннан-буена милиционерлар чылбыры тезелгән, алар бер-берсеннән 15–20 адым ераклыкта тора. Беренче чылбырдан соң, урманда – тагын бер шундый ук тере чылбыр. Әмма милиционерлар да исәпсез-хисапсыз түгел бит. Кортеж трассадан бистә урамына борылуга, милиция чылбыры башта сирәкләнә, аннары юкка чыга. Формалы кешеләр урынына – һәр капка төбендә җиңенә бәйләвеч таккан җәмәгать активисты.

«Майский» совхозы территориясенә беренче булып снайперлар утырган микроавтобус керә. Аларны тиешле урыннарга урнаштырып чыккач кына, Борис Николаевич утырган лимузин килеп җитә.

1990 НЧЫ ЕЛЛАР УРТАСЫНДАГЫ ОАЗИС

– Республика үзе теләгән кадәр суверенитет алганнан соң, мин Татарстанда халыкның ничек яшәвен карарга килдем, – дип, сәфәренең максатын аңлата Ельцин аэропортка килеп төшүгә үк.

Һәм башта курка-курка гына каравы яхшы тоемлана. Татарстанның фетнәле төбәк буларак имиджы аны үзләре үк уйлап чыгарган башкала акыллыбашларына әле һаман тынгы бирмәвә сизелә. Республика чигендәге гаскәрләр, Мәскәү ихтыярына каршы килеп үткәрелгән референдум һәм анда татарстанлыларның үз җөмһүриятләренең халыкара хокук субъекты булуын даулап алулары, катлаулы сөйләшүләр барышы – болар барысы да күптән түгел генә булган хәлләр бит әле. Хәтта РФ һәм ТР дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турында Шартнамәне дә Мәскәү белән Казанның моннан өч ай элек кенә имзалаган чагы…

Әмма «Майский» янында, якын килергә ярамаганга ерактарак торсалар да, кешеләр Ельцинны ихластан сәламли, аларның кулында бернинди плакатлар да юк, һәм бу үзеннән-үзе киеренкелекне бетерә. Ә инде теплица комплексы территориясе буенча беренче адымнарыннан ук делегациянең кәефе бөтенләй күтәрелә. Ни әйтсәң дә, Татарстанда кунак каршылый беләләр шул: «Майский»да лимоннар өлгерә, тропик чәчәкләрдән хуш ис аңкый, плантацияләрдә исә кызарып пешкән помидор, борыч, сусыл кыярлар күзне иркәли… Салмак адымнар белән Ельцин атлап барган оазис үзеннән-үз, Татарстанда оҗмах ук булмаса да, ул каядыр янәшәдә генә, ахрысы, дигән уйлар уята түгелме соң?

Күтәренке кәеф бер генә тапкыр – Ельцинны озатып йөрүчеләр арасында бәхәс купкач кына бозыла яза. Республика газетасы мөхәррирен Яр Чаллыдагы милләтчеләр пикеты турындагы язмасы өчен шелтәли башлыйлар – ТР җитәкчелеге фикеренчә, андый пикет бөтенләй уздырылмаган була. Россия Президенты янында ук татарча бәхәсләшәләр, әлбәттә, Ельцин бернәрсә дә аңламый, әмма гаҗәпләнүен дә яшерә алмый…

Әмма бу тиз онытыла, Президент мактавыннан канатланган хуҗалар саф һавада, алдан ук әзерләнгән чатырларда табын кора. Биредә чәй, чәкчәк һәм бераз суынган өчпочмаклар белән тамак ялгаганнан соң, Ельцин, култамгасын салып, янәшәдәгеләргә китаплар бүләк итә – журналистларга гына эләкми, алар бу хәлне ерактан гына күзәтергә мәҗбүр була…

КИЛӘЧӘК БҮГЕНГЕДӘН ЯХШЫРАК

«Майский» бигрәк тә Ельцинны озатып йөрүче түрәләргә ошаячак. Юмарт хуҗалар башкаладан килгән кунакларның кофр һәм дипломатларына теплицада үскән нигъмәтләрне төяп җибәрәчәк, һәм канәгать әфәнделәр Казанга кайтып җиткәнче, хәзер инде ликер-аракы сәнәгатенең җирле предприятиеләре эшен барып карасаң да шәп булыр иде, дип шаяртачак.

Әмма сәфәр программасы югарырак бурычларны күздә тота. Татарстан Россия Президентына үзенең тагын сыйфатын – толерантлыгын күрсәтә: Петр һәм Павел соборында һәм Мәрҗани мәчетендә.

Мәчеткә кергәндә, Ельцин, шәригать кушканча, аяк киемен сала һәм бүләк ителгән түбәтәйне кия, шул рәвешле миллионнарча мөселманның ихтирамын яулый.

Россия Президенты статусында Татарстанга беренче сәфәре вакытында Борис Ельцин әдәпле, тыйнак, аз сүзле була. Ул да, татарстанлылар да үзара хөрмәт саклый. Ихтимал, нәкъ менә шул сәфәрнең иң мөһим нәтиҗәсе булгандыр һәм күпләрдә безнең уртак киләчәгебезнең хәзергедән яхшырак буласына ышаныч тудыргандыр да.

Дөрес, бер журналист соңрак әлеге сәфәрне экскурсия, дип атаячак. Чөнки Президент Казанда бер генә проблемалы предприятиегә дә бармый. Хәтта Ельцин карарларыннан соң юкка чыгу халәтенә килеп җиткән, төзелеп бетмәгән Ту-160 самолетлы авиация заводын да барып карарга теләүче табылмый.

Хәер, мондый төр проблемаларны харизма һәм сөйкемлелек белән генә хәл итеп булмый шул…

«БЕТАР»: ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАРДА ЧЫНЫККАН КОМАНДА

«90 еллар буыны» проекты кысаларында без ил өчен дә, республика өчен дә катлаулы елларда Татарстанда барлыкка килгән предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар турында сөйлибез. Алар кризисларга бирешмичә, аякларында басып кала алганнар, бүген дә уңышлы эшләп киләләр. Шундыйларның берсе – «Бетар» Җитештерү-коммерция фирмасы» ЖЧЖ – Россиядә энергия ресурсларын исәпкә алу приборларын җитештерүче алдынгы предприятиеләрнең берсе. Бүгенге көнгә ул ныклы нигезе, куәтле базасы һәм уникаль тарихы булган көчле предприятие булып килеп җиткән.

«БЕТАР» Җитештерү-коммерция фирмасы («БЕТАР» ЖКФ» ЖЧЖ) 1996 елда Чистай шәһәрендә оештырыла. Җитәкчеләр башта ук энергияне саклау юнәлешенең перспективалы булуын аңлап, югары сыйфатлы продукция җитештерүгә йөз тота. Предприятие Татарстанда беренчеләрдән булып, коммуналь һәм шәхси су куллану системаларында эчә торган суны исәпләү приборларын җитештерә башлый. Җитештерү өчен биналар һәм җиһазларны арендага алып, квалификацияле кадрларны җәлеп итеп, компания конструкторлык эшләнмәләреннән башлап, сатуга кадәр җитештерү циклын оештырып җибәрә. Төгәл исәпләнгән алгоритмнар тиз арада эшләп китәргә һәм көндәшлеккә сәләтле продукция җитештерергә бирә. «БЕТАР» СГВК-15 һәм СХВК-15 су исәпләү приборлары җитештерүне җайга сала.

Әмма икътисадта базар реформалары һәм кризис башлану белән, концепцияне тамырдан үзгәртеп, яңа конструкцияле су исәпләү приборларын ясый башлау ихтыяҗы туа. РФ һәм БДБ илләре масштабларында ТКХ реформаларын үткәрү һәм энергия ресурсларын исәпкә алу зарурлыгын аңлап, «БЕТАР» фирмасы ВНИИР (Казан), «Татарстан» Стандартлаштыру, метрология үзәге» ФБУ (Казан), «Эрготех» фәнни-җитештерү берләшмәсе (Минск), «Теплоприбор» ФТИ» АҖ (Мәскәү) белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, салкын һәм кайнар су куләмен санау өчен яңа су исәпләү җиһазларын җитештерүне оештырып җибәрә. Тәҗрибә бик уңышлы килеп чыга – беренче елны 120 мең прибор эшләп чыгарыла һәм сатыла.

1997 ел ахырына фирманың формалашу этабы тәмамлана, компаниянең ышанычлы партнер дигән имиджы барлыкка килә. «БЕТАР»ның иң зур өстенлеге клиентка юнәлгәнлек, аның ихтыяҗларына һәм теләкләренә игътибар итүдә була. 1998 елда коллективта 100 гә якын кеше эшли. Өч товар билгесен теркәү өчен гариза бирелә, алар «БЕТАР» фирмасының сыйфат билгесе булып тора, товарның көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итә, су исәпләү җиһазларын ялган күчермәләреннән һәм фальсификацияләрдән ышанычлы рәвештә саклый, үз-үзенә иң яхшы реклама вазыйфасын да үти. 1999 елда товар билгесе таныклыкларын алалар.

Компаниянең профильле күргәзмәләрдә катнашуы да үз нәтиҗәсен бирә – Россиянең һәм БДБ илләренең күп төбәкләрен дә иңләп, продукцияне сату базары киңәя, Омск шәһәрендә, Казахстан, Белоруссия, Үзбәкстан белән уртак предприятиеләр барлыкка килә. Беренче елларда төп бурыч үтәлә – иң югары сыйфатлы су һәм газ исәпләү приборлары чыгару хисабына базарда үз урыныңны табу. Моның өчен техник үсеш һәм җитештерүне нәтиҗәле итү буенча чаралар уңышлы башкары-

Реклама
Фото «ПКФ «БЕТАР» ЖЧЖнән алынды

ла. 1999 елда компания СГ-1 газ исәпләү приборы, СХВ-20 һәм СГВ-20 тибындагы салкын һәм кайнар су исәпләү приборы җитештерүне оештырып җибәрә. Шушы ук елда фирма, МС ИСО 9000 таләпләренә туры килә торган сыйфат системасын эшләп, кулланышка кертеп җибәрүне дә башлый. Ике меңенче еллар башында хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын яхшырту өчен җитештерү мәйданнарына ремонт ясау буенча зур эшләр башлана, ә 2000 елның июлендә миллионынчы су исәпләү җайланмасы чыгарыла.

Метрологик тәэмин итү – энергия ресурсларын исәпкә алу приборларын җитештерүнең мөһим ягы. 2003 елда предприятиене су һәм газ исәпләү җайланмаларын тикшерү хокукына аккредитацияләү турында актка кул куела. Бәяләүне Россиянең баш метрологы В.М. Лахов башкара. «БЕТАР» үзенең Дәүләт стандартына ярашлы булуын раслап, калибровкалау эшләренә аккредитацияләнде. 2004 елда «БЕТАР» актив рәвештә су һәм җылылык исәпләү буенча турбиналы җайланмалар җитештерүне үзләштерә, су һәм газ исәпләү приборларына хезмәт күрсәтү сервисы проблемаларын хәл итү белән шөгыльләнә башлый. Су һәм газ исәпләү җайланмаларын калибровкалау һәм тикшерү өчен стендлар булдырыла. 2008 елда компания автоматлаштыруга йөз тота, ә 2013 елда ул актив рәвештә эш кораллары, станоклар, тутыкмый торган корычтан эшләнмәләр җитештерә башлый. 2016 елдан башлап, компания базасында Италиядәге коллегалары белән коелма формалар проектларын ясап җитештерү буенча инженерлык үзәге булдырыла.

Бүгенге көндә «БЕТАР» Россиядә су исәпләү приборлары чыгару күләме буенча лидерларның берсе, шулай ук Россия Федерациясе һәм БДБ илләре төбәкләрен су һәм газ исәпләү җайланмалары җитештерүчеләр арасында гарантияле хезмәт күрсәтү саны буенча да алдынгылар рәтендә. Предприятие 40тан артык төрле продукция эшләп чыгара, алар арасында су, газ, электр уты, җылылык исәпләү җайланмалары һәм өстәмә аксессуарлар бар. Моннан тыш, «БЕТАР» «Акыллы йорт» энергия ресурсларын комплекслы исәпләү буенча автоматлаштырылган системаны эшләп, аны кулланышка кертү белән шөгыльләнә, шулай ук заказга кою ысулы белән ясалган пластмасса эшләнмәләр дә җитештерә. 500 кешелек коллективы булган эре, ышанычлы һәм хөрмәт яулаган компания ай саен 1 миллионга кадәр данәдә су исәпләү, 150 мең данәгә кадәр газ исәпләү приборы эшләп чыгара ала. «БЕТАР» җайланмаларының популярлыгын саннарда болайрак күрсәтеп була: 25 елга якын дәвер эчендә фирма 75 миллионнан артыграк берәмлек продукция җитештергән. Кешеләр – компаниянең төп ресурсы алар. Нәкъ менә алар аркасында шундый җитди нәтиҗәләргә ирешелгән дә инде. Компаниядә хезмәттәшләрне даими рәвештә укытып торалар, җитәкчедән башлап, гади эшчегә кадәр белеменәрен камилләштерәләр. Биредә һәркем үзенең шәхес буларак үсүен тоя.

«БЕТАР» ҖКФ» ҖЧҖ – Россия территориясендә «АСКУПЭ «САКЛАУ» автоматлаштырылган системасы аша мәгълүматларны ерак арадан диспетчерлык системасы белән бер комплекста тапшыра һәм энергия ресурсларының барлык типларын бергә исәпләү җиһазлары чыгара торган бердәнбер предприятие. «БЕТАР» фирмасында җитештерелгән исәпләү җиһазлары Россиядә һәм чит илләрдә үткәрелгән дәрәҗәле күргәзмәләрдә һәм конкурсларда 50 тапкырдан артык лауреат һәм дипломат булган. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: исәпләү җиһазларын җитештерү процессы әйләнә-тирәгә зыянлы түгел, технологик процесста электр энергиясе, кысылган һава, су һәм экологик яктан куркыныч тудырмый торган чимал һәм материаллар кулланыла.

Кулланучыларга уңайлы булсын өчен, фирманың вәкиллекләре Россиянең 70 төбәгендә, шулай ук Белоруссиядә, Казахстанда, Үзбәкстанда, Төрекмәнстанда, Кыргызстанда һәм Монголиядә булдырылган. Кайнар элемтә эшли – телефоны: 8-800-500-45-45 (Россия буенча шалтырату бушлай). «БЕТАР» ҖКФ» ҖЧҖнең менеджменты системасы ISO 9001 (сыйфат менеджменты системасы) таләпләренә ярашлы сертификацияләнгән. Фирма ике тапкыр РФ Хөкүмәтенең сыйфат өлкәсендә премия лауреаты булган, ТР Хөкүмәтенең сыйфат өчен премиясе лауреаты булып тора. 2013 елда продукция һәм хезмәтләндерү сыйфаты өлкәсендә казанышлары өчен БДБ илләре премиясенең лауреаты булган. Шулай ук «БЕТАР» Бөтенроссия сыйфат оешмасының Дан залына да кертелгән.

«БЕТАР» ҖКФ» ҖЧҖ Татарстан Республикасының һәм шәһәрнең социаль бурычларын хәл итүдә дә актив катнаша, дини оешмаларга һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләренә ярдәм итә. Инвалид балаларга, Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә һәм фирманың лаеклы ялдагы пенсионерларына социаль ярдәм күрсәтә. ТР Һәм шәһәрнең башка предприятиеләре белән берлектә фирма спортка, туризмга, мәдәнияткә һәм күңел ачу өлкәсенә дә үз өлешен кертә.

Болгар ислам академиясенең тантаналы ачылышы (Болгар, 2017 ел).

Ак мәчет (Болгар, 2013 ел).

МИРАСНЫ САКЛАУ – КИЛӘЧӘККӘ ЮЛ

Республиканың төзелеш тармагы бүгенге көндә лаеклы рәвештә илдәге иң тотрыклы юнәлешләрнең берсе санала. Аның нигезен тәҗрибәле һәм ышанычлы төзелеш оешмалары тәшкил итә. Шундыйларның берсе – 1998 елның 17 июлендә оешкан «Грань» компаниясе.

Әлеге еллар эчендә «Грань» ЖЧҖ зур булмаган ремонт-төзелеш кооперациясеннән динамик рәвештә үсеп килүче, югары технологияләргә йөз тотучы республика төзелеш компаниясенә әверелде. Бүгенге көндә «Грань» – холдинг тибындагы эре төзелеш предприятиесе, ул идарәче компанияне һәм төрле хезмәтләр күрсәтүгә махсуслашкан оешмалар челтәрен үз эченә ала. Компания үз эшчәнлеген ике эре юнәлеш буенча алып бара: заказчы-төзүче функциясен башкаруны да күз уңында тоткан инвестицияле эшчәнлек (девелопмент) һәм подрядчы буларак башкара торган эшчәнлек, монысы инде заказчы һәм генподрядчы сыйфатында төзелеш-монтаж эшләре комплексын башкару, дигән сүз.

Оешма төзелеш эшләре базарында үзен ЕРСМ-подрядчы буларак таныта һәм тулы төзелеш циклы белән тәэмин итүче компанияләр сафында тора. Ягъни төзелешнең концепциясен эшләүдән башлап, эксплуатациягә тапшыруга һәм гарантия хезмәтен күрсәтүгә кадәрге этапларның барысын да тулаем үтәп чыга. Төзелеш компаниясе үзенең эшләү дәверендә катлаулылыгы буенча гаять төрле булган 95 федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге проектны тормышка ашырды.

«Грань» компаниясенә социаль билгеләнештәге объектларны төзүне һәм төзекләндерүне ышанып тапшыралар. Аның эшләре исемлеге шактый саллы: 2013 елда Универсиаданы уздырыр алдыннан төзелгән «Акчарлак» йөзү бассейны, Казандагы – «Соловушка», Чаллыдагы «Фиалка» һәм «Уенчык» балалар бакчалары, Галиәсгар Камал исемендәге театр, ТР Язучылар берлеге биналарын төзекләндерү, элеккеге Апанаевлар йорты – 7 нче номерлы шәһәр поликлиникасы һәм башка җитди объектлар.

«Грань» ЖЧҖ республиканың икътисадый потенциалын үстерергә тиешле сәнәгать объектлары төзи. Шулар арасында «Чаллы-Бройлер» ЖЧҖ кош ите җитештерү һәм эшкәртү буенча инновацион комплексы бар, ул бер сәгать эчендә 9 000 башны эшкәртергә мөмкинлек бирә. Тагын берсе – Яр Чаллыдагы минераль-витаминлы катнашмалар һәм комбиазык җитештерү буенча махсуслашкан завод.

Казанда компания торак төзү проектларын тормышка ашыра. Ул үзенең клиентларына квадрат метрлар гына тәкъдим итеп калмый, ә яхшы сыйфат белән югары тормыш дәрәҗәсе дә бүләк итә. Шул рәвешле «Грань» ЖЧҖ Кече Кызыл һәм Япеев урамнарындагы биш катлы йортларны, Академик Губкин урамындагы торак комплексын, Мәүлетов урамындагы 16 катлы йортны төзеп тапшырды. 2018 елда Рауис Гәрәев урамындагы эре торак комплексы – «Соловьиная роща»ны тапшырдылар, аның гомуми мәйданы 11, 2 гектарны тәшкил итә. 2016 елдан «Грань» «Яңа Горки» парк-шәһәре» Торак комплексын төзү белән мәшгуль, аның гомуми мәйданы 19,06 гектарны тәшкил итә.

«Грань» төзелеш компаниясе республиканың эре программаларында катнаша. «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя шәһәр-утравы» республика проекты кысаларында оешма Ак мәчет, Болгар ислам академиясе, Болгардагы Истәлек билгесе кебек әһәмиятле объектларны төзеде. 2018 елда «Грань» ЖЧҖ «Кол Гали» кунакханәсен эшләп өлгертте, бу бина XIV гасырның Ак пулатына аналог буларак корылды, ул үз эченә мунчалар комплексын да ала.

Хәзерге вакытта компания «Казан-Экспо» Халыкара күргәзмә залын ре-

Фотолар «Грань» ЖЧҖ нән алынды.

Реклама

Мунча комплексы да булган «Кол Гали» кунакханәсе – XIV гасырның Ак пулаты аналогы (Болгар, 2018 ел).

«Кол Гали» кунакханә комплексын РФ Президентының И(б)ФОндагы тулы вәкаләтле вәкиле М. В. Бабич (2011–2018), ТР Президенты Р. Н. Миңнеханов һәм ТР Дәүләт Киңәшчесе М.Ш. Шәймиев карыйлар. (Болгар, 2017 ел).

конструкцияләү юнәлешендә эшли. «Адымнар – путь к знаниям и согласию» мәгариф проекты кысаларында Бичурин урамында 800 кеше сыйдырышлы билингваль мәктәп, Бондаренко урамында йокы корпусы да булган 1224 кеше сыйдырышлы полилингваль мәктәп һәм «Ялкын» савыктыру лагере төзү белән мәшгуль.

«Грань» ЖЧҖ Татарстан тормышында актив катнаша: чиркәүләр, монастырьлар, мәчетләргә, физик үсешендә тайпылышлар булган балалар интернатларына, хәйрия оешмаларына даими ярдәм итеп килә. Хәйрия проектлары түбәндәгеләр: Яшел Үзән районындагы Раифа монастыренең Борадәрләр комплексы, Югары Ослан районындагы Введенск-Богородица храм-мөсафирханәсен төзекләндерү, Зөядәге Гражданнар сугышы музее урнашкан йортта яшәгән кешеләрне күчереп урнаштыру өчен торак йорт торгызу.

Компаниянең эшчәнлеге федераль һәм төбәкара дәрәҗәдә әллә ничә мәртәбә югары бәя алды. Көндәшлеккә сәләтлелекнең югары дәрәҗәсен, коллективның тотрыклылыгын һәм һөнәри осталыгын күпсанлы рәхмәт хатлары, бүләкләр һәм бәйгеләрдә откан җиңүләр раслый.

2019 елда «Грань» компаниясе Бөтенроссия иң яхшы төзелеш оешмасы конкурсы нәтиҗәләре буенча иң югары бүләккә – «Төзелеш тармагының алтын фонды» беренче дәрәҗәдәге дипломы белән кубогына ия булды. 2018 елда оешма республиканың «Ел төзүчесе» премиясенә лаек дип табылды, ә 2012 һәм 2016 нчы елларда «Эшлекле камиллек» номинациясендә республика хакимияте премиясенә дәгъва итүчеләр арасында җиңеп чыккан иде. «Грань» ЖЧҖ ел саен «Россиянең ышанычлы төзүчесе» исемен лаеклы рәвештә раслап килә.

ТР төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры И.Э. Фәйзуллин (2010–2020) «Ел төзүчесе» Беренче республика премиясе нәтиҗәләре буенча «Татарстан Республикасының иң яхшы төзелеш компаниясе» бүләген тапшыра. (Казан, 2018 ел).

«Соловьиная роща» торак комплексы. (Казан, 2018 ел).

«Яңа Горки» парк-шәһәре (Казан).

ЗИЛӘ ВӘЛИЕВА: «АШАГАН ДА БЕЛӘ, ТУРАГАН ДА БЕЛӘ»

Бүген «Татарстан»ның «Аш-су бүлмәсе»ндә узган гасырның 90 нчы еллары белән бәйләргә булдык. Баш пешекче алъяпкычын ТР Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева киде. Ул хәзер шушы вазыйфада. Ә телгә алынган 90 нчы елларда исә, «Википедия» әйтүенчә, Зилә Вәлиева – «Татарстан Республикасының иң йогынтылы сәясәтче ханымы» була.

Автор:
Татьяна Вафина

МОДАЛЫ САВЫТ-САБА

– Сезгә чүлмәктә ит пешерергә җыенам, – дип елмая Татарстанның иң йогынтылы сәясәтче ханымы. – Тик анда ит янына тәм өчен бәрәңге дә өстәрбез, без шулай гадәтләнгән. Суганны атланмайда алтынсу төскә җиткәнче кишер белән кыздыру мәҗбүри – бу йомшак тәм бирә. Хәтерлим әле, 90 нчы елларда чүлмәкләр модага кергән генә иде, мин аларны шул вакытта сатып та алдым. Кибетләрдә азык-төлек кенә түгел, матур савыт-саба да юк иде бит. Хуҗабикәләргә шактый кыенга туры килде. Ә монда – тегенди-мондый гына нәрсә түгел, ә чүлмәкләр! Аларда гап-гади итле бәрәңге дә тәмле килеп чыга, кунак сыйларга да оят түгел, гаиләне дә туйганчы ашатырга була. Өстәвенә эше дә тиз – чүлмәкне мичкә куясың да калган нәрсәләрне тыныч кына әзерли аласың. Ә чүлмәктә итнең шулпалы булуы бер үк вакытта ике ризыкны алыштыра: ул шулпа да, икенче ашамлык та булып тора. Хуҗабикәләргә уңайлы ярдәмче булды ул чүлмәкләр.

Өстәвенә, бу ашамлык – студент еллары истәлеге дә. Мәскәүдә үз вакытында «Садко» кафесы бар иде – анда гомеремдә беренче тапкыр шушы ризыкны татып карадым. Студентлар өчен кафега бару зур вакыйга иде. Шунда чүлмәкләрне күргәннән соң, кайчан да булса, үз йортым белән яши башлагач, мин дә шулай чүлмәктә пешерермен дип хыялланып куйган идем...

– Хыял тормышка аштымы соң?

– Әлбәттә. Хәер, хәзер бу ашамлыкны өйдә сирәк әзерлиләр. Минә бу чүлмәкләремнең кайда торганын да искә төшерә алмый тор-

КИРӘК БУЛАЧАК
(6 ЧҮЛМӘККӘ):

- Ит – 900 г;
- Бәрәңге – 2 данә;
- Суган – 1 данә;
- Кишер – 2 данә;
- Төшле караҗимеш – һәр чүлмәккә 3–4 данә;
- Тоз, борыч – тәме өчен җитәрлек кадәр;
- Атланмай – 20–30 г.

Фото: Ната Смирнова

Глубокоуважаемые читатели журнала «Татарстан»!
Желаю вам здоровья!, интересных встреч, верных друзей, а самое главное менее родных людей!

дым. Көчкә таптым. Ашау-эчүдә карашлар үзгәрде, мода алышынды һәм чүлмәктәге ит хәзер хуҗабикә әзерләп шаккатыра алырдай ризык түгел. Тик ул, аңа карап, тәмлелеген бер дә югалтмый!

ИКЕ КУЛЫ ДА ОСТА

– Пешерергә яратасызмы?

– Кулинария өлкәсендәге сәләтләрем турында әйтүегез икән, мин күбрәк башкалар әзерләгәнне яратам. Мин кеше пешергән ризыкларны бәяләргә остарак…

– Бүген «Татарстан» бу рәхәт һәм тәмле эшне үз өстенә ала…

– Күңелегезне төшермәскә тырышырмын, – дип вәгъдә бирә Зилә Рәхимҗан кызы, сул кулы белән ит кискәндә. – Ә язуны уң кулым белән язам мин, сулы белән тегәм, кисәм-турыйм, әтием сулагай булгангадыр, мөгаен.

– Ягъни ике кулыгыз да оста булып чыга?

– Димәк, шулай. Ит кисәкләре бик вак булмаска тиеш, югыйсә алар сусыллыгын югалта. Шуңа эре-эре итеп турыйм– алай аны ашарга да рәхәт, чөнки һәр кисәк үзенә шулпаны сеңдерә. Болай турау тизрәк тә әле. Хәер, 90 нчы елларда минем кухняда, өйдә пешеренеп-тозлап торырга вакытым булмады. Бөтен халык урамга чыккан кебек иде! Митинглар, ачлык игълан итүләр, төрле хатларга имзалар җыю… Кайчак без, депутатлар, Югары Совет сессиясеннән үк, үзсүзле төркемнәрнең фикерләрен тыңлар өчен, мәйданга чыгабыз. Аннары янә залга әйләнеп кайтабыз, кызу бәхәсләр, кайнар чыгышлар анда да суынырга уйламый. Кайчагында фикер алышулар, бәхәсләр төн уртасыннан соң гына тәмамлана…

– Итне чүлмәккә салабыз, аннары– суганны…Иттән аермалы буларак, суганны вак кына турыйбыз, – дип дәвам итә Зилә ханым.– Ул безгә тәм өчен генә кирәк. Кишерне бераз эрерәк тә ярый… Кухняда вакыт бик тиз үтә ул. Әмма ни дисәң дә, бу – теләсә кайсы хатын-кыз өчен бик мөһим минутлар. Һөнәри вазыйфаларың аш-су булмәсеннән никадәр генә ерак китмәсен, хатын-кызда үз гаиләсен табынга җыю теләге мәңге бетми.

ТОКМАЧ НЕЧКӘРӘК БУЛГАН САЕН КИЛЕН УҢГАНРАК

– Гадәттә нәрсә пешерәсез?

– Борщ пешерергә яратам. Элек токмачлы аш белән бик мавыга идем. Мин бит авыл килене, токмач нечкәрәк булган саен киленнең яхшырак икән белеп торам. Мин бу яктан шәһәр хатын-кызларын оятка калдырмаска тырыштым, токмачымның супернечкәлеген һәркем истә калдырырлык итеп кисә идем. Осталыгымны тәүге тапкыр күрсәтүгә үк, киленнең уңган-булган икәнен барысы да аңлады. Һәм мин моны бүген дә күз ачып йомганчыэшләп куя алам: камыр басып, токмачны нәзек кенә түгел, сокланырлык итеп кисеп бирәм. Аны бит карап торуы ук күңелле: шулпа кайнап тора, шуңа токмач саласың – үзе бер матурлык. Халкыбызның борын-борыннан килгән кухнясы – сәнгать ул. Һәм бу сәнгать миңа бик кадерле. Республикада дөньяның иң тәмле гөбәдиясен, дөньядагы иң тәмле токмачлы аш пешерә торган остабикәләрне беләм... Хатын-кызлар шаккатыра белә ул. Хәтта иң гади камырдан да искиткеч тәмле ризыклар пешереп куя алалар, чит ил кунакларын да сыйлау оят түгел. Барысы да бездәге милли ашамлыкларыбызның шундый тәмле булуына гаҗәпләнә. Сезнең ризыкларыгыз авыр, без андыйны ашамыйбыз дип, баштарак сөйләнеп торган европалыларны үзем дә очратканым бар. Ә авыз итеп карагач– тәмам гашыйк булалар безнең сыйларга!

МИЧТӘН – ЖУРНАЛИСТЛАР ЙОРТЫНА

Зилә Рәхимҗан кызы чүлмәкләргә соңгы «тәмләткеч»– караҗимеш сала да аларны мичкә озата.

– Әлегә без яшелчәләрне әзерли тора алабыз. Яшелчәләрне турамыйча, бөтен килеш кенә, укроп сабаклары, яшел суган кыяклары белән бирү гадәтен Мәскәүдә элекке Журналистлар йортында күргән идем. Мине СССР Журналистлар берлегенә шактый яшьли кабул иттеләр. Берлек әгъзалары шундый өстенлеккә ия: Мәскәүдәге «Домжур» бинасына тоткарлыксыз кертәләр. Шулай итеп, студент елларында ук иң затлы урыннарының берсе булып саналган Журналистлар йортына кереп йөри алдым. Анда яхшы кафе, ресторан да булгач, элегрә өчен һәркем атлыгып тора иде. Тик таныклык белән генә кертәләр. Таныклыгы булган кеше дусларын да алып килә ала. Без – яшь журналистларның– кыйммәтле ризыкларга заказ бирер мөмкинлеге юк. Ә менә арзанлы «яшелчә» ишегә акча җитә. Әмма, аның каравы, монда публицист Анатолий Аграровскийны, халыкара хәлләр турында язучы атаклы журналистлар Валентин Зоринны, Александр Бовин, Александр Каверзневны тыңлау мөмкинлегебез бар. Шәп бит! Башка кешеләр телевизордан гына күргән шәхесләр белән янәшә утырасың, бер тиң булып аралашасың. Монда шундый дәрәҗәле кешеләр җыела, ә сез сипкелле кызыйлар монда нишлисез, дип шаярталар да иде әле! Ә икенче-өченче тапкыр очрашуда инде бер-беребезне таный башлыйбыз. Алар искиткеч кызыклы кешеләр иде! Әнә шундый онытылмас очрашулар өчен мин журналист һөнәремә рәхмәтлемен.

Ә УКРОП КАЯ?

– Сез ни өчен шушы һөнәрне сайладыгыз? Балачак хыялы идеме әллә?

– Хыял бөтенләй башка иде. Минем өчен журналистика мәктәп иншалары конкурсыннан башланды. Анда минем очучы буларга хыяллануым турында иншам җиңде. Мин хәтта парашюттан сикерү мәктәбендә дә укыдым, тик әни сикерергә рөхсәт бирмәде: «Минем йөрәгем чыдамас», – диде ул.

Журналистика юлын сайлауга шул инша һәм менә дигән педагогларым булу тәэсир иткәндер. Мәктәптә кешегә очар канат куялар дигән фикерем хәзер дә үзгәрми. Шуңа күрә мәктәп минем өчен һәрвакыт изге урын булды– андагы остазларны ихлас яраттым. Барлык укытучыларны да хәтерлим. Үземнең очучы булу нияте белән ничек янып йөргәнемне дә онытмыйм.

Әле дә исемдә, әни борщ әзерли иде һәм ул мине базарга яшел укроп алырга җибәрде. Мин анда баргач, радиодан: «Кеше галәмгә очты!»– дигән хәбәрне ишеттем. Бу шундый зур вакыйга бит! Мин ашыга-ашыга өйгә йөгердем, бусагадан ук: «Ни булганын ишеттегезме?»– дип сөрән салдым. Алар, әлбәттә, ишеткән инде, радио бит һәр йортка кертелгән иде, мин йөгерә-чаба кайткан арада, бу яңалыкны ишеттерергә, уртаклашырга өлгергәннәр. Ә мин аны-моны уйларлык түгел идем, шундый яңалыкны өйгә беренче булып җиткерәсем килә: «Гагарин космоста!»– дип кычкырам. Әни: «Ә укробың кая?» – дип сорап куймасынмы?!Укроп турында бөтенләй оныткнмын.

Ул чакта андый героик һөнәр ияләре балаларга бик зур йогынты ясады. Очучылар, космонавтлар һәркемнең теленнән төшми иде. Барысы да шул һөнәрләр турында хыяллана. Җитмәсә, озакламый беренче хатын-кыз космонавт Терешкова да галәмгә очты. Очучы булу хыялы әнә шуннан килә дә.

НИЧЕК «АТАКЛЫ ЯЗУЧЫ»ГА ӘЙЛӘНДЕМ?

Химия укытучысы Нина Ильинична көтмәгәндә миңа: «Зилә, каян керде ул синең башыңа, нинди очучылык ул? Сиңа журналист булырга кирәк!»– дип әйтмәсенме! Ә мин бу һөнәрнең нәрсә икәнен дә белми идем. Ә ул вакытта Леонид Жуховицкийның журналист турында романы чыкты. Һәм кирәк бит, шундый хәл, Жуховицкий безнең китапханәгә килде. Бу бик мөһим вакыйга булды. Аның белән очрашудан соң кешеләрнең илһамланып китүен күрдем дә беренче тапкыр шул һөнәргә йөз тотарга карар кылдым. Бу 8 нче сыйныфта укыган чак иде.

Республикабыздагы яшьләр газетасы карамагында яшүсмерләр клубы эшләде, мине шунда алдылар. Безгә, материаллар язып, яшьләр газетасының үсмерләр сәхифәсен тутырырга тәкъдим иттеләр. Эшем әллә ни уңышлы да бармады кебек. Очучылык белән янып йөрүемне сөйләп бирдем дә, ә аннары нәрсә? Башка кешеләрне мактаганда, мөгаен, бу һөнәр минем өчен түгелдер, дигән уйлар да килгәләде. Ә ул вакытта хоккей буенча җыелма командабыз бөтен дөньяга шаулый иде. Һәм малайлар да, кызлар да – барысы да телевизордан дөнья чемпионатларын күзәтә, сәгать аермасы аркасында төне буе хоккей карыйлар, бигрәк тә Канада белән атаклы серия вакытында. Минем сыйныфташым – Валера Самойлов хоккейның чын җанатары иде. Без кайчак аның янына матч карарга җыела идек. Валера үзе дә хоккей уйный. Менә ул чып-чын хоккейчы киемендә телевизор каршына утыра, без аның тирәли җыелабыз. Ул команда өчен шулкадәр ихлас җан ата иде, кайчак

кәшәкәсе белән идәнгә шакый башлый һәм: «Анатолий Иванович, мине, мине чыгарыгыз!»– дип кычкыра (Анатолий Иванович Тарасов– ул вакытта җыелма команданың тренеры. **– Ред.**). Сыйныфташымның шулай хоккей каравы турында «Яшүсмер» битенә юмореска язып бирдем. «Җыелма командадагы 23нче уенчы» дип аталган хикәя газетада басылып чыкты һәм мин бер көндә атаклы «язучы кыз»га әйләндем дә куйдым.

ОСТАЗЛАРДАН УҢДЫМ!

Шуннан соң Журналистлар берлеге рәисе Давид Самойлович Гальперин мине үз янына чакырды. Нинди кешеләр эшләгән бит! Югыйсә мин– мәктәптә укучы гап-гади кыз, кем инде аңа! «Сиңа язарга, укырга кирәк», – дип, ул миңа хәер-фатихасын бирде.

Ә ул вакытта, МДУга керү өчен, «Журналист» журналында каләм тибрәтүчеләр конкурсы үткәрелә иде. Мин анда катнаштым, әмма җиңүчеләр исемлегенә эләкмәдем. Аның каравы, журналист Ирина Викторовна Склярдан хат алдым. Хәтта өч битлек хат! Һәм бу мине җиңүгә караганда да күбрәк илһамландырды. Тагын кабатлыйм, нинди шәхесләр булган! Ул миңа ничек яшәргә, ничек тырышырга кирәклеген тәфсилләп язган, беренчелек яуламауның әле берни дә аңлатмаганын искәрткән. Ә язарга телисең икән, димәк, бу– гомерлек эшең, дигән... Мин ул хатны бик озак сакладым. Ә МДУда журналистика факультетында укыганда, Ирина Викторовнаны табып, рәхмәтемне ирештердем. Кыскасы, болар барысы да очраклы туры килү генә түгел – сине гомер сукмагыннан алып баручы кешеләр ул. Язмышыңа булыша, аңа юл күрсәтә торган билгеле бер шәхесләр турында сүз бара.

9 нчы сыйныфта укыганда, кышкы каникулларда без Мәскәүгә экскурсиягә бардык. Һәм менә иртәнге сәгать биштә без ил башкаласына килдек. Кыш, караңгы. Туристлар өчен автобусларга утырдык, һәм әнә шул иртәнге караңгылыкта мин беренче тапкыр Мәскәү университетының шпильләрен күрдем. «Укырга икән, тик шушында гына!»– дигән уй йөгереп узды башымнан.

Шулай да безне, ерак төбәкләрдәге мәктәп укучыларын, ул чакта шактый кыю итеп тәрбияләделәр. Хәзер моны «лидерлык мәктәпләре» яки «уңышлылар сабагы» дип атыйлар. Минемчә, кайчагында купшы, яңгыравык исемнәр белән арттырып та җибәрәләр, чынлыкта лидерлар түгел, ә кайчак масайган – үз-үзенә артык ышанган кешеләр үстерәләр. Лидер – андый түгел, ә бик үҗәт, тырыш кеше. Борын төбендә ишекне өч тапкыр ябып куйсалар да, ул барыбер аны ачу ысулын эзли. Шуңа күрә мин укытучыларыма һәрвакыт рәхмәтле – без барысын да булдыра алабыз, дигән фикерне алар тиешенчә сеңдерә алды. Әйе, мин МДУ, Рига гражданлык авиациясе институты һәм МГИМО кебек зур-зур өч югары уку йорты турында һич тә курыкмыйча уйлана идем һәм шуларга укырга керергә җыендым да. Югыйсә Мәскәүне шул мәктәп каникулларына кадәр күргәнем дә юк иде бит!

ЖУРНАЛИСТИКА – СӘЯСИ ЭШЧӘНЛЕК ТӨРЕ

– Ә журналисттан ничек сәясәтчегә әйләнеп киттегез?

– Сәясәттәге хатын-кызлар мине һәрвакыт кызыксындырды. Корасон Акино*, Голда Меир, Индира Ганди, Беназир Бхутто** турында күп укый идем. Үз-үзләрен үстерә алган, уңышка ирешкән хатын-кызлар сыйфатында алар минем өчен геройлар иде. Аннары Төркиядәге Таңсу Чилләргә сокландым***. Бу хатын-кызлар миңа һәрчак кызык булды. Ир-атларның да йогынтысы юк түгел– Черчилльнең дә корреспондент булуын һәм шул юлның аны зур сәясәткә чыгарганын белдем. Кыскасы, күп кенә сәясәтчеләр журналистикадан чыккан дигән нәтиҗәгә килдем. Гомумән, журналистика үзе үк сәяси эшчәнлекнең бер төре ул. Син җәмәгатьчелек фикере, гражданлык җәмгыяте белән эшлисең. Һәркем укый һәм карый торган яхшы журналистның сәяси йогынтысы югары урындагы түрәнекенә караганда күбрәк тә хәтта. Шуңа күрә Анатолий Аграновский кебек журналистларның мәкаләләреннән соң, мәсәлән, кешеләр аңында революция була. Әйтик, аның аппаратны кыскарту турындагы танылган мәкаләләрен искә алырга мөмкин. Мин аны, кызганыч, укыган вакытта инде күрә алмадым, әмма аның абыйсы Валерий Абрамович миңа һәм иремә остаз булды. Алар чын мәгънәсендә олуг журналистлар иде, без аларга энеләр-сеңелләр кебек булдык, алар безнең белән дус булдылар, өйрәттеләр, киңәшләрен бирделәр.

ҺӨНӘРИ ДӘРТ БЕЛӘН ЯНГАНДА

Казанга килгәч, яңа урында һөнәри эшләрне нульдән башларга туры килде. Уфада үзем эшләгән яшьләр газетасында мине барысы да таный иде. Ә монда– беркем белми. Әмма ул барыбер дә кызыклы чор булды. Башта «Вечерняя Казань», аннары «Республика Татарстан» газетасында эшләдем, «Известия Татарстана» редакциясендә хезмәт куйдым. Көтмәгәндә-уйламаганда, мине шуннан депутат итеп сайладылар. Ул чакта хәтта сөенмәдем дә, журналистика диңгезенә, аның мөмкинлекләренә чумган чагым иде. Корреспондент сыйфатында СССР халык депутатларының I съездына бардым. Әлбәттә, ул бик зур мәктәп булды. Бу съездның составында танылган, искиткеч акыллы кешеләр иде бит. Ул чакта депутат Юрий Афанасьевның кыю һәм үлемсез гыйбарәсен – «агрессив-тыңлаучан күпчелек» дигән сүзләрне шактый еш телгә алдылар. Ул хәзер дә кулланыла. Төбәкара төркемдә иртәнгә кадәр эшли идек, шул арада нидер язып өлгерергә һәм иртән тапшырырга да кирәк әле. Интервью өчен мөмкинлекләр һәм геройлар– буа буарлык. Менә Дмитрий Сергеевич Лихачев, әнә коридордан Борис Николаевич Ельцин бара. Менә Николай Травкин килә, әнә Святослав Федоров. Академиянең бөтен профессорлары, Роальд Сәгъдиев... Минем Казаннан икәнне белгәч, барлык академиклар белән таныштырды: «Әгәр бу кыз яныгызга килә калса, аның барлык сорауларына җавап бирегез», – дип әйтеп куйды. Мин хәтта тәнәфестә дә һич кая китмәдем – шул арада яннан кем генә узмас дип уйладым. Кайчагында шунда Галина Старовойтованы көтеп алам. Иҗтимагый эчтәлекле бер басмада да күренми торган темаларга сөйләшергә була иде аның белән. Мине аның бер гыйбарәсе рухландырып җибәрә иде. Депутат хатын-кызлар «озак утырдык ич инде, балалар ач, кайтырга вакыт» дип шыңшый-зарлана башлагач, – утырышлар озын-озак бара иде бит – Галина Васильевна: «Девушки, давайте не будем так много говорить про женский пол, иначе подумают, что наш пол и есть наш потолок», – дип әйтә иде.

Бервакыт барысы да каядыр таралышты, әллә төшке ашка, әллә башкасына... Һәм шулчак туп-туры каршыма... Михаил Сергеевич Горбачёв килә, үзен нибары бер кеше озата йөри!.. Әлбәттә, аның янына йөгереп килдем. Әллә каян гына сакчылары да килеп чыкты, тик инде мине читкә этәреп булмый, чөнки сораулар бирә башладым... Үзебездәге трактор заводы турында сорадым. Миңа Евгений Андреевич Лисин: «Горбачевтан Алабуга трактор заводы язмышы турында сора», – дип гел әйтә килде. Трактор заводы турында ишетүгә, Горбачевның йөз-кыяфәте ничектер үзгәреп китте. Шуңа да карамастан, ул урында барыбер эре җитештерү предприятиесе булыр дип өметләндерде. Әңгәмә басылып чыкты, аннан соң бер атна бөтен журналист минем арттан йөгереп йөрде, янәсе, әйдәгез, аның янындарак торыйк, аңа гел уң килә, һичшиксез, кемне дә булса

*Корасон Акино– 1986–1992 елларда Филиппин Президенты. **Беназир Бхутто– 1988–1990 һәм 1993–1996 елларда Пакыстан Ислам Республикасы премьер-министры, төп халкы мөселман саналган илдә иң яңа тарих чорында хөкүмәт башлыгы булган беренче хатын-кыз. ***Таңсу Чилләр– төрек икътисадчысы һәм сәясәтчесе. 1993–1996 елларда Төркия премьер-министры вазыйфасын башкарган беренче һәм бердәнбер хатын-кыз.

элэктерми калмый, ди иделәр. Бу чын һөнәри дәрт белән янган вакытлар иде!

ГОРБАЧЁВ БЕЛӘН МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

1995 нче елда Михаил Горбачев Россия Президенты сайлавында катнашты. Язмышка шулай язган ки, кандидатны Казанда озатып йөрүне миңа ышанып тапшырдылар. Шулай кирәк булгандыр: мин Дәүләт Советы Рәисенең беренче урынбасары идем. Ирлехатынлы Горбачевлар белән көн буе йөрдем, аннары кунакханәгә озата бардым. Раиса Максимовна ял итәргә кереп китте, ә без Михаил Сергеевич белән әле бик озак сөйләшеп утырдык. Миңа калса, ул сайлауда җиңә алмаячагын чамалый, тик бу юлга аяк баскач, аны ахырына кадәр үтәргә карар кылган иде. Ул чакта төп кандидат булып гамәлдәге президент Ельцин барды. Шулай да Михаил Сергеевич белән очрашуга кая гына килсәк тә – КАИдамы, телевидениедәме, радиодамы – халык бик күп җыела, аны кайнар сәламлиләр иде. Ул бу уңайдан минем фикеремне дә сорый. Мин аңа дөресен әйттем: сезне тарихи шәхес буларак каршы алалар. Сез лидер һәм сәяси эшлекле буларак тарихка кердегез, шуңа күрә ни сөйләвегез, ни уйлавыгыз һәркемгә кызык.

«Дөресен әйткәнегез өчен рәхмәт», – диде ул.

Без аның белән иртәнгә кадәр диярлек сөйләшеп утырдык.

Әле бит Римзил кебек ирең дә булырга тиеш! Иртәнге сәгать дүрттә кайткач, ул ишек ачканда: «Кайда йөрдең шулкадәр озак?»– дип сорый. «Менә Михаил Сергеевич Горбачев белән чәй эчтек...» – дим. «Ярар, кер, бераз йоклап ал, – дип өйгә кертә ирем. – Иртән янә аның янына барасыдыр бит...»

Минтимер Шәрипович ул вакытта миңа киңәшен бирде: «Син Горбачев белән сөйләшкәннәреңне бераз булса да язып барсаң иде, Зилә, соңыннан онытылуы мөмкин».

Ил башлыгы булган кеше белән нәрсә турында сөйләшергә мөмкин, дисездер. Без... мәхәббәт турында сөйләштек. Михаил Сергеевич дөньядагы иң зур илнең беренче кешесе, һәрнәрсәгә кодрәтле зат булуы турында сөйләде, ләкин тормышындагы иң төп уңышы дип үз тиңен табу бәхетен атады. Ул Раиса Максимовнага табынып яшәде.

Сәфәрнең бер мизгелендә Раиса Максимовна, арыган-ярсыган хәлдә, миңа басым ясый, битәрли башлады, янәсе, дөрес урынга килмәдек, бу радиога барырга кирәкми иде. Горбачев моны сизеп алды, мине читкә алып китте дә үтенечен җиткерде: «Зинһар, син аның белән йомшаграк бул инде, Форостан соң нервлары бетте аның. Раиса Максимовнаны аңла инде, үзең күрәсең, ул бит шундый хәлдә...»

1999 елда Раиса Максимовна үлгән көн мин Америкада вакытка туры килде, анда зур халыкара хатын-кызлар конференциясендә чыгыш ясарга тиеш идем. Мин шаккаттым: трибунага чыгуыма, зал аягүрә басты. Америка хатын-кызларының барысының да күзләре яшьләнгән иде. Раиса Максимовна яшәгән ил вәкиле буларак, алар шулай минем белән кайгы уртаклашты. Америка аны яратты һәм бу югалтуны безнең кебек үк авыр кичерде. Бу бик дулкынландыргыч хәл булды.

БЕЗ ИКЕБЕЗ ДӘ БЕР КЕШЕНЕ – ЗИЛӘНЕ ЯРАТАБЫЗ

– Командировкалар, тәүлек буе эш, киеренкелек... Ә гаилә?

– Мин иремнән уңдым. Хәтерлим әле, инде хөкүмәттә эшләгән чагым. Үз башыма бер бәла уйлап чыгардым: хезмәттәшләр белән концертлар яздырабыз. Төрле вакыйгалар уңаеннан. Минтимер Шәриповичның туган көненә дә эшләдек... Яңа елга да яздырырга булдык һәм тегенди-мондый гына итеп түгел, ә телевидениедә. Бар да талант бит! Марат Готыфовичның ничек матур җырлаганын беләсезме, баянда да уйный әле! Фәрит Хәйруллович, җырлый-җырлый, цирк баскычыннан төшеп килә... Һәм менә шундый көн җитте: барысы да үз чыгышын яздырды, бер мин генә калганмын. Ә минем үтереп тамагым авырта. Командировкадан кайтып барам, Миләүшә Айтуганова шалтырата: «Әйдәгез, Зилә Рәхимҗановна, яздырырга килегез. Сез генә калдыгыз...» Үземә дә оят. Мин оештырып җибәрдем дә үзем менә кыен хәлгә куям дип уйлыйм. Кайсыдыр җырчы, тамак авыртканда, коньякка чи йомырканы болгатып эчәргә кирәк, дип әйткән иде. Һәм менә кичке сигездә өйгә кайттым да, бер шешә коньяк, йомыркалар алып, иремә «мин номерымны яздырырга киттем», дип, чыгып йөгердем. Ә ул минем «Казан егетләре» белән булырга тиешлегемне белә иде.

Җырны яздырабыз. Сәгать инде төнге унбер җитте.

Лия Заһидуллина өйгә шалтыраткан да: «Зилә кайда?»– дип сорый икән. Ирем тыныч кына җавап бирә: «Зилә өйдә юк. Ул бер шешә коньяк алды да «Казан егетләре» янына китте». Лия соңыннан бу хәлне һәм шул сүзләрне еш искә алды әле.

Ә егетләр миңа ул чакта «гоголь-моголь» дигән микстура ясап бирде, шуны ике кашык йотып җибәрдем– булышты, җырлый алдым. Ул язманы телевизордан берничә тапкыр күрсәттеләр.

Гаиләдә ышаныч зур әһәмияткә ия. Тик ышанычтан тыш, бу ышанычны аз гына какшатып җибәрерлек сәбәп тә булмаска тиеш дип саныйм.

Иремнән гаилә тормышы турында сораганда, ул: «Бездә барысы да әйбәт, гаиләдә каршылыклар юк, без икебез дә бер кешене – Зиләне яратабыз», – дип шаяртып җавап бирә иде.

Озын-озак гаилә тормышыбыз уңаеннан аның тагын шундый фикере бар – чынлыкта, бер-беребез турында башта уйлаганга караганда, без яхшырак та булып чыктык, дип саный ул.

ЗАМАНАЛАР ҮЗГӘРГӘН ЧАКНЫҢ ЖУРНАЛИСТИКАСЫ

– 90 нчы елларда журналистика нинди иде? Цензура булдымы? Нәрсә язарга ярый, нәрсә ярамый иде?

– Мин цензура белән очрашмадым диярлек. Ләкин әдәбият идарәсе вәкиле – главлитның һәрчак газетага мөһер сугуын хәтерлим. Бу әле «Вечёрка»да вакытта. Ул бик күңелле хатын-кыз иде, без аның белән төрле темаларга сөйләшкәләдек, безнең эшне аңлый иде, алай явызланмады. Тик язмалар да кемнедер пычракка батыру кебек нәрсә юк иде дип әйтергә була. Бәлки, ул вакытта һәрберебездә эчке цензор утыргандыр...

Күп нәрсә баш мөхәррир шәхесенә бәйле. Хәтерлим әле, нindидер күрсәтмә буенча язылган мәкаләләр бар иде. Берсен ул чактагы «Социалистическая индустрия» газетасыннан күчереп бастырдык. Шул язмага халыктан кайтаваз таләп итәләр. Ул вакытта хатлар бүлеге мөдире булып эшләдем. Алган хатның барысын да без өлкә комитетына илтеп бирергә тиеш идек. Ә теге язманы хуплап бер генә кайтаваз хат килде. Мин шуның белән баш мөхәррир янына кердем, ә ул – бюро әгъзасы, аңа бу хатлар буенча хисап тотарга кирәк.

– Ничек инде берәү генә?– дип сорый.

– Менә шулай, берәү генә. Мин нәрсә, үзем сырлап бириммени? Аларны аннары күрсәтергә кирәк булачак бит. Ә тикшерергә уйласалар?– дим.

Сүзем нигезле, тәэсирле булды:

– Берәү булгач, берәү инде.

Партия өлкә комитетында беренче секретарь каршында нинди хәлдә утырганын аңлыйм, ул бит үз көндәшенә карата халыктан нәфрәт көтә, ә мондый ачулы хат берәү генә, дип әйтергә туры киләчәк.

ЯҢА МӘГЪНӘ ИҖАТ ИТҮЧЕЛӘР

– 90 нчы еллар журналистикасы дүртенче хакимият була алдымы? 20 ел эчендә нәрсә үзгәрде?

– Булды. Чөнки бер мәкалә ярдәмендә кешене җир белән тигезләргә мөмкин иде. Бик җиңел генә.

1. Эре-эре итеп кисәлибез!

2. Вак-вак итеп турыйбыз!

3. Кишерне ваклап турыйбыз!

4. Бәрәңгене шакмаклап турыйбыз!

5. Чүлмәкне тутырабыз!

6. Каражимеш салабыз!

7. Мичкә озатабыз!

8. Табынга бирәбез!

Бүген, минемчә, журналистика исемсезгә, шәхессезгә әйләнде. Мин элек, газетаны ачканда, аерым бер фамилияләрне эзли идем. Миңа һичшиксез Инна Руденконы яки Аграновский, Третьяковны укырга кирәк иде. Хәзер андый атаклы исемнәр юк дәрәҗәсендә, башка буын үсеп җитте югыйсә. Һәм шунысы сәер, нәкъ менә мәгълүмат даирәсендә кыйммәтле контент азайды. Миңа гомуми сүзләр, дежур пресс-релизлар кирәкми. Аналитика һәм контент – бүгенге журналистиканың иң йомшак урыны. Югыйсә журналистлар – яңа мәгънәләр иҗат итүчеләр булырга тиеш кебек.

Тик кайвакыт бу мәгънәләрниндидер сәүдәгә әйләнеп кала. 90 нчы елларда бездә реклама бизнесы хәзерге кебек колач җәймәгән иде. Шуңа карамастан, совет елларында басмаларның тиражлары шулкадәр күп булды, шактый газета-журналлар партия кассасына зур-зур акчалар китерде. Дәүләт Советында эшем тәгәлләнгәннән соң, мин матбугат һәм мәгълүмат министры булдым. Шулай ук республика яңарышындагы кайнар урын бу! Ул чакта мәгълүмати продуктны һәм рухи ризыкны акча эшләүгә әйләндерү өстенлекле бурыч түгел иде әле. Акча эшләүдән бигрәк, мөхәррирләр белән күбрәк рубрикалар, мәкаләләрнең эчтәлеге, типография җиһазлары турында сөйләштек. Ачыктан-ачык ялганга корылган заказлы мәкаләләр һәм тапшырулар беркемгә дә кирәк түгел, бу мәсьәләдә фикерем катгый. Чөнки газета укучылар һәм тамашачылар ялганны һәрвакыт сизә. Ә гаделлеккә, дөреслеккә һәрвакыт ихтыяҗ булыр дип өметләнәм.

ГЛАМУР БЕЗНЕ БЕРНИГӘ ДӘ ӨЙРӘТМӘДЕ

– Татарстан журналистикасының киләчәге бармы?

– Һәрнәрсәнең киләчәге бар. Ул киләчәк нинди булачак, менә монысы инде башка мәсьәлә. Бу һәрвакыт билгеле бер кешеләргә бәйле, һәм ничек кенә тапталган гыйбарә булып яңгырамасын, кешенең гомере бер генә. Бүгенге вакыйгалар һәр адәм баласына үлем киләчәген түгел, ә бу үлемнең кинәт китереп суга алганын күрсәтә. Шуңа күрә кешегә гомер буе сайлау мөмкинлеге бирелә. Болай да эшли ала, тегеләй дә гамәл кылырга мөмкин. Бүген бу һөнәрне сайлаучылар мәгълүмат кырындагы хәлләр өчен җаваплылык тоярга тиеш. Әйе, бер кеше барысын да үзгәртә алмый, ләкин үз урынында гына булса да бу һөнәрнең дәрәҗәсен, хөрмәтен саклап калуны булдырырга көченнән килә. Талантлы кешеләр күп. Мөмкинлекләр дә күп. Җәмгыятьнең кайнар, авырткан урынын сизеп-тотып ала белү – менә нәрсә мөһим. Коронавирус белән бәйле вазгыять күрсәткәнчә, гламур басмалар һәм тапшырулар бүгенге проблемалар фонында тоныкланып, сүнеп калды.

Мин соңгы елларда журналистикадан ерак: ун елдан артык – вице-премьер булдым, мәдәният министры йөген тарттым. Әмма бу өлкәләрне берләштерә торган бер нәрсә калды. Мин иҗади шәхесләрнең талантына ышанам. Миңа калса, хәтта җитәкчелекнең дә башка төрле журналистикага күрергә теләге бар. Картинаны сылап-бизәп бирү беркемгә дә кирәкми, барысына да чынбарлыкны нинди бар, шундый итеп тасвирлау мөһим. Әгәр берәр сәер кеше җитәкләсә һәм үзе кирәкле дип санаган материалларны гына чыгарса, гадәти форматка сыймаган ниндидер яңа басмалар барлыкка килә. Бик күп матбугат чаралары кемнеңдер акчасына яши яки дәүләт заказында утыра…

Коронавирустан соң матбугат башка кыйммәтләргә игътибар юнәлтәчәк. Ниһаять, табиблар эшенә йөз белән борылып, рәхмәт әйтә башладылар. Югыйсә алар бит һәрвакыт үз эшләре белән шөгыльләнде. Ниһаять, мәгълүмати киңлектә алга киткән укытучыларның интернет ана укыту системасын җайга салуларын күрсәтә башладылар. Тик алар элек тә эшләп килде бит! Ә экраннарда картларның яшь бичәләргә өйләнүен, байлар, өреп кабартылган йолдызлар тормышын күрсәтү белән мәшгуль булдылар…

Үзизоляция – бик катлаулы һәм эчтәлекле чор. Кешеләр арасында мөнәсәбәтләр үзгәрә. Балалары белән өйдә утырганда, әти-әниләр: «Ә укытучылар ничек чыдый икән соң?» – дип уйлана башлый. Озак вакыт бергә булган гаиләләрдә ниндидер үзгәрешләрбарлыкка килә: кемдәдер проблемалар баш калкыта, кемнәрдер, киресенчә, тагын да якынаеп китә. Ягъни гаджетлар, телефоннар, айпадлар, чатлар, социаль челтәрләр һ.б. – болар барыбер инструмент булып кала. Менә диген заманча әсбаплар. Әмма хикмәт аларда гына түгел, төп хикмәт һәрвакыт шәхестә, кешенең талантында, белем дәрәҗәсендә. Иң мөһиме, без бу вакыйга-хәлләрдән бер беребезгә карата шәхси дәгъвалар белән чыкмаска тиешбез. Һәрнәрсәнең бәйләнештә икәнлеген аңларга кирәк: авырмас өчен, үзеңә дә сәламәтлегең турында кайгырту зарур. Без хәзер, әйтерсең, генераль җыештыру вакытында.

Күп нәрсәсез яшәп була икән ләбаса. Хәзер, кулланучылар җәмгыяте чорында, күпме кирәксез кыйммәтләрне тормышыбызга керттеләр, әһәмиятсез нәрсәләрне бик кирәк, дип ышандырырга маташтылар. Ә үлчәүгә кеше гомере куелгач, аңлыйсың: бусы артыннан куарга кирәкми икән, ә бу бөтенләй минем өчен түгел… Бөтен җирдә: өйдә дә, эштә тә, бар дөньяда асыл кыйммәтләргә, кешелеклелек мөнәсәбәтләренә әйләнеп кайтсак иде.

Халыкта «Ашаган белми, тураган белә» дигән гыйбарә бар. Ләкин демократик дәүләттә ашаучылар да, турауч ылар да бергә булырга тиеш, дип уйлыйм. Чөнки халык, авызын ачып, каптырганны гына көтеп утырмый, ул үзе дә ашарга әзерләүче. Бигрәк тә хәзергедәй шартларда ашны бергәләп пешерергә кирәктер. ▪

ТЕТРӘНҮЛӘР ҺӘМ ЮГАРЫ ОЧЫШЛАР ДӘВЕРЕ

Хәтәр 90 нчы еллар гражданлык авиациясе өчен дә кыю һәм шактый җилле була. Ирекнең исерткеч тәме һәм ачык чикләр үзенекен итә. Чит илләргә беренче даими пассажир рейслары, Гарәп Әмирлекләренә, Мисырга, Сүриягә, җирнең читенә диярлек – чартерлар! Республиканың «Татарстан авиалинияләре» дигән үз авикомпаниясе бар, ә аның – менә дигән очучылары белән өр-яңа булмаса да, сафта булган очкычлары. Татарстан Республикасы рәсми делегациясе дөнья буйлап «Боинг-737»дә оча, очкычның фезюляжын «Татарстан» дигән горур язу бизәп тора. Әйтүләре буенча, ул кайдадыр Кайман утрауларында теркәлгән. IDF шәхси Татарстан авикомпаниясе ватандашларына Көнбатыш сервисы үрнәкләрен күрсәтеп мактана алса, икенчесе, «Тулпар», Пакыстанда... пассажирларны ташый – табыш китерә торган, файдалы контракт буенча. Ә инде «Аэростан» Казан авиакомпаниясе исә гомумән ил буенча оча, ул илткән йөкләр арасында Африкадагы ач-ялангачларга гуманитар ярдәм генә түгел, Калашников патроннары да бар. Базар бит, нишлисең... Әйдәгез, искә төшерик шул чакларны...

Автор:
Әскәр Сабиров

БОСФОР ӨСТЕННӘН РЕПОРТЁРЛАР ОЧА...

1991 елның октябре, Казан аэропорты. Диктор «Казан – Истанбул» рейсының озакламый җиргә утырачагын хәбәр итә. Тавышында эмоциянең эзе дә юк – әйтерсең лә, бу рейс Актанышка йә Бөгелмәгә очудан бернәрсәсе белән дә аерылмый. Ләкин чынлыкта тарихи вакыйга: Татарстаннан Истанбулга беренче даими халыкара рейс. Пассажирлар да бик нык дулкынланган: Америка ачар өчен очалармыни...

Чынлап та – ачар өчен. «Татарстан хәбәрләре» баш мөхәррире Юрий Алаев белән аның урынбасары, мин фәкыйрегез, искиткеч рәсми делегация составына эләккән бәхетле делегатлар: Совет илендә җирле журналистларны чит илгә сәяхәткә алу – гайре табигый хәл. Очкыч шыплап тулган: ике арада мәдәни күпер салу өчен Татар дәүләт Җыр һәм бию ансамбле артистлары да оча...

Хезмәттәшләребезне көнләшүдән кара көйдерәчәгебезне күз алдына китереп (очкычта бездән кала бүтән бер генә журналист та юк!), очкыч җирдән аерылуга, репортажга тотынам. Хәер, язарга әллә ни җим дә юк әле, пассажирлар белән берничә блиц, әлеге тарихи мизгелнең әһәмияте – болар белән әллә ни юньле материал әмәлләү мөмкин эш түгел. Бүләк өчен әзерләнгән пакетларның эчендә ни булуы – монысын җәмәгатьчелеккә гомумән җиткерү тыелган. Җәмәгатьчелек уртача өч айлык эш хакы бәясе торган Диор галстуклары турында да белми калса да яхшырактыр...

Уңыш ике сәгать очканнан соң елмая. Салонга командир сугыла:

– Пилот кабинасына керергә телисеңме? Самолетны утырту мизгелләрен үз күзең белән күрергә?

Экипаж белән әле очкычка кергәнче үк танышуым өчен эчтән генә үземне мактап куярга өлгерәм. Һәм, иптәшләрнең көнчелектән ут янган карашларын күрмәмешкә салышып, «керү тыела» дигән ишеккә кереп чумам.

Әйтерсең, екияткә эләгәм.

– Әнә, күрәсеңме, безнең аста Кара диңгез җәелеп ята, – ди командир. – Ә алда – Босфор...

– Ә Босфор артында нәрсә?

– Мәрмәр диңгез. Ә аннан ары, кара, Дарданелл бугазы...

Мәктәптә география дәресләрендә тырыша-тырмаша ятлаганнарны без, ябык илдә яшәүчеләр, кайчан да булса күрергә хыялландыкмы икән? Юк, әлбәттә! Һәм менә бүген мин аларны пилот кабинасының тәрәзәсе аша күрәм! 10–15 минутлык очыш – кул сузымы ара кебек!

Эйфория шунда ук борчу белән алышына. Пилот, Истанбул аэропорты диспетчеры белән аралашканда (инглиз теле әллә ни әйбәт булмаганлыктан), биеклекне ялгышып күрсәтә: дүрт мең метр урынына – дүрт йөзне... Бәхеткә, бу ялгышны шунда ук төзәтәләр: кабинада, ике штаттагы пилоттан тыш, пилот-инструктор да бар: ни генә дисәң дә, беренче рейс бит – таныш түгел аэропорт.

Һәм менә безнең Ту-154 Ататөрк исемендәге аэропортның бетоны буйлап җилдерә инде. Казанда – минус 10 градус, биредә – җылы, рәхәт.

– Җәй! – дип елмая командир, ачык форточкадан пилот кабинасына сусыл үлән исе ургылып кергәч.

Аэропорттагы вип-залда кыска гына матбугат конференциясе узганнан соң, безне шушында ук капкалап алыр өчен махсуслашкан ресторанда зурдан купмый гына сыйлыйлар. Шуннан – кире Казанга, очкыч буш диярлек: төрек эшкуарлары һәм төзүчеләре десанты дәвере – алда әле...

Төрек иленә күпер салучылар кире кайтканда юл буе бер генә нәрсәгә үкенә: Истанбулга барып та Истанбулны күрми кайт инде! Хәер, укучылар бу хакта белмәячәк, әлбәттә. Икенче көнне газетада беренче халыкара рейсның ачылуына багышланган репортаж Истанбул гүзәллеген тасвирлаган сурәтләр белән бергә пәйда була. Ул вакыт өчен – башка сыймаслык оперативлык, тизлек! Коллегалар кара күмер булмый карасын менә!

Ә сурәтләрнең элегрәк, Инстанбулга Татарстан Президенты барганда, төшерелгән икәнен – анысын алар, әлбәттә, башларына да китерми.

«БАР ДА ТӘРТИПТӘ, МӘҖБҮРИ УТЫРАБЫЗ...»

1993 елның май иртәсе. Вакыт шактый туздырып өлгергән Ту-154 очкычы Казан аэропортыннан күтәрелә: курс – Каһирәгә. Пассажирлар – киеренке халәттә. Бу Татарстаннан ерак Африкага беренче рейс. Әмма борчыганы менә нәрсә: бер атна элек җирле авиакомпаниядән нәкъ шушындый «Туполев»ка мәҗбүри рәвештә төшәргә туры килә... Хәер, фронтовиклар нәрсә ди әле? Бер үк ядрә ике мәртәбә бер урынга төшми, диләр түгелме?

Салондагы пассажирлар ике төрле категориягә карый. Беренчесе – «тимер пәрдә» ачылганнан соң чит илләрне күрү мөмкинлегенә ия булучылар. Мондыйлар соңгы акчасына теләсә кайда һәм теләсә нәрсәдә очарга әзер. Икенчеләре – романтикадан мәхрүм «челноклар», алар өчен һәр рейс – акча эшләү мөмкинлеге.

– Гафу итегез, бу шул ук, шасси стойкасы ябылмыйча, утырырга мәҗбүр булган очкычмы? – дип сорый халык арасыннан берәү, стюардесса тыныч кына, суда калган очракта, сыбызгыны ничек сызгыртырга икәнен аңлаткан арада.

– Шул ук, – дип елмая стюардесса. – Әмма борчылырга сәбәп юк, аны инде төзәттеләр.

– Йәгез, очып барып җитәбез, дип ышанып, – әлеге дә баягы «челнок» шулай шаяртырга тырыша. Ул арада үзе күршедәге ханымга дьютифри алынган шешәсеннән «тынычландыргыч шифа» агыза.

Ханым баш тартмый, әмма күршесенең оптимизмын да уртаклашмый: аның креслосында, ни өчендер, элэктерергә саклык каешлары да юк. Чех телендәге язулар белән чуарланган очкыч, карап торышка, шактый таушалган: аны безнекеләргә, кирәге калмагач, бик арзанга гына Чехословакия Оборона министрлыгы саткан, диләр...

Ул арада вакыйгалар күз иярмәс тизлек белән алмашынып тора: очкыч әле тиешле югарылыкны да алып өлгерми, ә стюардессалар инде төшке аш таратырга керешә. Бик тә җитез кыланалар, очкычның ара-тирә янтаюына да исләре китми. Әмма бу игътибарны читкә юнәлтер өчен ясалган маневр халыкны тынычландыра алмый: барыбыз да бер үк күл өстеннән инде ничәнче мәртәбә әйләнеп йөрүебезне яхшы күрә.

– Туташ, ни диярсез? – «челнок» күтәренке кәефтә калуын дәвам итә.

– Шул ук хәл, – дип профессиональ елмаю белән елмая стюардесса, теләгән һәркемгә кофе өләшә-өләшә.

– Әйдә, әрәм булмасын! – «челнок» пластик стаканына кофе түгел, ә теге шифалы эчемлекне мул гына итеп тутыра.

Салонда бернинди паника юк, әмма, «челнок»тан күреп, башкалар да эчкә җылы кертергә сәләтле эчемлекләрне бер-бер артлы уртларга керешә – романтиклар да, прагматиклар да...

Ә ул арада очкыч утыру полосасына төште диярлек. Инде тәгәрмәчләр бетонга тия дигәндә генә, кинәт яңадан күккә ыргыла.

Арткы рәтләрдәге ирле-хатынлы «челноклар» ачыктан-ачык сөйләшүгә күчә:

– Бер-бер хәл була калса, бел, мин сиңа беркайчан да хыянәт итмәдем... – моны күршесе белән пластик стаканын чәкештергән, үзен беркетер өчен каешлардан мәхрүм булган ханым әйтә...

Очкычның тәгәрмәчләре җир белән «үбешеп» ала да аннан кабат аерыла.

– Мин дә сиңа – бер мәртәбә дә... – очкычның кыланышлары дәвам иткән арада бу күркәм пар тагын бер стаканны уртлап куярга өлгерә. Ул арада «Туполев» өченче кат әйләнергә ыргыла... Дүртенчеме, бишенчеме әйләнешеннән соң ул, ниһаять, җир белән «кавыша».

Казанда пассажирларны ашыгыч ярдәм машинасы каршы ала, шулай ук – аэропортның халыкара секторындагы кечкенә генә зал. Көтү залына чыгар өчен куркудан тәмам алҗыган һәм соңгы чиккә җиткән берәүгә дә рөхсәт юк: формаль рәвештә алар барысы да әле – Россия Федерациясенең теге як чигендә.

Бу – гадәттән тыш очрак, шуңа да аэропортта мөмкин кадәр тизрәк конструктив карарга килергә кирәк табалар: эчемлекләр белән тулы барны һәм медпунктны ачалар. Хатын-кызларның барысы да диярлек тизрәк табиб янына ыргыла – кан басымын үлчәтергә, тынычландыра торган уколлар алырга. Ирләр исә – кәефне җайларга. Араларындагы бердәнбер журналист кына, һөнәрен каргый-каргый, телефонга юнәлә – хәлнең ничегрәк икәнен редакциягә хәбәр итәргә...

Өч сәгатьтән соң Казан – Каһирә рейсы пассажирлары, башка очкычка төялеп, ерак пирамидалар иленә янә кузгала. Берәү дә очудан баш тартмый. Ләкин пилотларны шактый озак үгетләргә туры килә.

– Аңлыйсыңмы, стойкасы ябылмаган шасси – ул шасси чыкмау очрагыннан да хәтәррәк, – дип, җиңеләйтеп, популяр телдә аңлата миңа аннары, Каһирәгә төшеп утыргач, экипаж командиры. – Ә бит стойканың берекмәгән булуы да мөмкин, һәм ул, җиргә орыну белән, ябылса... Ул очракта – чәчкә ябышырга гына кала! Без полосага берничә мәртәбә елышып карадык, җирдән стойканың берегү-берекмәвен күрерләр, дип өметләндек... Юк, күрмәделәр...

Бер ядрәнең бер үк урынга ике мәртәбә төшмәвен кем уйлап тапкандыр?!

1990 нчы еллар

БЕР ЕЛГА СУЗЫЛГАН РЕЙС

Автор:
Ксения Сёмина

Талиблар тарафыннан яулап алынган Кандагарда Ил-76ны Әфганстан өстеннән оча торган Россия самолетларын озатып йөрүче яхшы таныш очучы-истребитель «утырта». 1995 елның 3 августында була ул хәл. Экипаж утыруның ни белән тәмамланасын күз алдына да китерми әле.

– Без Казанның «Аэростан» авиакомпаниясенең Тиран – Шардж – Кабул рейсында идек. Таныш маршрут – Кабулга өченче тапкыр очуыбыз. Рөхсәт ителгән йөк илтәбез – патроннар һәм амуницияләр, – дип хәтерендә яңарта ул вакыйгаларны самолетның икенче очучысы Газинур Хәйруллин. – Ул шәһәрне исламчылардан саклаучы хөкүмәт гаскәриләре өчен иде. Әфганстанда «Талибан» хәрәкәте террорлык эшчәнлеген башлап җибәргән чак.

«БУЙСЫНМЫЙСЫЗ ИКӘН – БӘРЕП ТӨШЕРӘБЕЗ»

Талиблар йөкне тикшерәбез, дип, самолетны утыртуны таләп итә. Сәбәп кенә икәне аңлашыла инде. Экипаж нәрсә эшләргә икән дип вакытны суза. Һавага күтәрелгән истребитель исә аңлашылырлык итеп катгый таләп куя: «Буйсынмасагыз – бәреп төшерәбез». Җиргә төшеп утырырга хәл итәләр. Ил-76 Кандагар аэропортына төшүгә, самолетка талиблар бәреп керә. Бер көн узгач, әсирләрне Кандагарга күчерәләр. Бирелдә, сарайга охшаган бер бинада, экипажның 7 кешесе, тышкы дөньядан тәмам аерылып, 378 көн уздырачак.

БИРӘҮ ДӘ БИРЕШМИ

– 2010 елда чыккан фильм (анда безнең беренче пилот Владимир Шарпатов баш консультант булды) әсирлектәге хәлебезне бик яхшы күрсәтә. Ләкин ул да безнең куркуыбызны, хәтта һәр көнне без кичкән билгесезлек упкынының тирәнлеген ачып бетерә алмый, – дип сөйли Газинур Хәйруллин. – Кайчагында өметсезлек буа башлый иде. Талиблар безне җибәрәчәкме, җәзалаячакмы – бернәрсә белмибез, аларның бездән нәрсә теләвен дә белмибез. Алар бик кызу канлы, импульсив кешеләр, эшгамәлләре без белмәгән һәм аңламаган башка кануннарга буйсына.

Әсирләр янына мулла килеп йөри, дини әдәбият алып килә. Экипажны әледән-әле ислам динен кабул итәргә өндиләр. Барысы да – юкка. Мулла талиблар ягыннан әсирләргә карата кешелеклелек күрсәткән бердәнбер кеше була. Шунда яшәүче бер ир белән хатын хыянәттә тотылгач, аларны таш атып җәзалаганда, мулла үзе экипаж кебек үк шок кичерә.

«БЕЗНЕ КАЛДЫРМЫЙЛАРМЫ?»

– Мин «төрмәбезнең» ишегалдында бер-ике тимер табып алдым, күпме булдыра алам, шуның кадәр тимердә атындым. Ул даими җанны кимереп торган курку хисеннән коткара иде. Һәрдаим туган йорт, әти-әни, үзебезнең Чүпрәле искә төшә. Үтереп кайтасы килә. Менә шул туган якка омтылыш миңа һәм иптәшләремә кеше булып калырга ярдәм иткәндер дә инде. Һәм тагын

бер ышаныч: күңелем түрендә безне бәладә калдырмаячаклар, азат итү турында сөйләшүләр бара, дигән иман яшәде.

Ә сөйләшүләр, чыннан да, бара. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев вәкиле Тимур Акулов талиблар белән бик катлаулы сөйләшүләр алып бара, алышуның мөмкин булган барлык вариантларын тәкъдим итеп карый. Инде сөйләшү уңай нәтиҗәләр бирде, 1996 ел башында, ниһаять, экипажны җибәрәләр, дигәндә, эшнең җае китә.

Гыйнварда Хәйруллин һәм аның иптәшләренең өмете җуела башлый.

– Атарлар инде, дип уйладык без. Өстәвенә, шундый бер «репетиция» дә булды – ташландык фабрикага алып килеп, төне буе бикләп тоттылар. Күрәсең, талиблар безне мөмкин кадәр файдаланып калырга тели иде, – дип сөйли икенче пилот. – Дөнья җәмәгатьчелегенең безгә булган игътибары аркасында, аларны таный башладылар һәм алар массакүләм мәгълүмат чараларында чыгыш ясау мөмкинлегенә ия булды. Алар, моннан файдаланып, үзләренең экстремистик идеяләрен үткәрергә тырышты.

ХӘЗЕР ЯКИ БЕРКАЙЧАН ДА

Самолетны тиешле хәлдә тоту өчен экипажны атнага бер тапкыр двигательләрне эшләтеп карарга дип, очкыч янына алып киләләр. Җирле халык үзе самолетны кабыза да, йөртә дә белми. Тора-бара, план димәсәң дә, качу уе барлыкка килә. Шулай бервакыт, җомга көнне, ислам кануннары буенча ял вакытында, экипажны самолет янына алып киләләр.

– Башта ярдәмче двигательне кабызып карадым, әмма коточкыч эссе һава шартларында – Цельсий буенча 50 градуста ул кабынмады. Тарханга, безнең каравылчыга, двигательнең суынганын көтәргә кирәк, дидек. Боевиклар безне сакларга өч сакчы калдырып, аэропорт бинасына чәй эчәргә кереп киттеләр. Һәм мин тәвәккәлләргә булдым, – дип искә ала ул көнне Газинур Хәйруллин. – Без радист Юрий һәм сакчыбыз Әсхәт белән кабинада идек. Мин бер-бер артлы двигательләрне кабыза башладым. Беренчесе, икенчесе. Инженер Серега минем нәрсә эшләргә җыенганны шунда ук аңлап алды һәм алар койрык өлештәге люкларны күтәрергә тотынды. Мин өченче двигательне кабыздым, ләкин беренчесе сүнде. Ләкин без артка юл икәнне аңлый идек: йә ниятебезне тормышка ашыруны дәвам итәргә, йә үләргә. Бәхеткә, теге двигатель кабынды.

«ҺӘМ КЕМНЕҢДЕР ЧЫНАЯГЫ ТӨШЕП КИТТЕ...»

Аннан соң без һавага күтәрелдек. Күтәрелгәндә, очып китү полосасына чыккан боевиклар машинасы белән чактан гына бәрелешмичә калдык. Талибларның «Урал»ына ун метр кала самолет җирдән аерылып, күккә күтәрелгәч, сакчылар нәрсә булганын аңлап алды. Аларны тиз арада коралсызландырдык, югыйсә самолет җиргә мәтәләчәк, дип аңлаттык.

– Мин, радарларга эләкмәс өчен, бик түбәннән очарга тәкъдим иттем. Шарджа белән элемтәгә чыктык. Диспетчерлар безгә ышанмады. Аннан соң кемнеңдер чынаягы төшеп киткәне ишетелде, һәм, ниһаять, нәрсә булганын аңлап алдылар. Без шатлыктан кычкыра идек инде, – дип искә ала Газинур Хәйруллин.

Шарджда экипажны Россия вәкилләре каршы ала. Алай да Россия очучыларын бер тәүлек җирле полициядә тоталар, сорау алалар. Шуннан соң гына Мәскәүгә кайтарып җибәрәләр.

ВАТАНПӘРВӘРЛЕК

Батырлык күрсәткәннәре өчен Владимир Шарпатов белән Газинур Хәйруллинга «Россия Герое» исемнәре бирелә. Экипажның калган әгъзалары «Батырлык өчен» орденнары белән бүләкләнә. Барысы да очучылык эшен дәвам итәрә. Дүртесе, шул исәптән Газинур Хәйруллин да, Ульяновскиның «Волга-Днепр» авиакомпаниясендә эшли. Безгә әлеге тарихны сөйләгән каһарман Ил-76да оча. Ул штурвал артына җиңел кайта. Кабулга да, Кандагарга да тагын берничә тапкыр очарга туры килә аңарга. Әмма әсирлекне гомерендәге иң куркыныч вакыйга итеп хәтерли.

– Безнең бу тарих – бәләкәй һәм олы батырлыкларның бер-бер артлы тезелгән чылбыры ул. Аларны гап-гади кешеләр эшләгән. Минем өчен ватанпәрвәрлек – үзеңнең кем икәнеңне, каян икәнеңне онытмау, тарихыңны белү, – ди Газинур Хәйруллин. – Батырлык та әнә шуңа ватаныңа һәм тарихыңа лаек булу теләгеннән туа. Синең кадәр яшәгән ватандашларың үткән юлга лаек булу теләгеннән.



1990 нчы еллар

ЯНГАН ЗАВОДНЫҢ КАРА ТӨТЕНЕ ӘЛЛӘ КАЙДАН КҮРЕНӘ ИДЕ

1993 елның 14 апрелендә килеп чыккан фаҗига – КАМАЗның двигательләр заводын юк итә. Еллык куәте 100 мең двигатель булган, 19 мең кеше хезмәт иткән предприятиедән иртәнге якка баганалар һәм тимер-томыр өеме генә кала...

Автор:
Михаил Рябинин



Двигательләр заводындагы янгын турында ул вакытта җирле газетада фотохәбәрче булып эшләгән Николай Туганов кичке сәгать тугызда гына ишетә. Фотоаппаратын эләктерә дә күршесенә йөгерә – аның «Москвич»ында заводка барып җитәләр. Күз алдында коточкыч күренеш ачыла.

– Заводның түбәсе һәм корпусы ут эчендә иде, ялкын телләре йөз метр чамасы өскә күтәрелә, – дип искә төшерә соңрак Николай Туганов. – Караңгыда төшердем, ул вакытка территорияне милиция хезмәткәрләре тыгыз боҗра белән уратып алган иде инде, ЧП булган урынга беркемне дә кертмәделәр...

Мәскәүдә «Авто» газетасының беренче битендә фаҗига булган урында төшерелгән фото чыга – бу илебез массакүләм мәгълүмат чараларында басылган бердәнбер фото булачак.

Туганов һәм аның коллегасы Вячеслав Бурнышев төшергән пленкаларны КГБ хезмәткәрләре алалар, журналистларны янгын чыгуы турында язарга катгый тыялар.

Николай Туганов үзенең тарихи кадрын төшергән арада двигательләр заводы янгын эчендә була, ялкын телләре бина түбәсе буйлап йөгерә...

ӨЙРӘНҮЛӘР БАРА, ДИП УЙЛЫЙЛАР...

Янгын 18:41 сәгатьтә трансформатор подстанциясенә алып баручы көч кабелендә кыска ялганыш килеп чыгу сәбәпле башлана. Ул вакытта ТР ЭЭМның сәнәгать объектларында хәрби сак башлыгы булып эшләгән Виктор Волков көндез заводта гражданлык оборонасы өйрәнүләре үтүен искә ала. Бәлки, шуңа да шартлау тавышына беркем дә игътибар итми, өйрәнүләр бара дип уйлыйлар... Ә ут, яңадан-яңа урыннарны биләп алып, кабель буенча гаять зур тизлектә тарала башлый. Вентиляция шахтасы аша түбәгә кучә – гудронга, җылыткычка мизгел эчендә ут каба...

Хәтәр барлыгын иң беренче булып слесарь-ремонтчы булып эшләгән эшче сизеп ала. Изоляция янган ис килгәч, подстанция ишеген ача... һәм чак кына төтенгә буылмый кала. Алга таба барысы да шулкадәр зур тизлектә бара.

19:04. Беренче янгын сүндерү бригадасы килеп җитә. Подстанция, кабельләр яна, ут капкан түбәдән эрегән битум һәм полистирол ага. Кискен җил утны көчәйтә генә. Каравыл башлыгы Н.Цветков Яр Чаллы өчен максималь сандагы янгын сүндерү көчләрен чакыра, тиз арада кешеләрне эвакуацияли башлыйлар.

19:25. Барлык янгын сүндерүчеләр һәм техника – урында. Утка каршы тугыз янгын сүндерү шлангыннан сиптерәләр, шуларның алтысы – түбәдә, өчесе завод эчендә эшли. Ләкин бу көчләрнең янгынның таралуын туктату өчен дә җитеп бетмәве ачыклана. Корыч өслек өстенә җәелгән пенополистирол җылыткыч каен тузы кебек янып китә, янгын сүндерүчеләр үзләре дә еш кына ут эчендә калалар.

19:52. Янгын мәйданы – 100 мең квадрат метрда, түбәнең дүрттән бер өлеше инде яна. Металл конструкцияләр ишелә. Түбән Кама, Әлмәт, Алабуга шәһәрләрендәге янгын сүндерү машиналары һәм гражданнар оборонасы көчләре ярдәмгә килә. Утны сүндерергә 30 машина җәлеп ителә. Ләкин янгын көчәя генә бара.

21:31. Ялкын двигательләр заводы түбәсен тулысынча ялмап ала...

Мәйданы – 1152 метрга 363 метр, аны шәһәрдәге берәр микрорайон территориясе белән чагыштырып булыр иде...

ПОЛИСТИРОЛ ДӨРЛӘП ЯНА

Әлфия Гарипова үзе эшләгән заводтагы янгынны фатир тәрәзәсеннән күреп

Фото: vestikamaza.ru

ала – завод ягыннан кап-кара, коточкыч куе төтен күтәрелә. Иртән эшкә килгәч, эш урынын таба алмый.

– Минем эш урыным юк иде, цехыбыз тулысынча янып беткән. Безне өйгә кайтарып җибәрделәр. Шундук эштән китү турында гариза яздым, янгыннан калган өемнәрне чистарту, көек исен иснәү – хатын-кыз эше түгел, дип санадым.

Полистиролның януы напалмны хәтерләтте, диярләр белгечләр, янгын сүндерелгәннән соң. Завод цехларын төзегәндә җылыткыч сыйфатында илдә беренчеләрдән булып куркыныч полистиролны кулланырга кирәклеге кайсы гына акыллыбашның эше булгандыр – бу турыда халыкка җиткерүче булмый. Ләкин шунысын искә төшерәчәкләр: әлеге фаҗигагә кадәр үк Яр Чаллыда шундый аяныч нәтиҗәләргә китергән «полистирольле» янгыннар бер-ике генә мәртәбә булмаган. Мондый янгыннардан соң дөрес нәтиҗәләр чыгарыла. Әмма акчаларны янга калдыру теләге һәрвакытта да акыллы карарлардан өстенрәк чыга. Сүз уңаеннан, Чаллыдагы завод америкалылар технологиясе буенча корыла, әмма алар, америкалылар, җылыткыч сыйфатында полистирол кулланылганын белгәннән соң, объектны иминиятләштерүдән баш тарталар...

Бинада барган янгынны, дөресрәге, шул вакытка аннан калган өемне янгын сүндерүчеләр 15 апрельдә, көндезге 11дә генә сүндереп бетерәләр. Ләкин бу да әле заводның җир өстендәге өлешендә генә. Ут подвалларда тынмый, ә аларның озынлыгы җиде километрга якын. Подваллар буенча ялкын двигательләрне сынау станциясенә күчәргә мөмкин, ә анда – майлар һәм дизель ягулыгы саклана торган савытлар... Нәтиҗәдә ут юлын вак таш һәм кирпечләр белән бүлеп, станцияне саклап калуга ирешәләр.

21 апрель көнне янгынны тулысынча сүндерәләр – шушы көнгә кадәр янгын сүндерүчеләр икешәр смена эшли, һәр смена бер тәүлек дигән сүз... Утка каршы көрәшүчеләр сафында – 560 янгын сүндерүче, гражданнар оборонасы полкы хәрбиләре, 64 берәмлек янгын сүндерү техникасы, 236 башка төр машина һәм механизм...

Янгын сүндерүчеләрнең фидакарьлеге, эшләрне дөрес оештыру нәтиҗәсендә җиһаз-җайланмаларның да бер өлешен саклап калалар. 420 мең квадрат метр мәйданны биләгән җитештерү корпусы тулысынча юкка чыга. Бәхеткә, үлем-җитемнәр булмый.

Фаҗиганең масштабын ТАСС фотохәбәрчесе Михаил Медведев вертолёттан төшерә – бары тик аңа гына органнар тарафыннан янгын чыккан заводны рөхсәт бирелә.

ТАГЫН ӨР-ЯҢАДАН

Яр Чаллыдагы янгынның нәтиҗәләре коточкыч була. КАМАЗ өчен генә түгел – бөтен ил һәм күрше илләр өчен дә. Кама ярындагы автогигантта төзелгән дизельләр Россиядәге, Украинадагы, Белоруссиядәге автомобиль предприятиеләренә бара – алардагы эш тә тукталу куркынычы алдында кала. Кайбер экспертларның бәяләмәләренә караганда, янгын салган зыян күләмен Чернобыль атом электростанциясендәге һәлакәт белән чагыштырып була.

Ихтимал, бу чагыштыру күпкә артыктыр. Ләкин, икенче яктан караганда, двигательләр заводында эшләп, мизгел эчендә эшсез, акчасыз калганнарга килгән мораль һәм матди зыянны әле беркемнең дә санаганы юк. Кайберәүләр, Әлфия Гарипова кебек, эшләрен алыштыра, икенчеләре, аның ире кебек, завод урынын чистартуда, аны яңадан торгызуда катнаша. Өстәвенә, кайбер әфәнделәр (аерым алганда, бөек реформатор Егор Гайдар) заводны торгызудан мәгънә юк, дип тәкрарлый. Болгавыр 90 нчы еллар...

Бәхеткә, акыллы карарлар кабул ителә. РФ һәм ТР хөкүмәтләре булышлыгы белән, камазлылар, акрынлап, элеккеге җитештерү куәтен торгызуга ирешәләр. Елына 100 мең двигатель җыя башлыйлар. Параллель рәвештә көч агрегатларын камилрәк җайланмалар нигезендә җитештерүне дә алып баралар. Бер ел да үтми, янгыннан соң беренче «КАМАЗ-7405» двигателе җыела.

Һәм 1996 елның 24 декабрендә тантаналы рәвештә двигательләр җыюның төп конвейерын эшләтеп җибәрәләр.

ЖУРНАЛИСТЛАР НИЧЕК **ИТЕП ҺӨНӘР АЛЫШТЫРДЫ**

90 еллар символы – күтәргесез шакмаклы авыр сумкалар тоткан кешеләр. Вак сәүдәгәрләр. Аларга исән чагында ук һәйкәл куярлык – шуларның берсе хәзерге вакытта Яр Чаллыда үзәк базарның сәүдә мәйданын бизи. Икътисад белгечләре бу феноменны ничек бәяләргә дип, әлегә кадәр бәхәс куерта – базар икътисадына күчкәндә, котылгысыз үтәргә тиешле этапмы, әллә сәүдә эшенә очраклы рәвештә кереп киткән гыйлемле кешеләрнең һәлакәтеме? Укытучылар, табиблар, инженерлар, галимнәр акчаларын, фатирларын, хәтта гомерләрен кыл өстенә куеп, барлык оешмаларда һәм предприятиеләрдә хезмәт хакы түләнми башлагач, һөнәр алыштырган чак иде ул. Алсу Динова 90 нчы елларда, вак сәүдәгәрләр сафына басып, журфакның икенче курс практикасының иң яратмаган «Журналист һөнәр алыштыра» дигән темасын «бишле»гә тапшыра.

500 ДОЛЛАР ҺӘМ «ЧҮЛДӘ КОМ БУРАНЫ»

90 нчы еллар уртасында ничек тә яшәргә кирәк иде. Мин дә теләсә кайсы эшкә – базарда сатарга да, идән юарга да, газета таратырга да әзер идем. Акча бернәрсәгә дә җитми. Мин бәләкәй бала белән декрет ялында утырам, шул вакытта үземнең «сәүдәгәрлек бәхетем»не сынап карарга булдым да инде. Шул рәвешле гаиләнең ераккарак җыеп куелган 500 долларына кердем. Акчаның бер өлешенә дуслар Чистай сәгать заводы чыгарган «Чүлдә ком бураны» сәгатен алырга ярдәм итте – шул ук «Командир» сәгате, тик чикләнгән сериядә чыгарылган. Имештер, ватылмый торган. Ул вакытта чит илдә бәһасе әйбәт иде аларның. Белгән кешеләр аны Польшада сатып, 45–50 (!) доллар табыш алып була, диделәр. Бер яшьлек кызымны әнигә калдырдым да... Варшавага чыгып киттем.

БАЛАЛАР ТЕМАСЫ

Бөтен җирдә дефицит, кая анда памперслар, даруханәдән марля да алып булмый! Кыскасы, идеяләр тулып ашкан, теләсә кайсы товар белән шаккатырып була. Сәүдәгәрлек «темасын» үземнең яшь әни булуымнан чыгып сайладым. «Коляска, караватһәм башка балалар өчен товарлар алып кайтып сатачакмын», – дип хәл иттем.

ЯНГЫН РЭКЕТТАН ДА ЯМАН

Казаннан – Варшавага, Варшавадан Казанга юл бер атна вакытны ала. Автобусларда 2–5әр кеше йөрибез. Автобусның алгы утыргычларына үзебез утырабыз, арткы утыргычларны алып куйдык, чөнки кайтканда, салон түшәменә кадәр диярлек товар белән шыплап тутырыла – җиһаздыр, савыт-саба, коляска, кием-салым, аяк киеме, хуҗалык товарлары...Товар белән түшәм арасында якынча 70 см тирәсе урын калдырабыз – шуышып кереп йоклап алырга. Янгын чыгып, кыймылдамыйчарак торсаң – терелә́й яначаксың. Андый хәлләр дә булгалады. Автобуслар ярты сәгать эчендә янып бетә иде. Иң курыкканым шул иде. Рэкеттан да ныграк курка идем. Базарда «крыша» булып йөрүчеләрнең кыланмышын алдан белеп булмый. Базарда торганда, спорт костюмы кигән яшь кенә кешеләр килеп баса да, алар белән шунда ук ай саен түләнә торган сумма турында килешергә кирәк. Ә менә юл рэкетирлары акчаны гына алып калмый, тәгәрмәчкә атарга, үтереп яки автобуска ут төртеп китәргә мөмкин иде...

ПОЛЬША СУКМАКЛАРЫ БУЙЛАП...

Автобуслар иске, йөртүчеләре – поляклар. Үзләре генә белгән сукмаклар буйлап йөртәләр. Белоруссия буйлап бигрәк тә. Анда юл автоинспекциясенең һәркайсы сәүдәгәрләрдән кимендә 50 доллар алып калырга тырыша. Кайсыныңдыр җиңел

кулы белән аларны «дай» дип йөртәләр иде. Автобусларның кыр уртасында ватылып калган чаклары да булды. Кесә телефоннары юк иде әле ул вакытта. Йөртүчеләрнең рацияләре була торган иде. Ике автобус белән барсаң, әйбәт әле – дүрт йөртүче русларның «аналарын» искә төшереп, полякларның «курва»лары белән төзәтә дә янә кузгалабыз.

ЯШЕРЕН КЕСӘ

Чик буена килүгә таможняда эре акчаларны декларациягә бирергә кирәк иде. Әлбәттә, берәү дә алай итми инде, акчаларны ничек булдыра алсак, шулай яшерәбез: эчке киемгә, күкрәкчәгә, оекларга, колготкаларга... Һәр сәүдәгәрнең үзенең яшерен кесәсе була. Варшаваның йөреп чыккысыз зур базарында да керәге чыга иде аның: анда кесә каракларының тулы бер интернационалы кәсеп итә иде. Анда бик уяу булырга кирәк, югыйсә акчасыз да, товарсыз да калуың ихтимал. Өйгә авызыңны салып, яшьләреңә чыланып кайтырга гына кала аннары. Күбрәк товар алыр өчен кешеләр бурычка ала, машиналарын, хәтта фатирларын сата иде. Кайберәүләр, ни кызганыч, янды да. Мин мантра кебек бер сүзне кабатлый идем: «Сумкаңны кулыңнан ычкындырма, үз яныңда гына тот». Ә төп акчаны йөрәккә якын урында саклый идем, алай ышанычлырак...

Кайтыр юл да җиңел түгел. Юл рэкетирлары товарга да кызыга. Таможнячылар кебек үк. Кагыйдә буларак, алар автобустан берничә йөз доллар ала, һәм чик аша юл ачыла иде.

ХАТЫН-КЫЗ БӘХЕТЕ

Бервакыт чик буендагы постта бер кызык хәл килеп чыкты. Гадәттә, товарга хатын-кызлар гына йөрибез, ә берсендә ярдәм булыр дип, бер ирне дә иярттек. Алай булса икән! Ул Варшавадан Белоруссиягә барган юлда шундый итеп «кәефләнгән» иде, чик аша чыкканда, без аның паспортын үзебез күрсәттек, хәтта уята да алмадык, чәченнән тотып, башын гына күтәреп карадылар. Ярый әле чик сакчылары хәерхаһлы булды, автобусны үткәреп җибәрделәр.

Ә болай хатын-кызлар белән җиңелрәк. Алар, чыннан да, чыдамрак, эчмиләр, тавыш чыгармыйлар. Безнең үзебезнең язылмаган кануннар бар иде, кизү торулар, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Чөнки вак сәүдәгәр эше куркыныч кына түгел, ул физик яктан да авыр. Үзең белән зур суммада акча йөртүе генә ни тора! Шуңа да иптәшләрең ышанычлы, чиста куллы булырга тиеш. Һәм пөхтә. Чөнки түшәменә кадәр йөк төялгән автобуста теләсә кайсы чит ис авыр кабул ителә...

ҺӨНӘРИ ТЕЛӘКТӘШЛЕК

Күп тапкырлар Польшага үзем генә барганым булды. Поездда Брестка кадәр, аннан төнге икедә Варшавага кадәр автобуста. Иртәнге биштә инде базарга тәпилисең. Берничә сәгать эчендә товар аласың да яңадан автобуста шул ук маршрут белән өйгә кайтырга юлга чыгасың. Һәрбер бару – риск. Таларга мөмкиннәр, таможнядан үткәрмәскә.

Польшага чик аша чыкканда, белорусларга булышабыз. Һәрбер туристка үзе белән бер блок тәмәке һәм бер литр аракы алырга рөхсәт ителә. Чик аша алып чыгабыз, ә инде теге «ярда» белоруслар үзләренең контрабандасын җыеп ала да полякларга сата. Безнең сәүдәгәрләр арасында тугандаш Белоруссиядән хезмәттәшләрне «алдаган» бер генә очракны да ишеткән булмады. Һөнәри теләктәшлек.

Менә шушы рәвешле узды минем чит илләргә сәүдә сәфәрләрем. 90 нчы елларда күпләрнең юлы Польшага гына түгел, Гарәп Әмирлекләренә дә, Төркиягә дә, Кытайга да төште. Ни өчен безне «челнок» дип атадылар соң? Көймә кебек бәтерелгәнгә, айкалганга-чайкалгангадыр инде. Ул вакытта өйдә кул кушырып, акча юк дип елап утырганчы, әнә шулай бәтерелергә мәҗбүр булдык без. «Хочешь жить – умей вертеться!» дигән рус мәкале, 90 нчы елларга бигрәк тә туры килә.

P.S. Сүз уңаеннан, үземнең бердәнбер «Чүлдәге ком буранын» мин Варшавада үзем яшәгән бәләкәй кунакханә хуҗаларына 60 долларга сатып җибәрдем...

10 000 СУМГА НӘРСӘ АЛЫРГА БУЛА?

...1995 елның апрелендә:

- 800 грамм 1 нче сортлы колбаса
- яисә 500 грамм атланмай
- яисә 1,5 литр үсемлек мае
- яисә 22 арыш ипие
- яисә 7 теш щеткасы
- яисә 2 чынаяк (тәлинкәсе белән)
- яисә 100 граммлы 11 данә исле сабын

РФндә уртача хезмәт хакы
(1995 елның апреленә)
383 000 сум

...хәзерге вакытта:



- яшүсмерләр өчен электр самокаты
- яисә индукцияле плитә
- яисә ике смартфон (Кытай)
- яисә бер камералы суыткыч, кечкенә
- яисә 150 грамм мәрсин балыгы уылдыгы
- яисә 32 килограмм атланмай
- яисә 300 арыш ипие

РФндә уртача хезмәт хакы
(2019 елның июленә)
46 509 сум

МЕТРОГА ХАКЫБЫЗ БАР

«ТАТАРСТАН» АРХИВЫННАН

Татарстан башкаласына метро кирәклеге хакында Казан узган гасырның 70 еллары ахырында миллионынчы кешесе тууга хәбәр сала башлый. СССРдагы нормативлар буенча «җир аслы» булырга миллионлы шәһәрләрнең генә хокукы була. Ә Казанның архитектор-төзүчеләре аның мөһимлеген 1976 елда ук дәлилләп күрсәтә. Әмма Казан метросының тарихы 1983 елдан, «Гипрокоммундортранс» институты ТАССР башкаласының комплекслы транспорт схемасын төзегәч кенә башлана.

Автор:
Татьяна Колчина

«Заречье» метро станциясе төзелеше.

Солтан Исхаков фотосы

Шул ук елны шәһәрдә геологик тикшерүләр узган урыннарда беренче тапкыр зур итеп язылган «М» хәрефләре пәйда була. Проектның һәм төзелешнең техник-икътисадый нигезләмәсе 1987 елда СССРның Юл министрлыгы тарафыннан эшләнә. Икенче елны ук комплекслы геологик тикшерүләр һәм беренче линия трассасының проектын төзү башлана. Ә шәһәр башкарма комитетының Баш архитектура-планлаштыру идарәсе һәм «Вечерняя Казань» газетасы казанлылар арасында «җир астының» беренче линиясендәге тукталыш атамаларына конкурс игълан итә.

Әмма тагын бер елдан барлык шәһәрләрдә дә метрополитенны проектлаштыру һәм төзелешләрне финанслауның бетерелүе турында СССР Министрлар Советының ябык карары чыга. Метро өчен Казан үзе азмы-күпме акча тапканга, проектлау эшләре акрынайса да, бөтенләй үк тукталмый.

Казанда «җир асты»н төзү идеясе икенче тапкыр 1995 елда тагын аздан гына юкка чыкмый кала. Россия Хөкүмәте якын киләчәктә метролы булырга мөмкин тугыз шәһәрнең исемлеген төзи, ә Казан бу исемлеккә кертелми. Республика һәм башкала җитәкчелеге Мәскәүгә Казанның да метрополитенга хакы барлыгын исбатларга китә. Нәтиҗәдә, Казан бәхетле шәһәрләр исемлеген тулыландырып, унлыкка эләгә. Менә шунда инде проектлаштыру эшләре тулы куәткә башлана, һәм эш башлаган участокның техник проекты 1996 елның декабрендә раслана.

1996 елның июнендә сайлау алды визиты белән Казанга Борис Ельцин килә, һәм нәкъ менә шушы визит нәтиҗәсендә, татарстанлыларга метро төзелеше өчен Казан акча алачак, дип вәгъдә ителә. Ельцин ТР җитәкчеләренең Казан метросында тәүге пассажир булу тәкъдимен рәхәтләнеп кабул итә.

Шул ук елның декабрендә Татарстан Хөкүмәте Казан шәһәрендә метрополитен төзү программасын раслый. Аның буенча «Җиңү проспекты»ннан алып «Завод»ка кадәр сузылган беренче линия 2008 елда ук кулланышка тапшырылырга тиеш иде. Әлеге линиягә «Карбышев» – «Яшьләр үзәге» участогы да керә. Икенче («Азино» – «Тимер юл вокзалы») һәм өченче («Восстание» – «Борисково») линияләренең кайчан төзеләсе программада күрсәтелмәгән.

Казан метрополитенының гомуми озынлыгы программа буенча 48 километр 300 метрны тәшкил итәргә тиеш. Ә төзелешнең смета буенча бәясе (1991 елгы бәяләр) ике миллиардтан артыграк дип билгеләнгән.

1990 нчы еллар

90 нчы еллар афишасы

НУРИЕВ ҺӘМ АНЫҢ СОҢГЫ СӘЛАМЕ

Көнбатышта аны данга күмәләр, ул иң данлыклы сәхнәләрдә генә чыгыш ясый, ә туган ягында, СССРда исә белергә дә, күрергә дә теләмиләр. Шулай да чын талант иясе булган балет артисты һәм балетмейстер 31 ел узгач Россиягә кайта. Ленинградка, ягъни Санкт-Петербургка түгел, ә нәкъ менә Казанга. Биюче буларак та түгел, ә дирижер булып. Ул вакытта Нуриев самолет басмасыннан да көч-хәл белән төшә, бииләр турында сүз дә була алмый. Аның гомере дә нибары берничә генә ай калган була. Шулай да М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры чакыруы буенча ул Казанда халыкара классик балет фестивалендә «Щелкунчик» спектакленә оркестр белән һәм концертта Татарстан Республикасының дәүләт симфоник оркестры белән Чайковскийның «Ромео һәм Джульетта»сының увертюра-фантазиясенә дирижерлык итә. Театрның балет труппасы сәнгать җитәкчесе Владимир Яковлев болай дип исенә төшерә: «Щелкунчик»тан соң, Нуриев, залны күрер өчен, беренче кулиса янына басты. Мин: «Рудольф, чыгар вакыт җитте», – дидем. Ул ышанмады, кабатлап сорады: «Мине чакыралармы? Бу алкышлар миңамы?» Мин аны, кулыннан җитәкләп, сәхнәгә алып чыктым. «Берегись автомобиля» дигән фильмның ахырын хәтерлисезме: анда Смоктуновский троллейбусны туктата? Аның йөзендә нәүмизлек һәм бәхет чагыла шул мәлдә. Рудольф та әнә шундый тыныч шатлык хисләре кичерә иде. Аннан соң, һәр актер янына килеп, кулын кысты, күзләренә карады. Ул шулай саубуллашты һәм үзен әнә шундый итеп хәтерләп калдыруларын теләде, дип уйлыйм».

Спектакльдән соң, Нуриев балет труппасының да, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры оркестрының да башкару осталыгын югары бәяли һәм Казандагы балет фестивалена үз исемен бирергә рөхсәт итә.

Фото: Рамил Гали

1992 ел.

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры

1992 ел.

Казан ТЮЗы

ЯШЬ ТАМАШАЧЫЛАР ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ ЧУАЛЫШ

1992 нче ел. Кара гәүдәләр һәм куркыныч йөзләрдән чорналган олы йомгак, үлем китерүче маятник-айбалта кебек каһарман өстендә селкенеп тора. Казанның Яшь тамашачылар театры сәхнәсендә даһи режиссер Борис Цейтлинның дәһшәтле спектакле. Ул Марк Шагалның «Оча торган кешеләр»ен хәтерләтә... Шушы ук елны Борис Васильевның «И был вечер, и было утро» романы буенча куелган «Чуалыш» спектакленә Дәүләт премиясе бирәләр. Казан театры өчен бу – вакыйга! Сүз уңаеннан, режиссерлар легендар авторның әлеге романына «А зори здесь тихие» яки «Завтра была война» әсәрләренә караганда игътибар биреп җиткерми. Бәлки, аның сюжеты гади генә булмагангадыр? Узган гасыр башының һәркем бер үк вакытта палач та, корбан да яки күзәтүче дә булган коточкыч тарихын Цейтлин метафоралар һәм образлар ярдәмендә ачып бирә. Ул тамашачыны Вахтангов һәм Станиславский спектакльләренең мизансценаларын, авангард рәссамнарның сәнгатен, кабаре, балетны, кинематографның аклы-каралы кадрларын, Шостакович һәм Прокофьевның иҗатын искә төшерә... Шулай итеп, уйлап чыгарылган Прославль дигән провинция шәһәре ул вакыттагы провинциаль Казанда җанланып, бөтен илнең хәтеренә сеңеп кала.

Әмма дә ләкин шушындый драматик спектакльдә дә комедиягә урын калдырылмаса, ул Яшь тамашачылар театры булмас та иде! Татар Байрулланы уйнаган танылган артист Александр Купцов «Чуалыш»та бутафор атның... колынлавы турында еш искә ала торган була! Хикмәт шунда, Борис Цейтлин спектакльгә хайваннар кертергә ярата. Берсендә сәхнәдә кәҗә «кучтәнәчләр»ен калдырып чыгып китә. Шушыны истә тотыпмы, әллә «актер» артык зур гәүдәле булгангамы, Борис Ильич рольгә тере юртак урынына карачкы куя. Ул чын ат зурлыгында була, корсагында – ярык. Менә шул корсакка театрда күпләп йөргән мәчеләрнең берсе кереп кала да инде. Труппада баш саны арту турында актерлар һәм режиссер сәхнәгә чыккач, бутафор ат эченнән... мәче балалары коела башлагач белә.

1991 ел.

Казан университеты

БГның КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ

1991 нче елның язы. Казан университеты залында «БГ-Бэнд» – Борис Гребенщиковның «Аквариум»нан соңгы яңа төркеменең беренче концерты. Дебют дияргә дә була! Икеләтә дә әле: коллектив казанлыларга «Государыня» белән «Никита Рязанский» җырларын да алып килгән – рок-мэтрның иң яхшы альбомнарының берсе шушы җырлардан башлана. Алга таба «Русский альбом» репертуары «еш кына концерт алдыннан» иҗат ителә.

Әйтүләренчә, бу килүендә БГ үзенең яңа төркеме белән Зөя утравына барып чыга. Кызмача була, җирле халык белән аралашырга омтыла, хәтта ул вакытта акылы зәгыйфь кешеләр тотылган Свияжск Успения ирләр монастыре территориясенә дә керергә тырышып карый. Килеп чыкмый. Свияжск бэндны салкын каршылый. Казан турында исә алай әйтеп булмый! Музыкантлар туктаган «Татарстан» кунакханәсе янында Яр Чаллыдан килгән җанатар кызлар хәтта палаткалар корып, алар янәшәсендә яшәп ала, дигән сүзләр дә йөри. Университеттагы концерт «тыныч, йомшак» үтә. Шаярталардырмы, юктырмы, әмма БГ моның сәбәбен болай дип аңлаткан, имеш: «Төрле яклап яшь-яшь кызлар уратып алган сәхнәдә утырганда, мин үземне ничек тотарга белмәдем. Без бит инде башка дәрәҗәдә эшлибез, һәм миңа беренче рәттә хатын-кыз кирәк иде, мин аңа гына карап җырлар идем. Ләкин ул юк иде». Концерт башланып, бер сәгать үтүгә аңа бер язу килеп төшә, ул аптырап, хәтта куркып кала: «Цойга сәлам әйт».

«Нишләп әле безгә концерт белән Казанга барып кайтмаска?» Шушы гади җөмлә ел ярымга сузылган гастрольләргә әйләнде һәм музыканы тамырдан үзгәртте, дип искә алачак соңыннан Борис Гребенщиков. Алар кырыктан артык шәһәрдә булачаклар, илнең бөтенләй уйламаган почмакларына барып чыгачаклар. Ләкин ни өчен маршрутның беренче ноктасы ТАССРның башкаласы була соң? Очраклы түгел, билгеле. Биредә флейтачы һәм клавишникта уйнаучы Олег Сакмаров – БГның дусты туган. Ул яңа төркемнең администраторы вазыйфасын да башкара, ә Казанда «пилмәнгә килгәч, БГны апасы Алланың ире – Леша Кайбияйнен белән белән таныштыра. Тегесе «БГ-Бэнд»ның директоры булып китә, һәм ике ел эчендә мең дигән гастрольләр оештыра, төркемнең гаҗәеп рухын саклауга зур өлеш кертә».

ЕКАТЕРИНА II КОМПАНИЯСЕНДӘ – СЕКС-СИМВОЛЛАР

Чынбарлык үзгәргән вакыт иде ул. Ул вакытта кино кайгысы да юк әле. Казанлылар хәтерләвенчә, сеансларда бер-ике кеше утыра. Ләкин Лейтенант Шмидт урамындагы Маяковский исемендәге клубка режиссер Виталий Мельниковның «Царская охота» фильмына Казан дәүләт университетының якын-тирә тулай торакларыннан студентлар унышарлап йөри. Өстәвенә, фильм тарихи сюжет вәгъдә итә, ул елларның тыйнак шартларында кино үзебезнең илдә генә түгел, ә Чехословакия белән Италиядә дә төшерелгән. Виталий Мельников җыйган актерлар составы да шәп: Анна Самохина – кенәз кызы Тараканова, Николай Ерёменко – граф Алексей Орлов, Светлана Крючкова – патшабикә Екатерина II.

Әйтергә кирәк, режиссёр Виталий Мельников ул вакытта киносөючеләргә «Әни кияүгә чыкты», «Ефрейтор Збруевның җиде кәләше», «Исәнме һәм сау бул», «Өлкән ул», «Капитанга кияүгә чыгарга» кебек кинолар аша таныш. Берәү дә аны тарихи кинолар төшерер дип көтми.

– Миннән «хатыннар режиссеры» дип көләләр иде... Әмма җәмгыятьтә үзгәрешләр барганлыгы аермачык иде, тарихка мөрәҗәгать итәр вакыт җитте, ә анда барысы да кабатлана бит... Нәкъ менә тарихи түнтәрелешләр вакытында үткәннәрне искә төшерергә кирәк кебек тоелды миңа, – ди Мельников үзе.

Фильмны караган кеше аның кенәз кызы Елизавета Тараканова турында дип кабул итә, ул яраткан кешесе граф Алексей Орловның хыянәте аркасында соңгы көннәренә кадәр Петропавловск крепосте тоткыны була. Орлов Екатерина кушуы буенча шулай эшли, тегесе исә көндәшен сөяркәсенең үз кулы белән юкка чыгара. Шулай итеп, сюжет үзәгендә – исткиткеч гүзәл тарихи урыннарда мәхәббәт һәм хыянәт. Киноның буеннан-буена үзеңне Екатерина II янында кебек хис итәсең, һәм сине менә-менә тотып алырлар да җәзалау өчен җир астына озатырлар кебек.

Фильм экраннарга чыгу белән газеталарга өлкән буын тамашачылардан нәфрәтле хатлар күпләп килгән, диләр. Николай Еременко белән Анна Самохина төшкән кадрлар артыгы белән кыю тоелган чөнки. Булган хәлдерме, юктырмы, әмма ләкин актерларга 90 нчы елларның төп секс-символлары дигән мөһер тагылып кала. Ә Светлана Крючкованы әлегә кадәр экрандагы иң яхшы «Екатерина» дип йөртәләр.

1991 ел.

Маяковский исемендәге клуб

PRESSA

1990 НЧЫ ЕЛЛАРГА СӘЯХӘТ

Узганнарга әйләнеп карасак, 90 нчы еллар буынына хәтәр вакыйгаларга шаһит булырга туры килүе искә төшә. Сәяси стройның алышынуы, митинглар, демонстрацияләр, бандитизм, инфляция... Язмышларына давыллы 90 нчы еллар язылган кешеләр үзләрен төрлечә тоталар, төрле гамәлләр кылалар: кемдер, ирек даулап, мәйданнарга чыга, кемдер, вуз дипломын тирәнгәрәк яшереп, зур букчасын асып, ерак илләргә товарга чыгып китә, кемдер һәлакәт салган зыянны юкка чыгаруда катнаша... Заманаы сайлап алмыйлар – анда яшиләр, исән калу өчен тырышалар-тырмашалар. 90 нчы еллар буыны да исән-имин калды. Ничек? Безнең бүгенге ретрофоторепортажыбыз – шул турыда...

30 август – Республика көне. Казан.

Татарстанлылар итек белән тәэмин ителгән.



Татарстанда референдум. Тавыш бирү участокларының берсе. 1992 елның марты.

Авыл. Ипи китерделәр...

Фото: Рамил Гали; ТР Президенты матбугат хезмәте архивыннан.

Казан. Бауман урамы 90 нчы елларда.

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

*«Татарстан» — җөмһүриятебез
тормышы турында
иң тулы хәбәрләр
Тигез хокуклылык, дуслык,
милли яңарыш,
көнкүреш, ял сәгатьләрендә,
китаплар дөньясында
Туган ягыбызның үткәне, бүгенгесе,
киләчәге, икътисады, мәдәнияте,
табигате, кешеләре турында
ихлас күңелдән сөйләшү*

*«Татарстан» — иң юнь бәяле журнал — елына 7 сум 20 тиен генә!
Яңа басмага язылып
калырга онытмагыз!
Индекслары: татарчасы — 73377
русчасы — 73947*

РЕДАКЦИЯ КОЛЛЕГИЯСЕ:

Баш редактор **Р. Ә. Мостафин**

В. Д. Григорьев, М. З. Зәкиев, С. А. Ларионов, А. Л. Литвин, Т. Ф. Морозова, Н. М. Мөхәррәмов, В. И. Пискарев (баш редактор урынбасары), **В. Н. Русаков, В. Ф. Семенов, Б. Ф. Солтанбеков, И. Р. Таһиров, Р. М. Харисов, Р. С. Хәкимов.**

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

Телефоннар: белешмәләр өчен — 53-07-35, баш редактор — 53-27-36, баш редактор урынбасары — 53-07-23, җаваплы секретарь — 53-31-92,

бүлекләр: иҗтимагый-сәяси тормыш — 53-54-88, социаль-икътисади проблемалар — 53-07-25, фипософия, әхлак һәм хокук — 53-07-27, фән, мәгариф һәм мәдәният — 53-07-29, миппи-гуманитар проблемалар — 53-57-91, тәрҗемә — 53-07-33.

Производствога бирелде 17.06.1991. Басарга кул куелды 5.08.1991. Кәгазь форматы 70х108 1/16. Типография кәгазе № 2.
Офсет басмада. Күләме 6,0 басма табак. 8,4 шартлы табак. Нәшер-хисап табагы 9,2. Заказ II-276.
Тираж татар һәм рус телләрендә 10 353. Айга бер тапкыр чыга.
КПССның Татарстан республика комитеты нәшрияты типографиясе. 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

ТР Милли китапханәсенең вакытлы матбугат бүлеге фондларыннан

ТАССРның 100 еллыгына багышлана

ТАТАРСТАН

تاتارستان



Минтимер Шәрип улы Шәймиев – Татарстан Республикасының беренче Президенты

7

1991